# **Псалтырь (Зәбур китабы).**

Псалтырь (Зәбур) уку алдыннан әйтелә торган догалар.

Корбанчы: Безнең Аллабыз данлаулы, һаман да, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә. Амин.

Дөнья кешесе: И Ходай Гайсә Мәсих, безнең Аллабыз, изге аталарыбыз догалары хакына, безне ярлыка, амин.

Шөкер Сиңа, и Аллабыз, шөкер Сиңа.

Күк Патшасы, Юатучы, хакыйкать Рухы, кайда булса да бар Син, барын да өлгерттерәсең, яхшылыклар хәзинәсе Син, терелек бирүче Син Үзең, безгә килеп урнаш, безнең һәрбер шакшылыгыбызны әрче, җаннарыбызны коткар, Син игелекле.

Изге Алла, Изге Кодрәтле, Изге Үлемсез, безне ярлыка. *(3 тапкыр).*

Шөкер Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә. Амин.

И иң изге Өчле, безне ярлыка; и Ходай, безне гөнаһтан тазарт; и Иябез, кануныңнан язганыбызны кичер; и Изге, безгә килеп, безнең хәлсезлекләребезне савыктыр, Үз исемең өчен.

И Ходай, ярлыка. *(3 тапкыр).*

Шөкер Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә. Амин.

И Күктәге Атабыз, изге ителеп торсын исемең Синең; килсен патшалыгың Синең; җирдә дә күктәгечә булсын иркең Синең. Бүген көнлек икмәгебезне бир безгә, һәм бурычларыбызны безгә кичер, без дә безгә бурычлы булганнарга кичергән кебек; һәм сыналуга безне кертмә, әмма яманнан безне котылдыр.

*Тропарьләр: 6-нчы көйгә.*

Безне ярлыка, и Ходай, безне ярлыка, без гөнаһлылар үзебезне дөресләргә бер җавап та бирә алмагач, тик Син безне тотучыга шушылай гына инәләбез: и Ходай, безне ярлыка.

Шөкер: И Ходай, Синең пәйгамбәреңнең кадерле тантанасы җыенны күк итеп күрсәткән, кешеләр белән фәрештәләр сөенешәләр. Аның догалары хакына, и Мәсих Алла, гомеребезне тыныч үткәздер, Сиңа җырласак иде: аллилуиа.

Әле дә: Гөнаһларым күптән күп, и Алла Анасы, мине коткар дип, сыенып, и данлаулы таза Кыз, Сиңа инәләмен. Хәлсезләнгән җанымны күреп, Үз Улың безнең Аллага инәл, кылган усал эшләремне барысын да кичерсен иде.

И Ходай ярлыка. *(40 тапкыр). Күпме телисең башыр.*

*Тере итүче Изге Өчлегә дога.*

И иң изге Өчле, бөтен дөньяны булдыручы Алла, тиз итеп күңелемне юнәлтеп җибәр, Алла Рухы белән язылган бу китапны аң белән башлап, игелекле эшләр белән бетерсәм иде. Бу мәдхияләрне Изге Рух Давыт пәйгамбәр авызы аркылы әйткән, хәзер инде мин яраусыз аларны укымакчы буламын. Үземнең наданлыгымны аңлап, Сиңа егылып инәлеп, Синнән булышу сорыймын. И Ходай, уемны юнәлт, һәм күңелемне ныгыт; әйткән сүзем авызымда гына булмасын иде, әмма шушыларны әйтеп, алардан өйрәнеп, яхшы эшләр кылырга әзерләнсәм иде. Яхшы эшләр белән яктырылып, Синең хөкемеңдә бар сайлаганнарың белән өлештәш булып, уң ягыңда торсам иде. Хәзер инде, и Иям, бәхиллә, эч күңелемнән инәлеп, телем белән дәшеп, болай әйтим:

Килегез, Патшабыз Аллага башырыйк.

Килегез, Патша Аллабыз Мәсихкә егылып башырыйк.

Килегез, Патша Аллабыз Мәсихнең Үзенә егылып башырыйк.

*Аннары аз гына туктап тор, бар тойгыларың тынычлансын, шунда әкрен генә башлап җибәр. Ялкауланмыйча, йомшак күңел һәм кайгылы рух белән болай әйт:* Бозыкларның киңәшенә бармаган ... .

## **Пәйгамбәр патша Давытның җыруы.**
## **Беренче кафисма.**

Беренче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

1Бозыкларның киңәшенә бармаган, һәм гөнаһлылар юлында тормаган, һәм юкка чыгаручылар
җыенында утырмаган кеше бәхетле. 2Әмма иркесе – Ходай канунында, һәм Аның канунына көн-

төн өйрәнеп торыр ул. 3Агым сулар янына утыртылган, үз вакытында җимешен бирәсе агач
кебек булып торыр ул, яфрагы да коелмас; һәм ни генә эшләсә дә, ул барына да өлгерер.
4Бозыклар алай түгел, алай түгел: әмма җир өстеннән җил өреп җибәрә торган тузан кебек.
5Шунлыктан бозыклар хөкемдә, гөнаһлылар гаделләр җыенында тора алмаслар. 6Чөнки
гаделләрнең юлы Ходайга билгеле, бозыкларның юлы исә юкка чыгар.

Икенче псалом (мәдхия).
*Псалом Давида*
*(Давытның мәдхиясе).*

1Халыклар нигә котырышалар һәм кешеләр ник булмасны уйлашып торалар? 2Җир патшалары
алга чыктылар һәм башлыклары Ходайга да, Аның Мәсихенә дә каршы бергә җыелдылар.
3”Аларның богауларын өзик һәм өстебездән аларның күтәрәмен ташлыйк”, *диешәләр*. 4Күкләрдә
Торучы алардан көләр, һәм Ходай аларны хур итәр. 5Ул чакта Ул аларга ачуланып әйтер һәм
ярсуында аларны болгатып бетерер. 6Изге тавы Сион өстеннән патша булып Мин ич Аңардан
куелганмын, 7Ходай кушканын әйтеп бирергә дип. Ходай Миңа әйткән: “Син Минем Улым,
Мин Сине бүген тудырдым. 8Миннән сора, һәм Синең кулыңа халыкларны да, кырыйларыннан
алып биләп торырга җирне дә бирермен. 9Аларны тимер таяк белән көтәрсең, чүлмәкче
савытлары шикелле аларны ватырсың”, дигән. 10Менә инде, патшалар, аңга килегез, җир
түрәләре, барыгыз да үгет алыгыз. 11Ходайга куркынып эшләгез һәм Аңа калтырап сөенегез.
12Ходай ачуланмасын өчен, үгет алыгыз, Аның ярсуы тиз ялкынланса, дөрес юлны җуеп
җибәрерсез. Аңа ышанучылар барысы да бәхетле.

Өченче псалом (мәдхия).
1*Псалом Давида, когда он бежал от Авессалома, сына своего*
*(Давытның үз улы Абшалумнан качып киткән чагында әйткән мәдхиясе).*

2И Ходай, ник мине кысучылар күбәйгәннәр? Күбесе миңа каршы торалар. 3Күбесе: “Алласы
аны коткармас”, дип җаныма әйтәләр. 4Син исә Ходай Үзең мине яклаучы, минем даным һәм
башымны күтәрүче Син. 5Тавышым белән Ходайга ялвардым, һәм Ул изге тавыннан мине
ишетте. 6Мин йокыга киттем дә йокладым, тордым, чөнки мине Ходай яклый. 7Мине чолгап
алып, миңа ябышучылар мең меңләп булса да, курыкмам. 8И Ходай, тор, әй Аллам, мине коткар,
чөнки Син буштан миңа дошманлык итүчеләрнең барысын да яраладың, гөнаһлыларның
тешләрен җимердең. 9Ходайдан саклау килә, һәм бәрәкәтең халкың өстендә тора.

Шөкер:

Дүртенче псалом (мәдхия).
1*В конец. Песнь. Псалом Давида.*
*(Ахырга. Җырлап. Давытның мәдхиясе).*

2Мин инәлгән чагымда дөреслегем Алласы мине ишетте. Тарлыгымда Син миңа киңлек бирә
торган идең. Әле дә мине кызган һәм догамны ишет. 3Әй адәм балалары, кайчанга чаклы
күңелләрегезне катыландырып торырсыз? Ник бушны сөеп, ялганны эзлисез? 4Белеп торыгыз,
Ходай Үзенә яраулыны искитәрлек итеп данлаган. Ходайга дәшкән чагымда Ул мине ишетер.
5Ачуыгыз килсә дә, гөнаһ кылмагыз; күңелегездә әйткәнегезгә яткан урыныгызда үкенегез.
6Корбанга дөреслек китерегез, һәм Ходайга өмет итегез. 7Күп кешеләр: “Безгә игелек кем
күрсәтер? И Ходай, йөзеңнең яктысы безгә билгеләнгән”, дип әйтәләр. 8Күңелемә куаныч
салдың: алар бодайның, йөземнең һәм майның җимешенә тук. 9Берьюлы тыныч ятып
йоклармын, чөнки Син Ходай, мине үзем генә өметләгәнгә урнаштырдың.

Бишенче псалом (мәдхия).
1*О наследствующей. Псалом Давида.*
*(Мирас итеп алучы хакында. Давытның мәдхиясе).*

2И Ходай, сүзләремне тыңлап ал, дәшүемне аңлап ал. 3И Патшам һәм Аллам, догамның авазын
тыңла, чөнки Сиңа Ходай инәлермен. 4Иртә беләнге тавышымны ишет, иртә белән алдыңда
торырмын, һәм мине күрерсең. 5Чөнки Син канунсызлыкны яратмый торган Алла, яманлык
кылучы Синең яныңа урнаша алмас. 6Кануннан язучылар да күзең алдында тора алмаслар,
канунсызлык кылучыларның барысын да күрәлмадың. 7Ялганны сөйләүчеләрнең барысын да

юкка чыгарып бетерерсең, кан түгүче кешедән һәм ялагайдан Ходай җиренә. [8]Мин исә күп рәхимеңнән Синең өеңә керermen, Синнән куркынып, изге йортыңа башырырмын. [9]И Ходай, мине дөреслегеңдә йөрт, дошманнарым сәбәпле алдымдагы юлымны төзәт. [10]Чөнки авызларында чынлык юк, күңелләре буш уйлы, тамаклары ачкан кабер шикелле, телләре белән юмалаганнар. [11]И Алла, аларны гаепләә, уйлаганнарыннан чигенсеннәр; бозыклары күпкә күрә, аларны куып җибәр, чөнки алар, Ходай, Сине үтә рәнҗеттеләр. [12]Сиңа өмет итүчеләр барысы да куансыннар иде, мәңгегә сөенсеннәр иде, һәм алар эченә урнашырсың, исемеңне сөючеләр дә Синең белән мактанышырлар. [13]Чөнки Син Ходай гаделгә игелек итәрсең; калкан белән каплаган кебек, безне Үз ризалыгың белән ябып саклыйсың.

Алтынчы псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Песнь. Об осьмом (дне). Псалом Давида.*

*(Ахырга. Җырлап. Сигезенче (көн) турында. Давытның мәдхиясе).*

[2]И Ходай, ачуың белән мине гаепләмәсәң иде, ярсып миңа кыен күрсәтмәсәң иде. [3]И Ходай, мине ярлыка, чөнки хәлем бетте инде, и Ходай, мине савыктыр, чөнки сөякләрем калтырыйлар. [4]Җаным да бик йөдәде. И Ходай, кайчанга чаклы инде? [5]И Ходай, борылып җанымны коткар, Үз рәхимең хакына мине сакла. [6]Чөнки үлгәч Сине исенә алучы юк, тәмугта Сиңа кем үкенә алыр? [7]Үкси-үкси газапланып беттем, төн саен урнымны юамын, күз яше белән түшәгемне чылатамын. [8]Ачуыңнан күз алдым караңгыланды. Дошманнарым арасында таушалып беттем. [9]Әй канунсызлык кылучылар, барыгыз да миннән китегез, чөнки Ходай елаган тавышымны ишетте. [10]Ходай инәлгәнемне ишетте, Ходай догамны кабул итте. [11]Бар дошманнарым оятка калып, болганышып бетсеннәр иде, чигенеп кире китсеннәр иде, һәм тиз үк хурлыкка калсыннар иде.

Шөкер:

Җиденче псалом (мәдхия).

[1]*Псалом Давида, который он воспел Господу, по поводу слов Хусия, сына Иемениина*

*(Беньямин ыругыннан Куш исемле кеше кылган эшләр хакында Давытның Ходайга әйткән кайгы җыры).*

[2]И Ходай Аллам, Сиңа ышандым, мине куучыларның барысыннан да мине сакла һәм мине коткар. [3]Коткаручы, саклаучы юклыктан, дошман, арыслан кебек, җанымны талап алмасын иде. [4]И Ходай Аллам, моны кылган булсам, кулымда гаделсезлек булса, [5]миңа усаллык кылганнарга усаллык кайтарган булсам, дошманнарымнан хәлем бетеп егылыйм алайса, [6]дошман җанымны куып, тормышымны җиргә таптап бетерсен, һәм данымны туфракка күмсен.[7]И Ходай, ачуланып тор, дошманнарыңа җирләрендә куәтеңне күрсәт, и Ходай Аллам, Үзең биргән боерыкны җиренә китерергә тор. [8]Халыклар җыены әйләнәңә килеп торырлар, алар өстеннән дә югары күтәрел. [9]Ходай халыкларны хөкем итәр. И Ходай, дөреслегемә карап, усаллык кайтармаганыма карап, мине хөкем ит. [10]И күңелләрне һәм эчләрне гадел тикшерүче Алла, гөнаһлыларның усаллык итүчеләре бетсен иде, һәм гаделне төзек йөрт. [11]Миңа булышучы, дөрес күңеллеләрне саклаучы Алла. [12]Алла гадел тикшерүче һәм нык торучы, озак түзүче һәм көн саен ачуланучы түгел. [13]Әгәр кире кайтмасагыз, коралын кайрар, җәясен корып төзәр, [14]җәядә үтергеч кораллар әзерләр, укларын янасыларга аныклаган. [15]Менә бозык кеше дөрессезлек чире белән чирләп, зыян тидерергә уйлый башлаган, шуннан канунсызлык кылган. [16]Баз казыган, аны бик тирән иткән, казыган базына үзе егылыр. [17]Үз усаллыгы үз башына тияр, һәм дөрессезлеге үз түбәсенә төшәр. [18]Ходайны гаделлегенә күрә мактармын, һәм югарыгы Ходайның исеменә җырлармын.

Сигезенче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. О точилах. Псалом Давида*

*(Ахырга. Йөзем савытлары турында. Давытның мәдхиясе).*

[2]И Ходай, Ходаебыз, Синең исемең бөтен җир өстендә ничек кенә искитәрлек, ямең күкләрдән югары күтәрелгән. [3]Яшь балаларның һәм имчәк имә торганнарның авызыннан Үзеңне мактаттың: үч итүче дошманны кырып бетерер өчен, дошманнарың сәбәпле. [4]Син беркеткән күкләргә, Үз кулың булдырган айга һәм йолдызларга карап карагач, [5]ни нәрсә кеше? Алай да аны исеңдә тотасың ич. Я адәм улы ни? Аңа игелек итәсең икән. [6]Фәрештәләрдән аз гына аны ким иткәнсең, олылык һәм санлау белән аны кадерләгәнсең. [7]Кулларың эшләренә аны баш итеп куйгансың; барын да аягы астына буйсындыргансың: [8]сарыкларны һәм үгезләрне барысын да,

тагы шулай кыр җәнлекләрен, 9һава кошларын һәм диңгез балыкларын да, диңгездә йөзә
торганнарның барысын да. 10И Ходай, Ходаебыз, Синең исемең бөтен җир өстендә ничек кенә
искитәрлек.

Шөкер:

1-нче кафисмадан соң,
Өч изгелек. И иң изге Өчле: И күктәге Атабыз:
*Тропарьләр: 1-нче көйгә.*

Канунсызлыкларда яралганмын мин азгын, күккә таба карарга да кыймыйм, әмма Синең адәмне яратуыңа өметләнеп дәшәмен: и Алла, мин гөнаһлыны тазарт, һәм коткар мине.

Гадел дә көчкә генә котыласы булгач, мин гөнаһлы кайда күренермен? Авырлыкка да, көн кызуына да түзеп үткәрмәдем, әмма унберенче сәгаттә генә килгән ялчылары белән мине сана, и Алла, һәм коткар мине.

Шөкер: Аталык кочагыңны миңа да ачсаң иде, тормышымны азгынлыкта үткәрдем шул, Синең бетми торган юмартлыкларыңның байлыгына карап, и Коткаручы, әле минем ярлыга калган күңелемне кире борып җибәрмәсәң иде. Чөнки Сиңа Ходай йомшак күңел белән дәшәмен: күккә дә, Сиңа да гөнаһлы булдым.

Әле дә: Мәсихчеләрнең өмете изге Кыз, Алланы кеше уе белеп җиткезә алмаслык тудыргансың, югары чирүләр белән туктаусыз инәл, сөю һәм иман белән Сине кадерләүчеләрне барысының да гөнаһларын кичерсен иде.

Әй Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И бар нәрсәне дә Тотучы, белеп җиткезә алмаслык, яктының башы, һәм бик хикмәтле куәт, ипостась Сүз Алланың Атасы, һәм Үзеңдәй бер үк куәтле Рухыңны чыгаручы. Мәрхәмәтле рәхимең һәм әйтә алмаслык игелегең хакына гөнаһ упкынында торган адәм затыннан җирәнмәгәнсең, әмма изге өйрәтүләреңнең Аллалык яктылары, канун һәм пәйгамбәрләр белән дөньяга яктырткансың, аннары безгә бердәнбер туган Улыңны тән белән яктырырга һәм яктылыгыңа безне өйрәтергә ризалык иткәнсең. Синең колакларың безнең инәлгән авазыбызны ишетсен иде, уяу һәм аек күңел белән бу тормышның төндәй караңгылыгын, и Алла, безгә үткәзергә дә бүләк ит; барысын да хөкем итүче Синең Улыңның һәм безнең Аллабызның килүен көтеп торсак иде. Йоклап ятмыйча, әмма уяу килеш һәм боерыкларың кыла торган килеш Аңа очрап, Аның сөенечкә керсәк иде. Анда бәйрәм итүчеләрнең тавышлары тукталмый һәм йөзеңнең әйбәтлеген әйтеп бетерер хәл юк, чөнки Син игелекле һәм адәм сөючән Алла, һәм Сиңа дан китерәбез, Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

## Икенче кафисма.

Тугызынчы псалом (мәдхия).
1*В конец. О тайнах сына. Псалом Давида*
*(Ахырга. Улының серләре хакында. Давытның мәдхиясе).*

2И Ходай, бар күңелем белән Сине данлармын, бар могҗизаларыңны әйтермен. 3Синең хакыңа
сөенермен дә, куанырмын да, и Югарыдагы, Синең исемеңә җырлыйм. 4Дошманнарым кире
киткән чакта, йөзеңнән хәлләре бетеп юкка чыгарлар. 5Чөнки Син хөкемемне һәм дәгъвамны хәл
иттең; гадел хөкем итүче Син тәхеткә утыргансың. 6Халыкларга кыен тидердең, һәм бозык кеше
югалды. Исемен гомергә, һәм гомердән гомергә бетердең. 7Дошманның кораллары бөтенләй
бетте, калаларын да җимереп бетердең: аны искә китерү дә шаулап югалды. 8Әмма Ходай
гомергә тора, хөкем итәргә тәхетен әзерләгән. 9Ул дөньяны гадел тикшерер, халыкларны
дөреслек белән хөкем итәр. 10Ходай мескеннең сыенычы, кирәкле чагында кайгыларында
булышучысы. 11Исемеңне белүчеләр Сиңа өмет итсеннәр, и Ходай, чөнки Үзеңне эзләүчеләрне
калдырмагансың. 12Сионда торучы Ходайга җырлагыз, Аның эшләрен халыклар арасында
белдерегез, 13чөнки мескеннәр каны өчен үч кайтаручы аларны искә алган, тилмергәннәрен
онытмаган. 14И Ходай, мине ярлыка, дошманнарымнан кимсетелгәнемне күр, мине үлем
капкасыннан коткаручы Син. 15Сион кызының капкасы төбендә бар даныңны белдерсәм иде.
Син коткарганга сөенербез. 16Халыклар әзерләгән бәлаләренә үзләре батканнар, яшереп салган
тозакларына үз аяклары эләккән. 17Хөкем итүче Ходай билгеле, гөнаһлы кеше үз кулының

эшләренә чорналган. [18]Гөнаһлылар, Алланы онытучы халыклар тәмугка китсеннәр. [19]Чөнки
ярлы кеше бөтенләй онытылмас, мескеннәрнең түзгәне бөтенләй үк юкка китмәс. [20]И Ходай,
тор, кеше өстен булмасын, халыклар Синең алдыңда хөкем ителсеннәр иде. [21]И Ходай,
халыкларга канун куючыны куй, алар үзләренең кеше икәнен белсеннәр иде. [22]И Ходай, ник
ерак торасың, кайгылы, кирәкле чакта карамыйсың? [23]Бозык кеше горурланган чагында, ярлы
кеше янып тора; иткән исәпләренә чорналып бетәләр. [24]Чөнки гөнаһлы кешене җанының
нәфесләре өчен мактыйлар, кыерсытучы хуплана. [25]Гөнаһлы кеше Ходайны рәнҗетә: “Күп
ачуланса да, кыен тидермәс”, ди. Алдында Алласы юк. [26]Юллары һәрчакта шакшыланалар,
хөкемеңне булмаска куя, бар дошманнарын тотып тора. [27]Чөнки үз күңелендә әйткән:
“Кузгалмам, тумыштан тумышка зыянсыз торырмын”, дигән. [28]Аның авызы тулы каргау,
явызлык һәм юмачылык, теле белән читенлек һәм авырлык тидерә. [29]Гаепсезне үтерер өчен,
яшерен җирдә байлар белән посып утыра, күзләре ярлыны сагалыйлар. [30]Арыслан өнесеннән
сагалаган кебек, яшерен җирдә сагалап тора, ярлыны тотып өстерәп китерим, дип сагалый.
[31]Тозагында аны хур итәр, *әмма* мескеннәрне үз кулына төшергәч, үзе сыгылып егылыр. [32]Чөнки
үз күңелендә әйткән: “Алла онытты, бөтенләй күрмим дип, йөзен борды”, дигән. [33]И Ходай
Аллам, тор, кулың күтәрелсен, мескеннәреңне бөтенләй онытма. [34]Бозык кеше ни белән
Алланың ачуын китергән? “Кыен тидермәс” дип, күңелендә әйткәне белән. [35]Йөдәвен дә,
ачучанлыгын да Син күрәсең. Синең кулыңа тапшырылсын; мескен Сиңа кала, үгигә булышучы
Син. [36]Гөнаһлының һәм яманның кулын ват; гөнаһы эзләнер һәм табылмас. [37]Ходай гомергә,
һәм гомердән гомергә Патша. Мәҗүсиләр, Аның җиреннән югалырсыз. [38]И Ходай,
мескеннәрнең теләген ишеттең, әзер күңелләренә колагыңны салдың. [39]Үгинең һәм юашның
арасына кер, җирдә моннан болай кеше горурланмасын иде.

### Унынчы псалом (мәдхия).
### *В конец. Псалом Давида*
### *(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

[1]Ходайга өмет итәм, ник соң җаныма әйтәсез: “Кош кебек тауларга китеп тор”, дип. [2]Менә
гөнаһлылар, дөрес күңеллеләргә караңгыда атарга дип, җәяләрен кордылар, садакларында
укларын әзерләделәр. [3]Син төзегәнне алар ваттылар, гадел исә ни эшләде соң? Ходай Үзенең
изге йортында. [4]Ходай, − Аның тәхете күктә, Аның күзләре ярлыны күреп тора, күз кабаклары
адәм улларын сынап торалар. [5]Ходай гаделне дә, бозыкны да сынап тора, дөрессезлекне сөюче
исә үз җанына зыян китерә. [6]Ходай гөнаһлыларга тозак яудырыр: касәләренең өлеше − ут, һәм
күкерт, һәм давыллы җил. [7]Чөнки Ходай гадел, гаделлекне сөя, Аның йөзе гадел эшләрне күреп
тора.

Шөкер:

### Унберенче псалом (мәдхия).
### [1]*В конец. Об осьмом (дне). Псалом Давида*
### *(Ахырга. Сигезенче (көн) турында. Давытның мәдхиясе).*

[2]И Ходай, мине коткар, чөнки яраулылар бетте, чөнки адәм улларында чынлык азайды инде.
[3]Һәркем үз якынына бушны сөйли: авызларында юмалау, күңелдән усаллык сөйлиләр. [4]Юмачы
авызны, мактанучан телне Ходай барын да бетерер. [5]“Телебезне үткенләндерик, авызыбыз
үзебездә ич, Ходай безгә кем?”, дип әйтүчеләрне *Ходай бетерер*. [6]Ярлылар газапланганлыктан
һәм мескеннәр йөдәгәнлектән инде торырмын, Ходай әйтә, коткаручы булырмын, коткаруымны
нык итеп итәрмен, ди. [7]Ходай сүзләре − таза сүзләр, балчыктан әрчелеп, утта җиде тапкыр
эретеп тазартылган көмештәй. [8]И Ходай, Син безне карап сакларсың шушы тумыштан һәм
гомергә. [9]Әйләнәдә бозыклар йөриләр. Югарылыгыңа карап, адәм уллары өчен күп
кайгыртасың.

### Уникенче псалом (мәдхия).
### [1]*В конец. Псалом Давида*
### *(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

[2]И Ходай, кайчанга чаклы мине гел онытып торырсың? Кайчанга чаклы миннән йөзеңне борып
торырсың? [3]Кайчанга чаклы мин җанымны тынычсызлыкта, күңелемне көн-төн кайгыда
тотармын? Кайчанга чаклы алдымда дошманым горурланып торыр? [4]И Ходай Аллам, миңа

күзеңне сал, мине ишет, күземне яктырт, йоклаганда үлмәсәм иде. [5]Дошманым: “Аны җиңдем”,
димәсен иде. [6]Әгәр кузгалсам, мине кысучылар куанышырлар. [7]Мин исә Синең рәхимеңә өмет
иттем, күңелем Син коткарганга сөенер; миңа игелек итүче Ходайга җырлармын, һәм югарыгы
Ходайның исемен данлармын.

Унөченче псалом (мәдхия).
*В конец. Псалом Давида*
*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*
[1]Акылсыз үз күңелендә: “Алла юк”, дип әйткән. Алар азганнар һәм эшләрендә ямьсезләнгәннәр:
игелек кылучы юк. [2]Алланы аңлаучы, я эзләүче бар микән дип, Ходай күктән адәм улларына күз
төшергән. [3]Бары берьюлы авышканнар, яраусыз булганнар, игелек кылучы юк, берәү дә юк.
[4]Канунсызлык кылучылар бар да, минем халкымны, икмәк ашаган кебек, ашаучылар аңга
килмәсләр микәнни? Ходайны искә алмаганнар. [5]Куркыныч юк җирдә, котчыгаргыч
курыкканнар, чөнки Ходай − гаделләр затында. [6]Ярлының киңәшеннән көлдегез, әмма аның
ышанганы − Ходай. [7]Сионнан Исраилгә котылуны кем бирер? [8]Ходай Үз халкын тоткыннан
кайтаргач, Ягъкуб сөенер һәм Исраил куаныр.

Шөкер:

Ундүртенче псалом (мәдхия).
*В конец. Псалом Давида.*
*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*
[1]И Ходай, Син тора торган урында кем тора алыр? Я Синең изге тавыңда кем урнашыр?
[2]Шиксез йөрүче һәм дөреслек кылучы, күңелендә чынны сөйләүче, [3]*аннары* теле белән
юмаламаган, һәм якынына усаллык кылмаган, һәм якыннарын хурлаганны кабул күрмәгән кеше;
[4]яманлык итүчене юкка саный торган, әмма Алладан куркучыларны мактый торган, якынына
иткән антын бозмый торган кеше; [5]акчасын арттырып алырга бирмәгән, һәм гаепсезләрне
гаепләтер өчен биргән бүләкне кабул итмәгән кеше. Шушыларны кылучы гомергә кузгалмас.

Унбишенче псалом (мәдхия).
*Столпописание Давида*
*(Давытның баганадагы язуы).*
[1]И Ходай, мине сакла, чөнки Сиңа өмет иттем. [2]Ходайга әйттем: Син минем Ходаем, минем
игелекләрем Сиңа кирәкле түгел. [3]Үз җирендәге изгеләргә Ходай Үзе теләгәнне алар аркылы
искитәрлек иткән. [4]Аларның кайгылары күбәйгән, күбәйсә дә, тиз узган; дошманнар җыенына
канлы корбан китерергә катнашмам, аларның исемнәрен дә авызым белән искә алмам. [5]Миңа
тигән мал да, өлеш тә – Ходай; миңа тигән малны рәтләүче − Син. [6]Үлчәү җебе миңа иң яхшы
җирне үлчәп биргезде, миңа тигән җир иң яхшы җир. [7]Мине акыллыландырган Ходайны
данлармын; төнгә чаклы ук эчемнән өйрәнәм. [8]Ходайны һаман үз алдымда күрдем, чөнки Ул,
мин какшамасын дип, минем уң ягымда. [9]Шунлыктан күңелем куанды, һәм телем дә сөенде;
тәнем дә өмет белән җиргә керер. [10]Чөнки Син җанымны тәмугта калдырмассың һәм изгеңә черү
тидертмәссең. [11]Миңа терелек юлларын белдердең: ачык йөзеңнән мине сөенечкә
тулыландырсың; уң кулыңда рәхәтлек тора мәңгегә.

Уналтынчы псалом (мәдхия).
*Молитва Давида.*
*(Давытның догасы).*
[1]И Ходай, дөреслегемне ишет, инәлгәнемне тыңла, ялганламый торган авызымның догасын
аңлап ал. [2]Миңа хөкем Үзеңнән булсын иде, дөреслекне күзем күрсен иде. [3]Син күңелемне
сынадың, мине төнләтеп күрдең, эретеп карадың, һәм миндә дөрессезлек табылмады. [4]Авызым
кеше эшләрен яманлап сөйләшмәсен иде, авызыңнан әйтелгән сүзләр буенча читен юлны
тоттым. [5]Аякларымны Үз сукмакларыңнан йөргез, аякларым авышмасыннар иде. [6]И Алла, Син
мине ишеткәнгә күрә, мин Сиңа дәштем, миңа колагың сал, һәм сүзләремне тыңлап ал. [7]Уң
кулыңа карышучылардан Үзеңә өмет иткәннәрне саклаучы, миңа искитәрлек игелек ит. [8]Күз
карасын саклагандай, и Ходай, мине сакла, канатың белән мине бөркә [9]мине рәнҗетүче
бозыклардан: дошманнарым җанымны чолгап алдылар. [10]Көрлекләреннән йөрәкләрен

катыландырып, телләре белән горур сөйләшәләр. [11]Мине куучылар мине чолгап алдылар, мине
җиргә егыйк дип, күзләрен җимереп карыйлар. [12]Тотарга торган арыслан кебек, аулакка
яшеренгән яшь арыслан кебек, мине тоттылар. [13]И Ходай, тор, сизмәстән килеп аларны
егылдыр, бозык кешедән, кулыңа дошманнардан коралың белән җанымны коткар. [14]И Ходай,
аларны җирдәге кечеләрдән шушы гомердә аер, малларың белән корсаклары тулган, бала-
чагалары тукланганнар, һәм артканны яшь балаларына да калдырганнар. [15]Әмма мин Синең
йөзеңә дөреслек белән күренермен, алдымда даның күренгәч, тукланырмын.

Шөкер:

2-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 2-нче көйгә.*

Мин җимеш китерми торган агач, и Ходай, күңел йомшаклыгы җимешен йөртмимен шул, һәм кисеп ташланудан котым чыга, андагы сүнми торган уттан да куркамын. Шуңа күрә Сиңа инәләмен: шундый бәлагә туры китермичә, Үзеңә кайтарып мине коткар.

Диңгез дулкыннары шикелле канунсызлыкларым миңа тотындылар, көймә чоңгылда шикелле мин ялгыз күп гөнаһларымнан чайкалып йөримен, әмма тыныч җиргә тәүбә белән мине алып китер, и Ходай, һәм коткар мине.

Шөкер: Мине ярлыка, дип әйткән Давыт, мин дә Сиңа дәшәмен: гөнаһ кылдым, и Коткаручы, тәүбә белән гөнаһларымнан тазартып, мине ярлыка.

Әле дә: Мәсихчеләрнең сыенычлы яклаучысы, и Алланы тудырган Кыз, Үз Улыңа инәл, карышучының һәртөрле усалыгыннан һәм яманлыгыннан безне коткарырга дип, һәм кылган гөнаһларыбыз турыда безгә кичерү бирергә дип, рәхимле күңеллелегенең юмартлыклары хакына, Синең догалары белән, и Ана Кыз.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И бар нәрсәне дә Тотучы, безнең Ходаебыз Гайсә Мәсихнең һәм Синең бердәнбер туган Улыңның Атасы, шакшысыз тән, саф күңел, уяу акыл, адашмый торган зиһенне, Изге Рухыңның ябырылуын бир миңа, Мәсихеңдә чынлыкны табу һәм аңа кинәнү өчен. Аның белән Сиңа дан тиешле, Изге Рухың белән кадерләү һәм табыну тиешле, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

**Өченче кафисма.**

Унҗиденче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Отрока Господня Давида, который произнес Господу слова песни сей в день, в который избавил его Господь от руки всех врагов его, и от руки Саула, и сказал (Ахырга. Ходай колы Давытның мәдхиясе. Ходай Давытны барча дошманнарыннан һәм Шаулдан коткарган көнне Давыт Ходайга җыр багышлады):*

[2]И мине ныклаучы Ходай, Сине сөярмен! [3]Ходай − минем таянганым, һәм сыенганым, һәм
коткаручым, Аллам минем, булышучым, һәм өмет иткәнем Ул; яклаучым, һәм аралаучым, һәм
коткаруымның мөгезе. [4]Олылап Ходайга инәлермен дә дошманнарымнан котылырмын. [5]Үлем
чирләре мине тоттылар, һәм канунсызлык иделләре мине йөдәттеләр. [6]Тәмуг газаплары мине
чолгап алдылар, үлем тозаклары алдымда тордылар. [7]Көенгән чагымда Ходайга дәшеп, Аллама
ялвардым: Үзенең изге өеннән авазамны ишетте, һәм алдында ялваруым Аның колагына керер.
[8]Алланың аларга ачуы килгәнлектән, җир кузгалып тетрәде, һәм тау төпләре дерелдәп
кузгалыштылар. [9]Ачуыннан төтен бөркелде, һәм йөзеннән ут кабынды, Аңардан күмерләрне ут
алды. [10]Күкләрне сыгылдырып иңде, һәм Аның аяклары астында караңгы. [11]Херувимнәр өстенә
менеп очты, һәм җил канатлары өстендә очып барды. [12]Караңгыны Үзенә каплавыч итте,
әйләнәсендә Аның тора торган урны: һава болытларындагы караңгы су. [13]Аның алдында якты
ялтыраганлыктан болытлар боз һәм утлы күмерләр яудырдылар. [14]Ходай күктән күкрәде, һәм
Югарыдагы Үз тавышын бирде. [15]Уклар җибәреп бозыкларны таратты, һәм яшеннәрне
күбәйтеп, аларны болгатып бетерде. [16]И Ходай, Син кисәткәнлектән, ачуыңның җиле
искәнлектән, чишмәләр күренделәр, һәм дөньяның нигезләре ачылдылар. [17]Югартын иелеп мине
алды, дәү сулардан мине чыгарды. [18]Көчле дошманнарымнан һәм мине күрәлмый торганнардан,
миннән бигрәк ныгысалар да, мине коткарыр. [19]Яманлык күргән көнемдә алар алдыма килеп

төштеләр, һәм Ходай ныгытучым булды. [20]Ул мине иркенгә чыгарды, Үзе яратканга күрә мине
коткарыр. [21]Дөреслегем буенча Ходай миңа бирер, һәм кулларым тазалыгы буенча миңа
кайтарыр. [22]Чөнки мин Ходай юлларын тоттым, һәм Ходай алдында бозыклык кылмадым.
[23]Чөнки Аның хөкемнәре бар да минем алдымда, һәм боерыклары да миннән ерак китмәде.
[24]Аның алдында шиксез торырмын, һәм канунсызлыгымнан сакланырмын. [25]Дөреслегем буенча
һәм күзләре алдында кулларым тазалыгы буенча, Ходай миңа кайтарыр. [26]Яраулыга яраулыны
кылырсың, һәм гаепсез иргә гаебе юкча кылырсың, [27]сайланганга сайлануына карап
кыланырсың, әмма яманга ярсуланырсың. [28]Чөнки Син юашланган кешеләрне саклarsың, һәм
горурларның күзләрен юашландырырсың. [29]И Ходай, Син минем яктырткычымны яндырырсың,
и Аллам, караңгымны яктыртырсың. [30]Чөнки Синең аркылы сыналудан котылырмын, һәм
Аллам белән дивар аркылы атлап үтәрмен. [31]Аллам минем! Аның юлы шиксез, Ходай сүзләре
таза. Ул Үзенә өметләнгәннәрнең барысын да саклаучы. [32]Чөнки Ходайдан бүтән соң кем Алла?
Я Аллабыздан бүтән Алла кем? [33]Алла мине билемнән куәт белән чолгаучы, һәм Ул минем
юлымны шиксез итте: [34]Аякларымны боланныкы кебек җитез итә, һәм мине биек урынга
торгыза. [35]Куларымны сугышка өйрәтә, һәм сеңерләремне бакыр җәя кебек итте. [36]Син миңа
котылдыра торган калкан бирдең, һәм уң кулың мине аралап алды; үгетең мине төзәтеп
җиткезер, шул үгетең мине өйрәтеп җиткезер. [37]Атламнарымны киңәйттең, һәм табан асларым
талыкмады. [38]Дошманнарымны куып, артларыннан җитәрмен, һәм алар беткәнгә кадәр кире
кайтмам. [39]Аларны кысармын, һәм тора алмаслар, аякларым астына егылырлар. [40]Һәм сугышка
дип мине билемнән куәт белән чолгадың, миңа каршы торганнарны аягым астына ектың.
[41]Дошманнарымны миңа аркалары белән бордың, һәм мине күрәлмаганнарны бетердең. [42]Алар
инәлгәннәр иде, тик коткаручы булмады; Ходайга *инәлгәннәр иде*, һәм Ул аларны тыңламады.
[43]Җил күтәрә торган тузан кебек, аларны уармын, юлдагы балчыкны шомартканча, аларны
шомартырмын. [44]Халык карышуыннан мине коткарырсың, халыкларга мине башлыкка куярсың.
Мин белмәгән халык миңа кол булды, [45]минем турда ишетеп, миңа баш салдылар; ят уллар миңа
ялганладылар, [46]ят уллар искерделәр һәм сукмакларыннан авыштылар. [47]Ходай тере һәм Алла
данлаулы! Коткаручым Аллам күтәрелсен иде. [48]Алла − минем өчен үч кайтаручы, һәм
халыкларны миңа буйсындыручы, [49]ачулы дошманнарымнан мине коткаручы. Миңа каршы
торучылар өстенә мине күтәрерсең, дөрес түгел кешедән мине коткарырсың. [50]Шушы сәбәпле, и
Ходай, Сине халыклар арасында данлармын, һәм Синең исемеңә җырлармын. [51]Син патшаларны
зурлап коткаручы, Үзең майлаган Давытка һәм аның нәселенә дә гомергә рәхим итүче.

Шөкер:

Унсигезенче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Псалом Давида.*

*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

[2]Күкләр Алланың олылыгын белдереп торалар, күк җәяме исә Аның куллары булдырганны
әйтеп тора. [3]Көн көнгә сүз әйтә, һәм төн төнгә белем бирә. [4]Аларның сөйләшүләре, сүзләре юк,
авазларының да ишетелгәне юк. [5]Аларның тавышы бөтен җиргә җәелгән, һәм аларның сүзләре
дөньяның бар кырыйларына җиткән. Үзе торыр урнын кояшта төзегән. [6]Киенеп матурланып
бүлмәсеннән чыккан кияү шикелле, һәм йөгерешкә чыккан батыр кебек, кояш үз юлыннан
куанып, ялтырап бара. [7]Аның чыгуы күкнең бер кырыеннан, һәм баруы икенче кырыена чаклы;
һәм аның җылысыннан берәү дә яшеренеп кала алмый. [8]Ходайның җаннарны төзәтә торган
кануны шиксез, Ходайның балаларны белемлеләндерә торган таныткычы[1] дөрес. [9]Ходайның
күңелне сөендерә торган дөресләндергечләре[2] туры; Ходайның күзләрне яктырылдыручы
боерыгы якты. [10]Ходайдан курку таза, гомердән гомергә тора; Ходайның хөкемнәре чын,
барысы да гадел. [11]Аларга алтыннан да, күп асыл ташлардан да бигрәк кызыгырлык, алар
кәрәзле балдан да татлы. [12]Чөнки бәндәң аларны саклый, аларны саклаганы өчен күп
кайтарылыр. [13]Гөнаһ кылганнарына кем төшенер? Яшереннәремнән мине тазарт, һәм [14]ят
гөнаһлардан да бәндәңне сакла; әгәр алар мине биләп тормаса, шиксез булырмын, һәм зур
гөнаһтан тазарырмын. [15]Шунда авызымның сүзләре һәм күңелемнең үгет уйлары Синең
алдыңда һаман яраулы булырлар, и Ходай, Син минем булышучым һәм коткаручым.

[1]Таныткыч – Алла тарафыннан ачылыш рәвешендә бирелгән күрсәтмәсе, үгете.

[2] Дөресләндергеч – кагыйдә, устав мәгнәсендә.

Унтугызынчы псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Псалом Давида.*
*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

[2]Көенгән көнне Ходай сине ишетсен иде, Ягъкуб Алласының исеме сине сакласын иде. [3]Изге урныннан сиңа булышсын иде, һәм Сионнан сине сакласын иде. [4]Китергән нәрсәңне барын да исенә алсын иде, һәм яндырган корбаның көр күренсен иде. [5]Ходай сиңа күңелең теләгәнчә бирсен иде, һәм бар киңәшеңне булдырып җиткерсен иде. [6]Син котылганга сөенербез дә, һәм Алла Ходаебыз исеме белән зураербыз; Ходай теләгәнеңне булдырсын иде. [7]Инде Ходай майлаган кешесен коткарганны белдем, изге күкләреннән аны ишетер; Ходайның уң кулының куәте аны коткара. [8]Кайсылары − сугыш арбаларында, башкалары – атларында, без исә Ходай Аллабызның исеменә сыенырбыз. [9]Алар кире чигеп егылдылар, без исә торып төзәлдек. [10]И Ходай, патшаны сакла, һәм Сиңа сыенган көнне безне ишет.

Егерменче псалом (мәдхия).
[1]*Псалом Давида.*
*(Давытның мәдхиясе).*

[2]И Ходай, Син куәтләндергәнгә патша сөенә, һәм Син аны коткарганга бик куана. [3]Аңа күңеле теләгәнен бирдең, һәм авызындагы теләген буш калдырмадың. [4]Чөнки Син аны игелекле дәүләтең белән каршы алдың, башына асыл ташлы таҗны кидердең. [5]Ул Синнән гомер сорады, һәм аны күп яшәттең, гомердән гомергә. [6]Син коткарганлыктан аның даны олы, аны данга һәм ямьлелеккә киендерерсең. [7]Чөнки аңа гомердән гомергә игелек итәрсең, Үзеңнең якты йөзең белән аны сөендерерсең. [8]Чөнки патша Ходайга өмет итә, һәм Югарыгының рәхиме белән какшамый торыр. [9]Синең кулың бар дошманнарыңа очрасын, уң кулың Сине күрәлмый торганнарны очратсын. [10]Үз алдыңда аларны яна торган мич кебек итәрсең: ачуы белән Ходай аларны болгатып бетерер, һәм аларны ут ашар. [11]Аларның нәселен җирдән югалтырсың, һәм орлыкларын адәм уллары арасыннан бетерерсең. [12]Чөнки Сиңа каршы усаллык уйладылар, үзләре булдыра алмаслык киңәш төзеделәр. [13]Аркалары белән аларны борырсың, калган көчләреңне йөзләренә төзәрсең. [14]И Ходай, куәтең белән күтәрел, Синең кодрәтләреңне данлап җырларбыз.

Шөкер:

Егерме беренче псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Об утреннем заступлении. Псалом Давида*
*(Ахырга. Таң ату хакында. Давытның мәдхиясе).*

[2]И Аллам, и Аллам, миңа аң сал, ник мине ташладың? Гөнаһ кылганнарымның гаебе котылуымны еракка җибәрә. [3]И Аллам, көндез инәлермен, ишетмәссең, төнлә дә инәлермен, акылсызлык дип миңа саналмас. [4]Син исә изге өйдә торасың, Исраилнең мактанганы. [5]Аталарыбыз Сиңа өмет иткәннәр, өмет иткәч, аларны коткаргансың. [6]Сиңа инәлгәч, сакланганнар; Сиңа өмет иткәч, оятка калмаганнар. [7]Мин исә җир корты, адәм түгел, кеше көлкесе һәм халыкка җирәнгеч. [8]Мине күрүчеләр бар да мине мыскыл иттеләр, башларын айкап, телләре белән әйттеләр: [9]"Ходайга өмет иткән иде, аны коткарсын, әгәр Аңа яраулы булса, аны сакласын", дип. [10]Әмма Син мине анам эченнән алучы, анам имчәкләреннән үк өмет иткәнем Син. [11]Тумыштан ук Сиңа бирендем, анам эченнән үк минем Аллам – Син. [12]Миннән бизмәсәң иде, чөнки хәсрәт якынлашты, чөнки миңа булышучы юк. [13]Күп үгезләр мине чорнап алдылар, көр үгезләр мине чолгап тоттылар. [14]Акырып, таларга торган арыслан кебек, миңа авызларын ачып тордылар. [15]Су шикелле коелдым, һәм бар сөякләрем дә таралаштылар; эчемдәге йөрәгем эрегән балавыз шикелле булды. [16]Ныклыгым чүлмәк китеге шикелле корыды, һәм телем тамагыма ябышты, һәм үлем туфрагына мине төшердең. [17]Чөнки күп этләр мине чорнап алдылар, яманнар җыены мине чолгап тоттылар; кулларымны да, аякларымны да чәнчеделәр. [18]Бар сөякләремне санап чыгарлык иттеләр, үзләре карап торып, мине мыскылладылар. [19]Киемнәремне үзләренә аердылар, һәм өс киемемә шобага салдылар. [20]Син исә Ходай, миннән булышуыңны ерак тотма, мине яклауга ашык. [21]Җанымны кылычтан коткар, һәм ялгыз җанымны эттән *коткар*. [22]Арысланнар авызыннан мине сакла, һәм бер мөгезле киекләрнең мөгезеннән мин юашны *сакла*. [23]Исемеңне туганнарыма белдерермен, җыен уртасында Сине

данлап җырлармын. [24]Ходайдан куркучылар, Аны мактагыз! Әй Ягъкуб орлыгы, барыгыз да
Аны данлагыз! Исраил орлыгы барысы Аннан куркып торсыннар! [25]Чөнки Ул ярлының догасын
кимсетмәде, яратмый да калмады, миннән йөзен бормады, һәм инәлгән чагымда мине ишетте.
[26]Минем мактавым Үзеңнән, зур җыенда Сине сөйләп белдерермен; Аннан куркучылар алдында
вәгъдә иткәннәремне кылырмын. [27]Ярлылар ашасыннар, ашагач туенырлар, һәм Ходайны
эзләүчеләр Аны данларлар, күңелләре тере торыр гомердән гомергә. [28]Искә алынырлар һәм җир
кырыйларыннан алып бар да Ходайга кайтырлар, һәм халыкларның бар тумалары Аңа
башырырлар. [29]Чөнки патшалык Ходайныкы, һәм халыкларны Ул тотып тора. [30]Җирнең барча
көрләре ашаганнар да башырганнар; җир эченә төшерелә торганнар барысы да Аңа егылып
башырырлар, җаным да Аның өчен тора. [31]Нәселем дә Аңа табыныр, киләсе нәсел Ходайга
билгеләнер; [32]Ходай дөресен кылган, Ул кылганны туасы кешеләргә билгеле итәрләр.

Егерме икенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

[1]Ходай мине көтеп йөртә, һәм бер нәрсәгә дә йөдәү булмам. [2]Мине үләнле җиргә урнаштырды,
тыныч су янында мине асрады. [3]Җанымны Үзенә борды, Үз исеме хакына мине дөрес
сукмагына кертте. [4]Шуңа күрә үлем караңгылыгы уртасыннан барсам да, усалдан курыкмам,
чөнки Син минем белән: Синең таягың һәм таянгычың – шулар мине тыныч иттеләр. [5]Мине
кысучыларга каршы алдымда миңа аш әзерләдең, башымны май белән майладың, һәм мине
эчерүче касәң, касәнең ин яхшысы. [6]Һәм рәхимең гомеремнең бар көннәрендә дә мине йөртер,
шунлыктан Ходай өенә күп көнгә урнашырмын.

Егерме өченче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. В первый день недели*

*(Давытның мәдхиясе. Якшәмбе көнне).*

[1]Җир дә, җирне тутырып торган нәрсәләр дә, дөнья да, аның өстендә торучылар да Ходайныкы.
[2]Ул аны диңгезләр өстенә корган, һәм инешләр өстенә торгызган. [3]Ходай тавына кем менәр? Я
Аның изге урнында кем торыр? [4]Гаепсез куллы һәм таза күңелле, үз җанын буш уйга
бирендермәгән кеше, һәм якынына юмалап ант итмәгән кеше. [5]Ул Ходайдан бәхиллек, һәм
саклаучы Алласыннан рәхимлелек алыр. [6]Ходайны эзләүче, Ягъкуб Алласының йөзен эзләүче
зат шушы. [7]Әй башлыклар, капкалырыгызны күтәрегез, һәм мәңге капкалар күтәрелегез! Һәм
данлыклы Патша керер. [8]Бу данлыклы Патша кем? Кодрәтле һәм куәтле Ходай, сугышларда
куәтле Ходай. [9]Әй башлыклар, капкалырыгызны күтәрегез, һәм мәңге капкалар күтәрелегез!
Һәм данлыклы Патша керер. [10]Бу данлыклы Патша кем? Чирүләр Ходае, Ул данлыклы Патша.

Шөкер:

3-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 3-нче көйгә.*

Җирдә торганда, әй җаным, тәүбәгә кил, туфрак кабердә җырламый, гөнаһлардан арындырмый. Мәсих Аллага дәшеп әйт: и күңелдәгене Күрүче, гөнаһ кылдым, мине хөкем иткәнче, мине ярлыка.

Кайчанга чаклы җаным гөнаһлар эчендә торырсың? Кайчанга чаклы тәүбә итүне алга сузарсың? Киләсе хөкемне уеңа ал, һәм Ходайга дәшеп әйт: и күңелдәгене Күрүче, гөнаһ кылдым, мине хөкем иткәнче, мине ярлыка.

Шөкер: Куркыныч хөкемдә әйтүчеләр булмаса да, дөрессезлегем күренеп тора, таныкчыларсыз да хөкем ителәм: чөнки вөҗдан китаплары ачылалар, һәм яшерен эшләр күренәләр. Минем кылган эшләремне анда бөтен халык алдында тикшерер көн җиткәнче, и Аллам, мине тазарт һәм коткар мине.

Әле дә: И Алладан дәүләт алган Иям Кыз, Синең турыда эшләгән куркыныч яшерен эш бер уйга да сыештырырлык түгел: чолгап ала алмаслыкны яралдырып, таза каннарыңнан тән белән чолгаганны тудыргансың. И таза Кыз, Үз Улың итеп Аңа инәл, Сине җырлый торганнарны барысын да коткарсын иде.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.
И бар нәрсәне дә тотучы Ходай, була башлаган чагы юк Атаның Сүзе, Үзең камил Алла Гайсә Мәсих, рәхимеңнең чагыштыргысыз мәрхәмәте хакына Үз бәндәләреңнән берничек тә аерылмыйсың, әмма һаман аларда торасың, калдырма мине, Үз бәндәңне, и иң изге Патша. Әмма мин тиешсезгә коткаруыңның шатлыгын бир, һәм Яхшы Хәбәреңне танып белү яктысы белән акылымны яктырылдыр, Хачыңны сөю белән җанымны бәйлә. Тәнемне исә нәфессезлегең белән матурла, уйларымны тынычландыр, һәм аякларымны таюдан сакла. И игелекле Ходай, канунсызлыкларым белән бергә мине харап итмә, әмма сына мине, и Алла, һәм күңелемне акылга китер, тикшер мине, һәм сукмакларымны күреп бел. Әгәр канунсызлык юлы миндә булса, моны күр, һәм аңардан кайтар, һәм мәңгелек юлына мине бастыр. Чөнки Син Үзең юл, һәм чынлык, һәм терелек, һәм Сиңа дан китерәбез, була башлаусыз Атаң белән, һәм иң Изге, һәм игелекле, һәм тере итүче Рухың белән, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

**Дүртенче кафисма.**

Егерме дүртенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

1И Ходай, җанымны Сиңа күтәрдем, и Аллам, Сиңа өметләндем, һичкайчан оятка калмасам иде,
дошманнарым да миннән көлмәсеннәр иде. 2Чөнки Сиңа өмет итүчеләр оятка калмаслар. 3Бушка
канунсызлык итүчеләр оятка калсыннар. 4И Ходай, юлларыңны миңа әйт, һәм сукмакларыңны
миңа белдер. 5Үз чынлыгыңнан мине йөргез һәм өйрәт мине, чөнки Син Алла коткаручым, көн
дә Сиңа өмет иттем. 6И Ходай, мәңгедән кыла килгән юмартлыгыңны һәм рәхимлелекләреңне
исеңә ал. 7И Ходай, яшьлегемдә белми кылган гөнаһларымны исеңә китермә, рәхимең буенча,
яхшылыгың хакына мине исеңә ал. 8Ходай игелекле һәм гадел, шуңа күрә гомерләрендә гөнаһ
кылучыларга канун бирер. 9Сабырларны хөкеменә өйрәтер, аларга Үз юлын белдерер. 10Ходай
васыятен һәм Аның боерыкларын эзләүчеләргә Ходай юллары рәхим белән чынлык була. 11И
Ходай, Үз исемең хакына гөнаһымнан мине тазарт, ул бик дәү шул. 12Ходайдан куркучы кеше,
кем ул? Үзе теләгән тормышына, Ходай аңа канун бирер. 13Җаны рәхәтлеккә кертелер, һәм
нәселенә дә җир тияр. 14Ходай Үзеннән куркучыларны ныкландыра, һәм васыяте аларга *моны*
күрсәтер. 15Күзләрем һаман Ходайга карап торалар, чөнки Ул аякларымны тозактан чыгарыр.
16И Ходай, миңа кара һәм мине ярлыка, чөнки мин ялгыз һәм ярлы. 17Күңелемнең кайгылары
күбәйде, йөдәвемнән мине чыгар. 18Юашлыгымны һәм читенлектә торуымны күр, һәм бар
гөнаһларымны кичер. 19Дошманнарым күбәйгәнне күр, һәм мине көнчелек итеп күрәлмыйлар.
21Җанымны сакла һәм мине коткар, Сиңа өмет иткәнемә күрә оятка калмасам иде. 21И Ходай,
Сиңа өмет иткәнемә күрә, явыз түгелләр һәм дөресләр миңа ярделәр. 22И Алла, Исраилне бар
кайгыларыннан коткар.

Егерме бишенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

1И Ходай, мине тикшер, чөнки мин явызлык тотмый йөрдем, һәм Ходайга өметләнгәч алҗымам.
2И Ходай, мине тикшер һәм мине сына, эчемне дә, күңелемне дә эретеп кара. 3Чөнки рәхимең
күзем алдында тора, һәм чынлыгыңда *йөреп* яраулы булдым. 4Бушны уйлаучылар җыенында
утырмадым, һәм кануннан язганнарга керешмәм. 5Яманнар җыенын яратмадым, һәм бозыклар
белән утырмам. 6И Ходай, кулларымны гаепсезләр белән юармын да, һәм корбан урныңны
әйләнермен. 7Сине данлаган тавышны ишетсәм иде, һәм бар могҗизаларыңны да белдерсәм иде.
8И Ходай, өеңнең ямен дә, даның тора торган урынны да сөйдем. 9Җанымны бозык кешеләр
белән, һәм тормышымны кан түгүчеләр белән бергә югалтмасаң иде; 10аларның кулларында
канунсызлык, уң куллары тиешсез бүләк белән тулы. 11Ә мин явызлык тотмый йөрдем: и Ходай,
мине коткар һәм мине ярлыка. 12Аягым турылык юлына басты, и Ходай, җыеннарда Сине
данлармын.

Егерме алтынчы псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. Прежде помазания*

*(Давытның мәдхиясе. Майлау алдыннан).*
[1]Ходай минем яктырткычым һәм коткаручым, мин кемнән куркыйм? Ходай тормышымны
саклаучы, мин кемнән каушыйм? [2]Миңа явызлык итүчеләр һәм мине кысучылар, дошманнарым
тәнемне ашарлык булып, миңа килеп җиткәндә генә, хәлләре бетеп, үзләре егылдылар. [3]Миңа
каршы чиру килсә дә, күңелем курыкмас; миңа каршы сугыш кузгалса да, мин Ходайга ышанам.
[4]Гомеремнең бар көннәрендә дә Ходай өендә торуны, Ходайның матурлыгын күрүне, һәм Аның
изге келәү өенә йөрүне генә Ходайдан сорадым, шуны эзләрмен. [5]Чөнки Ул бәла килгән көнне
мине Үз чатырында яшерде, Үз чатырының яшерен төштә мине саклады, таш тау өстенә мине
күтәреп бастырды. [6]Әле дә менә башымны дошманнарым өстенә күтәрде; Аның келәү
чатырында *корбан урнын* әйләнеп, мактау һәм куану корбанын китердем: Ходайны данлап
җырлармын. [7]И Ходай, инәлгән авазымны ишет, мине ярлыка һәм мине тыңла. [8]Күңелем Сиңа
әйтте: Ходайны эзләрмен. И Ходай, Сине эзләдем, йөзеңне эзләрмен. [9]Йөзеңне миннән борма,
һәм ачуланып бәндәңнән авышып китмә; миңа булышучы бул, мине кире җибәрмә, и Коткаручы
Аллам, мине ташлама. [10]Чөнки атам-анам мине ташладылар, әмма Ходай мине кабул итте. [11]И
Ходай, юлыңда миңа канун куй, һәм дошманнарым сәбәпле мине туры сукмактан йөрт.
[12]Кысучыларым кулына мине тапшырма, чөнки ялган таныкчылар миңа каршы тордылар, һәм
дөрессезлек үзен үзе алдады. [13]Тереләр җирендә Ходай игелекләрен күрермен, дип ышанам.
[14]Ходайга өметлән, йөрәкле бул, күңелең ныгысын, һәм Ходайга өметлән.

Шөкер:

Егерме җиденче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

[1]И Ходай, Сиңа инәлеп дәшәрмен, и Аллам, миңа дәшми калма; кабергә төшерелә торганнарга
охшашлы булмасам иде, миңа бер чакта да дәшми калма. [2]Сиңа инәлгән чакта, изге йортыңа
карап кулларымны күтәргән чакта, и Ходай, инәлүемнең авазын ишет. [3]Гөнаһлылар белән бергә
мине хөкемгә тартма, һәм дөрессезлек кылучылар белән, күңелләрендә яманлык тотып,
якыннарына тынычлык диючеләр белән бергә мине юкка чыгарма. [4]И Ходай, эшләренә карап,
һәм уйлары яманлыгына карап аларга кайтар, кулларының эшләренә карап аларга кайтар, аларга
тиешләрен кайтар. [5]Чөнки алар Ходай эшләренә, һәм Аның куллары кылганга аң салмаганнар:
аларны бөлдерерсең дә торгызмассың. [6]Ходай данлаулы, чөнки Ул инәлүемнең авазын ишеткән.
[7]Ходай – минем булышучым һәм саклаучым, күңелем Аңа өметләнде, Ул миңа булышкач тәнем
дә яшәрде, һәм Аны үз иркемнән сөйләп данлармын. [8]Ходай – Үз халкын ныгытучы, һәм
майлаганын котылдырып саклаучы. [9]Халкыңны сакла, һәм йортыңа бәрәкәт бир, аларга көтүче
булып, гомергә чаклы аларны күтәреп тор.

Егерме сигезенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. На исход скинии*

*(Давытның мәдхиясе. Чатыр чыгару чагында).*

[1]Ходайга китерегез, әй Алла уллары, Ходайга яшь тәкәләр китерегез, Ходайга дан белән кадер
китерегез. [2]Ходайга Аның исеменең данын китерегез, Аның изге йортында Ходайга баш ырыгыз.
[3]Ходай авазы сулар өстендә, данлыклы Алла күкрәде, Ходай күп сулар өстендә *күкрәде*. [4]Ходай
авазы куәтле, Ходай авазы ямьле. [5]Ходай авазы эрбет агачларын ватып ташлый, һәм Ходай
Ливан тавындагы эрбетләрне чәрдәкләп бетерә. [6]Аларны Ливан бозавын *тураклаган* шикелле
тураклап бетерер, ә сөеклесе[3] бер мөгезле киекнең улы кебек. [7]Ходай авазы ут ялкынын аера.
[8]Ходай авазы чүлне тетрәтә, һәм Ходай Кадыш чүлен тетрәтер. [9]Ходай авазы боланнарны
бозаулата, һәм урманнарның яфрагын коя. Һәм Аның йортында һәркем Аның данын әйтә.
[10]Ходай су баскан җирне тотырып тора, һәм Ходай мәңгегә Патша булып утырыр. [11]Ходай Үз
халкына куәт бирер, Ходай Үз халкына тынычлык салыр.

---

[3] Исраил.

Егерме тугызынчы псалом (мәдхия).

[1]*Псалом песни. На обновление дома Давидова*

*(Җыр-мәдхия. Давыт йортын яңартканда).*

[2]И Ходай, Сине олылармын, чөнки Син мине күтәргәнсең һәм дошманнарымны минем турда
куандырмагансың. [3]И Ходай Аллам, Сиңа инәлеп дәштем, һәм Син мине савыктырдың. [4]И
Ходай, җанымны тәмугтан күтәрдең, кабергә төшерелә торганнардан мине аерып сакладың. [5]Әй
Ходай яраулылары, Аңа җырлагыз, һәм изгелеген искә алып сөйләгез. [6]Чөнки ачуында кыен
тора, һәм иркендә терелек тора: кичтән еларлар, һәм иртәгесен сөенерләр. [7]Имин торган чагында
әйткән идем: "Гомергә какшамам: [8]и Ходай, иркеңнән яхшы данымны көчәйт", дигән идем. Син
исә йөзеңне боргач, йөдәп киттем. [9]И Ходай, Сиңа дәшәрмен, һәм Аллама инәлермен. [10]Каным
түгелеп, кабергә төшерелүемнән ни файда? Туфрак Сине сөйләп данлармыни? Я чынлыңны
белдерермени? [11]Ходай ишетеп, мине ярлыкады, Ходай миңа булышучы булды. [12]Елавымны
миңа сөенечкә алмаштырды, кайгы киемемне ертып, билемнән мине куаныч белән буды. Даным
Сине җырласын иде, һәм кайгырмам. И Ходай Аллам, Сине гомергә сөйләп данлармын.

Шөкер:

Утызынчы псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Псалом Давида. При исступлении*

*(Ахырга. Давытның мәдхиясе. Йөдәү билән алганда).*

[2]И Ходай, өметемне Сиңа салдым, гомергә оятка калмасам иде: дөреслегең белән мине
коткарып чыгар. [3]Миңа колагың сал, мине тиз чыгар, мине яклаучы Алла бул, һәм мине
сыендырып сакларга йорт бул. [4]Чөнки ныклаучым һәм сыенганым минем Син, һәм Үз исемең
хакына мине йөртерсең, һәм мине туйдырырсың. [5]Миңа дип яшереп салган тозактан мине
чыгарырсың, чөнки Син Ходай, яклаучым минем; [6]рухымны Синең кулыңа тапшырам. Син
мине коткардың, и Ходай, чынлык Алласы. [7]Буш уйны юкка саклап тотучыларны яратмадың,
мин исә Ходайга өмет иттем. [8]Рәхимле булуыңа сөенеп куанырмын, чөнки юашлыгымны күреп,
җанымны бәлаләрдән саклдың. [9]Һәм дошманнар кулына мине калдырмадың, аякларымны
иркен җиргә бастырдың. [10]И Ходай, мине ярлыка, чөнки бик кайгырам: ачуыңнан күзем, җаным
һәм эчләрем болганыштылар. [11]Чөнки тормышым авыруларда һәм гомерем үксүдә үтеп китте,
кысанлыкта торганлыктан көчем кимеде һәм сөякләрем какшадылар. [12]Бар дошманнарыма,
бигрәк тә күршеләремә көлке булдым, һәм белешләремә куркыныч булдым: мине күрүчеләр
миннән качтылар. [13]Үлгән кеше кебек, кеше күңелендә онытылдым, уалган савыт шикелле
булдым. [14]Чөнки тирәмдә торучыларның күбесенең мине хурлаганнарын ишеттем, аларның
миңа каршы бергә җыелганнарын чакта, җанымны алырга киңәш итештеләр. [15]Әмма мин,
Ходай, өметемне Сиңа салдым: Син минем Аллам, дидем. [16]Шобагам Синең кулыңда:
дошманнарым кулыннан һәм мине куучылардан мине коткар. [17]Үз бәндәңә йөзеңне
яктырылдыр, рәхимең белән мине сакла. [18]И Ходай, Сиңа сыенганыма күрә, оятка калмасам иде,
бозыклар оятка калып, тәмугка төшсеннәр. [19]Гадел кешегә каршы горурланып, аны кимсетеп,
аңа канунга каршыны әйтә торган ялганчы телләр дәшә алмаслык булсыннар. [20]И Ходай,
яхшылыгың ничек кенә күптән күп, аны Үзеңнән куркучыларга саклыйсың, адәм уллары
алдында Үзеңә өмет итүчеләргә әзерләгәнсең. [21]Халык болгануыннан аулагыңда аларны
яшерерсең, карышучан телләрдән бөркәвең белән аларны ябып торырсың. [22]Ныклаган калага
керткән кебек итеп, зур рәхимен күрсәткән Ходай данлаулы. [23]Акылым китеп торганда, күз
алдыңнан куылган икәнмен, дидем. Шуңа күрә Сиңа инәлеп дәшкәч, инәлгән авазымны
ишеттең. [24]Әй Ходайның яраулылары, Аны сөегез, чөнки Ходай чынны сорый һәм
горурлыкларын үтә күрсәтүчеләргә кайтара. [25]Әй Ходайга өмет итүчеләр, барыгыз да йөрәкле
булыгыз, һәм күңелегез нык булсын.

Утыз беренче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. В научение*

*(Давытның мәдхиясе. Нәсыйхәт.).*

[1]Канунсызлыклары кичерелгән һәм гөнаһлары бетерелгән кешеләр бәхетле. [2]Гөнаһын Ходай
кичергән кеше һәм теле белән юмаламаган кеше бәхетле. [3]Көн буе Сиңа ялварганлыктан
сөякләрем искерде, шыпырт булдым. [4]Чөнки кулың көн-төн мине авырайтып тотты; күгән
чәнечкесе җаныма кадалган чакта, кабат газапландым. [5]Канунсызлыгымны тойдым һәм
гөнаһымны яшермәдем, канунсызлыгымны Ходайга әйтеп үкенермен, дидем; һәм Син
күңелемнең бозыгын кичердең. [6]Шуңа күрә кирәкле вакытта Сиңа һәрбер яраулы инәлер,
шунлыктан басарлык ташыган сулар да аңа якын килмәсләр. [7]Мине чолгаган кайгыдан

сыендыручы – Син. И Сөенечем, чорнап алганнардан мине коткар. [8]”Сине акыллыландырырмын
һәм шушы барасы юлыңнан сине өйрәтеп йөртермен, күзләремне синң салырмын”. [9]Акыллары
булмаган ат һәм качыр кебек булмагыз; аларны үзең теләгәнчә йөртсәң, йөгәнен киереп
авызлыклыйсың. [10]Гөнаһлыга кыен күп, Ходайга өмет итүчене исә рәхим чолгар. [11]Әй гаделләр,
Ходайга сөенеп куаныгыз, һәм дөрес күңеллеләр барыгыз да *Аның белән* мактаныгыз.

Шөкер:

4-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 7-нче көйгә.*

Юашланган җанымны килеп күр, и Ходай, гөнаһта бар гомерен үткәргән шул; азгын хатынны кабул иткәнең кебек, мине дә кабул ит, һәм коткар мине.

Бу тормыш диңгезен йөзеп барганда, үземнең күп усал эшләремнең упкынын исемә аламын, һәм уйларымны дөрес алып баручы юк булганда Петернең авазы белән Сиңа дәшәмен: коткар мине, и Мәсих, коткар мине, и Алла, чөнки Син кеше сөюче.

Шөкер: Озакламый инде Мәсихнең туй пулатына керербез, Мәсих Аллабызның бәхетле тавышын барчабыз ишетсәк иде: килегез, әй күктәге данны сөючеләр, акыллы кызлар белән өлештәшләр булып, яктырткычларыбызны иман белән төзәтеп.

Әле дә: Әй җаным, чыгышың элек тәүбәгә кил, гөнаһлыларга хөкем күндерә алмаслык һәм түзәрлек түгел. Күңел йомшаклыгында Ходайга дәшеп әйт: Сиңа гөнаһ кылдым белгән көе дә, белмәгән көе дә, и Юмарт, Алланы Тудырганның догалары хакына юмартлык кылып, коткар мине.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

Сиңа, и Ходай, бердәнбер игелекле һәм исеңдә усаллыкны тотмый торганга гөнаһларымны әйтеп бирәмен, Сиңа егылып, мин тиешсез дәшәмен: гөнаһ кылдым, и Ходай, гөнаһ кылдым, һәм дөрессезлекләрем күплегеннән күккә таба карарга мин лаеклы түгелмен. Тик, и Ходаем, и Ходай, күңел йомшаклыгының күз яшен миңа бүләк ит, бер генә игелекле һәм рәхимле Сине күз яшьләр белән инәлеп күндерә алсам иде, ахырым булганчы һәртөрле гөнаһтан тазарынырга дип. Куркыныч һәм дәһшәтле җирдән үтәсем бар шул, тәнемнән аерылгач, һәм караңгы да адәм төсле түгел җеннәр күплеге мине очратыр; берәү дә булышка, юлдаш булып, минем белән бармас та коткармас. Шуңа күрә Синең игелегеңә егыламын: кимсетүчеләремә мине бирелдермә, һәм дошманнарым минем турда мактанышмасыннар иде, и игелекле Ходай, һәм моны әйтмәсеннәр иде: безнең кулга килде, һәм безгә бирелде. И Ходай, юмартлыкларыңны онытма, һәм канунсызлыкларыма карап миңа кайтарма, һәм йөзеңне миннән борма. Әмма Син, и Ходай, рәхимең һәм юмартлыкларың белән мине акылга керт, дошманым исә минем хакымда сөенмәсен иде; әмма аның миңа янауларын сүрелдер, һәм бар эшен юкка чыгар, һәм Сиңа таба әрләүсез юлны миңа бир, и игелекле Ходай. Чөнки гөнаһ кылган булсам да, бүтән дәвалаучыга килмәдем, һәм ят аллага кулымны сузмадым. Инәлүемне кире чигермә, әмма игелегең белән мине ишет, һәм күңелемне Синнән курку белән беркет. Синең дәүләтең миндә дә булсын иде, и Ходай, шакшы уйларымны ут кебек өтсен иде. Чөнки Син, и Ходай, һәрбер яктыдан да зур якты, һәрбер сөенечтән дә зур сөенеч, һәрбер тынычлыктан да зур тынычлык, чын терелек һәм гомердән гомергә була торган котылу, амин.

## Бишенче кафисма.

Утыз икенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида, не надписанный у евреев*

*(Давытның мәдхиясе. Гыйбриләрдә өстән язып куймаган).*

[1]Әй гаделләр, Ходайга сөенегез, гаделләр мактарга тиеш. [2]Ходайны гөслә белән данлагыз, Аңа
ун кыллы саз белән җырлагыз. [3]Аңа яңа җыру җырлагыз, Аңа көйләп, кычкырып җырлагыз.
[4]Чөнки Ходайның сүзе дөрес һәм бар эшләре дә чын. [5]Ходай рәхимне һәм дөрес тикшерүне сөя,
Ходай рәхименә җир тулы. [6]Ходай сүзе белән күкләр, һәм Аның авыз тыны белән алардагы бар
чирүләр нык беркетелгән. [7]Ул диңгез суларын турсыкка җыйгандай, бер урынга җыйган,
чоңгылдагы суларны хәзинәләргә тутырган. [8]Ходайдан бөтен җир курыксын, Аннан дөньядә
торучылар барысы да калтырасыннар. [9]Чөнки Ул әйткән дә – булганнар, кушкан да

яратылганнар. 10Ходай халыкларның киңәшләрен юкка чыгара, кешеләр уйларын һәм
башлыклар киңәшләрен тарата. 11Ходай киңәше исә гомергә тора, Аның күңелендәге уйлары
тумыштан тумышка бара. 12Алласы Ходай булган халык бәхетле, – Алла Үзенә мирас итеп
сайлап алган кешеләр *бәхетле*. 13Ходай адәм улларын күктән карап, барын да күргән. 14Үзе тора
торган әйбәт урыннан җирдә торучыларның барысына да күз салган. 15Аларның күңелләрен
үзалдына булдырган, бар эшләрен дә белә. 16Патша куәте күплеге белән котылмый, батыр да
көче күплеге белән котылмас. 17Котылырга дип, ат ышанычлы түгел, көче күплеге белән коткара
алмас. 18Менә Ходай күзләрен Үзеннән куркучыларга, Аның рәхименә өмет итүчеләргә сала:
19аларның җаннарын үлемнән коткарыйм һәм ачлык чакта аларны туйдырыйм дип. 20Җаныбыз
исә Ходайга өмет итә, чөнки Ул безнең булышучыбыз һәм яклаучыбыз. 21Күңелебез Аңа сөенер,
һәм Аның изге исеменә өметләндек. 22И Ходай, Сиңа өметләнеп торганыбыз буенча, безгә
Синең рәхимең булсын иде.

Утыз өченче псалом (мәдхия).
1*Псалом Давида, когда он изменил лицо свое пред*
*Авимелехом, и тот отпустил его, и он ушел*
*(Әбумәлик алдында җүләргә салынып, аның хозурыннан куылып*
*китеп барган чакта, Давыт әйткән җыр сүзләре).*
2Һәрбер чакта Ходайны олылап торырмын, авызым белән Аны һаман мактармын. 3Җаным
Ходай исеме белән мактаныр, сабыр кешеләр ишетеп сөенсеннәр. 4Минем белән Ходайны
олылагыз, һәм бергәләшеп Аның исемен күтәрик. 5Мин Ходайны эзләдем, һәм Ул мине ишетте,
булган кайгыларымнан да мине коткарды. 6Аңа якын килегез, һәм яктырылырсыз, йөзләрегез дә
хур булмас. 7Шушы мескен инәлгән, һәм Ходай аны ишеткән, бар кайгыларыннан да аны
коткарган. 8Ходайдан куркучыларны Ходай фәрештәсе әйләнәләреннән ябып торып коткарыр.
9Татыгыз, һәм Ходайның ничек игелекле икәнен күрерсез: Аңа өмет итүче кеше бәхетле. 10Әй
Ходайның изгеләре, барыгыз да Аннан куркып торыгыз, чөнки Аннан куркучылар ярлыга
калмаслар. 11Байлар ярлыланганнар да ачыкканнар, ә Ходайны эзләүчеләр бер яхшылыктан да
буш калмаслар. 12Әй балалар, килегез, мине тыңлагыз, Ходайдан куркырга сезне өйрәтермен.
13Кемнең тере торасы килә, кем яхшы көннәр күрүне сөя? 14Телеңне яманнан һәм авызыңны
юмалап сөйләүдән тый. 15Яманнан читкә кит һәм яхшыны кыл, татулыкны эзлә һәм аны тот.
16Ходайның күзләре гадел кешеләргә *карап торалар*, һәм Аның колаклары – алар догасына.
17Ходай йөзен яманлык кылучыларга каршы тота, аларны искә китерүне җир өстеннән бетерим
дип. 18Гадел кешеләр инәлгәч, Ходай аларны ишеткән һәм бар кайгыларыннан да аларны
коткарган. 19Йөрәкләре кайгырганнарга Ходай якын, һәм күңелләре юашларны саклар. 20Гадел
кешеләрнең кайгылары күп, алай да барысыннан да Ходай аларны коткарыр. 21Ходай аларның
бар сөякләрен саклый, сөякләренең һичберсе дә уалмас. 22Гөнаһлыларның үлүе газаплы, һәм
гадел кешене күрәлмый торучылар ялгышырлар. 23Ходай Үз бәндәләренең җаннарын коткарыр,
һәм Аңа өмет итүчеләр һичберсе дә ялгышмас.

Шөкер:

Утыз дүртенче псалом (мәдхия).
*Псалом Давида*
*(Давытның мәдхиясе).*
1И Ходай, мине рәнҗетүчеләрне хөкем ит, мине җиңәргә торучыларны Үзең җиң. 2Сугыш
коралы белән калкан алып, миңа булышырга тор. 3Кылычыңны чыгарып, мине куучыларга
каршы тор, җаныма әйт: коткаручың синең Мин, диген. 4Җанымны эзләүчеләр оятка калып, хур
булсыннар иде, миңа яманлык уйлаучылар оялып, кире чиксеннәр иде. 5Җил өреп җибәргән
тузан кебек булсыннар иде, һәм Ходай фәрештәсе аларны кысрыкласын иде. 6Аларның юллары
караңгы һәм тайгак булсын, һәм Ходай фәрештәсе аларны куып барсын. 7Чөнки гаепсез көе
мине харап итәргә, яшертен тозакларын салдылар, җанымны гаебе юк көе хурладылар.
8Һәркайсысы белмәгән көе тозакка туры килсен иде, һәм яшерен куйган капкыны үзен капсын
иде, тозагына үзе эләксен иде. 9Җаным исә Ходайга сөенер, Аның саклавына куаныр. 10Бар
сөякләрем дә әйтерләр: и Ходай, и Ходай, Сиңа кем охшаулы? Көчсезне аннан көчлеләрдән һәм
ярлыны да, мескенне дә кысучыларыннан коткарасың. 11Ялган таныкчылар миңа тотынып,
миннән мин белмәгәнне сорап тордылар. 12Минем яхшылыгыма яманлык кайтардылар һәм бала-

чагасыз булсын, диделәр. [13]Мин исә, алар мине йөдәткән чагында, тузган кием киеп һәм ураза
тотып, җанымны юашландырдым, һәм кылган догам үземә кайтты. [14]Аларга, якыныма, агай-
энемә ярарга тырышкан кебек, ярарга тырыштым; елаучы һәм кайгыручы шикелле, моңаеп
йөрдем. [15]Һәм җыелышып, мин моңайганга куаныштылар, мине яраларга җыелыштылар, ни
өчен икәнен белмәдем; өер-өер тордылар һәм күңелләрен йомшатмадылар. [16]Мине сынадылар,
үртәли-үртәли тордылар, миңа тешләрен шыкырдаттылар. [17]И Ходай, моны кайчан күрерсең?
Җанымны аларның усаллык итүеннән, ялгыз җанымны арысланнардан ерак тот. [18]Зур җыенда
Сине сөйләп белдерермен, олы кешеләр арасында Сине мактармын. [19]Миңа тиешсез дошманлык
итүчеләр, мине гаепсез көе күрәлмый торучылар һәм күз кысышучылар, минем сәбәпле
сөенешмәсеннәр иде. [20]Чөнки үземә: тынычлык сиңа, дисәләр дә, әмма юмалый-юмалый
явызлык итәргә исәпләштеләр. [21]Миңа авызларын җәеп, әйттеләр: “Яхшы, яхшы, күзләребез
күрделәр”, дип. [22]И Ходай, моны күрдең, дәшми калма; и Ходай, миннән читкә китмә. [23]И
Ходай, тор, һәм хөкемемә аң сал, и Аллам һәм Ходаем, дәгъвамны күр. [24]И Ходай, дөреслегең
белән мине хөкем ит, и Ходай  Аллам, алар минем сәбәпле сөенешмәсеннәр иде. [25]Үз
күңелләрендә: “Яхшы, яхшы, җаныбыз теләгәнчә булды”, димәсеннәр иде. “Аны ашап
бетердек”, димәсеннәр иде. [26]Минем бәлаләремә сөенүчеләр бергәләшеп оятка калып, хур
булсыннар; алдымда мактанышучылар оятка һәм хурлыкка киенсеннәр иде. [27]Минем дөрескә
чыгуымны теләүчеләр сөенеп куанышсыннар иде, һәм Ходай бәндәсенә тынычлык теләүчеләр:
“Ходай зурлансын” дип, һаман әйтсеннәр иде. [28]Һәм телем Синең дөреслегеңә өйрәнер, көн буе
Сине мактарга *өйрәнер*.

Утыз бишенче псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Отрока Господня Давида*
*(Ахырга. Ходай колы Давытныкы).*
[2]Канунга карышучы үз эчендә гөнаһ кылырга уйлый: Алладан куркуны күзләре алдында
тотмый. [3]Ул канунсызлыгын тоенып, аны яратмас буласы булып, Алла алдында юмалый.
[4]Авызындагы сүзләре канунсызлык белән юмачылык: акылга килеп, яхшылык кыласы килмәгән.
[5]Яткан урнында канунсызлык итүне уйлаган, һәрбер эшәке юлга баскан, усаллыктан
җирәнмәгән. [6]И Ходай, рәхимең күкләргә чаклы, һәм чынлыгың болытларга чаклы. [7]Дөреслегең
– Алла тауларыдай, хөкемнәрең – чиксез күп: и Ходай, кешеләрне дә, туарларны да саклыйсың.
[8]И Алла, рәхимеңне күбәйттең: адәм уллары исә канатларың астына ышыкланырга өмет итәләр.
[9]Өеңнең байлыгыннан туенырлар, һәм тәмлелек чишмәңнән аларны эчертерсең. [10]Чөнки терелек
чишмәсе Синдә, Синең яктыңда яктыны курербез. [11]Сине белүчеләргә рәхимеңне һәм туры
күңеллеләргә дөреслегеңне озаклат. [12]Горурның аягы мине басмасын иде, һәм гөнаһлының
кулы мине какшатмасын иде. [13]Анда канунсызлык кылучылар барысы да егылдылар, аларны
түбән ыргыттылар, һәм тора алмыйлар.

Шөкер:

Утыз алтынчы псалом (мәдхия).
*Псалом Давида*
*(Давытның мәдхиясе).*
[1]Яманлык итүчеләргә охшарга тырышма, канунсызлык кылучыларга көнчелегең килмәсен.
[2]Чөнки үлән кебек тиз корырлар, һәм яшел үләндәй шиңеп төшәрләр. [3]Ходайга өмет итеп,
яхшылык кыл, җирдә урнаш, һәм аның байлыгыннан тукланырсың. [4]Ходайга кинәнеп тор, һәм
Ул сиңа күңелең теләгәнне бирер. [5]Юлыңны Ходайга күрсәтеп тор һәм Аңа өметлән, һәм Ул
булдырып җиткезер. [6]Дөреслегеңне яктыдай һәм тормышыңны көн уртасыдай ачык күрсәтер.
[7]Ходайга баш сал һәм Аннан үтен; кануннан язучы кешенең тормышы алга киткәнгә көнчелегең
килмәсен. [8]Ачуыңнан тыел һәм ярсуыңны ташла, яманлык итәргә тырышма. [9]Чөнки яманлык
итүчеләр юкка чыгарлар, Ходайга өмет итүчеләргә исә җир тияр. [10]Тагы бераздан гөнаһлы юкка
чыгар: һәм урнын эзләрсең, тик таба алмассың. [11]Сабырлыклыларга исә җир тияр һәм күп
тынычлыкта рәхәтләнерләр. [12]Гөнаһлы кеше гадел кешене сагалап, аңа тешләрен шыкырдата.
[13]Ходай исә гөнаһлыны хур итәр, чөнки көне килерен алдан күреп тора. [14]Мескенне һәм ярлыны
егар өчен, дөрес күңеллеләрне чәнчер өчен, гөнаһлылар кылычларын кынысыннан чыгардылар,
җәяләрен кордылар. [15]Кылычлары үз йөрәкләренә кадалсын, һәм җәяләре дә сынып бетсеннәр.
[16]Гадел кешенең аз гына малы да гөнаһлыларның күп байлыгыннан артык. [17]Чөнки

гөнаһлыларның сеңерләре өзелерләр, ә гаделләрне Ходай ныгыта. [18]Ходай шиксезләрнең
юлларын беләдер, һәм аларның өлеше гомергә торыр. [19]Читенлек килгән чакта гаделләр оятка
калмаслар һәм ачлык көннәрдә дә тукланырлар, әмма гөнаһлылар югалырлар. [20]Ходайның
дошманнары мактанышкан һәм күтәрелешкән чакларында ук, төтен таралгандай таралалар.
[21]Гөнаһлы кеше әҗәткә алгач түләми, ә гадел кеше юмартланып түли. [22]Чөнки гадел кешегә
игелек теләүчеләргә җир тияр, аны каргаучылар исә югалып бетәрләр. [23]Кешенең аякларын
Ходай төзек йөртә, һәм аның йөрешләрен бик яратыр. [24]Егылганда имгәнмәс, чөнки кулыннан
Ходай тота. [25]Яшь кенә идем, менә инде картайдым, һәм гадел кеше ташланылганны, нәселе
икмәк соранып йөргәнне күрмәдем. [26]Гадел кеше көн саен игелек итә, әҗәткә дә бирә, һәм
нәселе кадерле булыр. [27]Яманнан читкә кит, һәм яхшыны кыл, һәм гомердән гомергә тор.
[28]Чөнки Ходай турылыкны сөя, һәм Үзенә яраулыларны ташламас, гомергә саклаулы булырлар,
канунсызлар исә куылырлар, һәм бозыкларның нәселе кырылып бетәр. [29]Гаделләргә исә җир
тияр һәм шунда гомердән гомергә урнашырлар. [30]Гаделнең авызы хикмәткә өйрәнер, һәм теле
чынны сөйләр. [31]Алласының кануны аның күңелендә, һәм аяклары сөртенмәс. [32]Гөнаһлы кеше
гаделне сагалап йөри һәм аны үтерергә эзли, [33]Ходай исә аны аның кулына калдырмас, хөкем
иткән чагында да аны гаепләмәс. [34]Ходайга өмет ит һәм Аның юлыннан йөр, һәм сиңа җир
тидерер өчен сине күтәрер, гөнаһлылар югалып беткәнне күрерсең. [35]Бозык кешенең
мактанганын, Ливан тавындагы эрбет агачларыдай күтәрелгәнен күрдем: [36]янынннан үтәр идем,
ул инде юк та, аны эзләдем, урыны да табылмады. [37]Усал булма һәм турылыкны күр, чөнки юаш
кешенең алда өмете бар. [38]Канунсызлар исә бөтенләй бетәрләр, бозыкларның калганнары да
бетәрләр. [39]Гаделләрне исә Ходай саклый һәм кайгылы чакларында аларны яклый. [40]Ходай
аларга булышыр һәм аларны коткарыр, гөнаһлылар арасыннан алып, аларны саклар, чөнки алар
Аңа өмет иттеләр.

Шөкер:

5-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 5-нче көйгә.*

Синең куркыныч тәхетең, минем яман тормышым, һәм теге чактагы бәладән кем мине аралап алыр, әгәр Син мине ярлыкамасаң, и Мәсих Алла, Үзең юмарт һәм кеше сөючегә күрә.

Шөкер: Тормыштагы кайгыру оҗмахтан мине куып чыгарды, һәм өметем өзелгәч, ни эшлим? Шуңа күрә капкага шакып дәшәмен: и Ходай, и Ходай, тәүбә белән миңа ач, һәм коткар мине.

Әле дә: Синең йортыңны, и Алланы Тудырган Кыз, ничек дип атыйк? Рухыбыз белән сыена торган җир дипме? Я бетми торган тормышны табып бирүче, күктәге рәхәтнең оҗмахы дипме? Бар яхшылыклар Синдә бар шул. Җаннарыбыз коткарыр өчен, Мәсихкә һаман инәлә күр.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И гадел һәм мактаулы Алла, и олы һәм куәтле Алла, и мәңге Алла, гөнаһлы ирнең догасын шушы сәгаттә ишет. Чынлыкта Сиңа инәлеп дәшүчеләрне ишетергә вәгъдә иткән Алла, ишет мине. Шакшы авызлы һәм гөнаһлар эчендә торучы мине бигрәк тә шакшыландырма, и җирнең һәрбер читендә торучыларның һәм чит җирләрдә йөрүчеләрнең Ышанганы. Сугыш коралы белән калкан алып, миңа да булышырга тор, кылыч чыгар һәм мине куучыларга каршы тор. Шакшы рухларга мин акылсызның җаныннан китәргә кисәтеп куш. Уемнан да нәфрәт һәм усаллыкны истә тоту рухы китсен иде, тагын да көнчелек һәм алдау рухы, курку һәм моңаю рухы, горурлык һәм һәртөрле бүтән явызлыкның рухы китсен иде; тәнемнең дә шайтаннан килә торган һәртөрле кызуы һәм кузгалуы басылсын иде; җаным да, тәнем дә, рухым да Алладан килә торган танып белү яктылыгы белән яктырылсын иде. Синең күп юмартлыкларың белән иман тоташтыруына, камил иргә, яше җиткән чамасына җитсәм иде. Фәрештәләр һәм бар изгеләрең белән Синең иң кадерле һәм иң олы исемеңне, Атаны, һәм Улны, һәм Изге Рухны җырлап данласам иде, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

## Алтынчы кафисма.

Утыз җиденче псалом (мәдхия).

[1]*Псалом Давида. В воспоминание. На субботу*

*(Давытның мәдхиясе. Искә төшерү өчен. Шимбә көнне).*

2И Ходай, ачуың белән мине гаепләмәсәң иде, ярсып миңа кыен күрсәтмәсәң иде. 3Чөнки
укларың миңа кадалганнар, һәм кулың өстемә авыр баскан. 4Ачуыңнан тәнем төзәлми,
гөнаһларым күплегеннән сөякләрем тынычланмый. 5Чөнки гөнаһларым башымнан ук
капладылар, авыр күтәрәм шикелле мине авырайттылар. 6Акылсызлыгымнан яраларым череп
сасыландылар. 7Газапланып бөтенләй бөкрәйдем, көн буе моңаеп йөрдем. 8Чөнки эчем чир
белән тулган, һәм тәнем дә төзәлә алмый. 9Яманлык күреп, бик кимгә калдым, йөрәгем
кайгырганлыктан үкереп тордым. 10И Ходай, теләгәнем бар да Синең алдыңда, һәм кайгыруым
да Сиңа яшерен түгел. 11Йөрәгем каушады, хәллем китте, һәм күзләрем алдында якты да бетте.
12Дус-ишләрем якын килеп, каршымда тордылар. 13Һәм якыннарым миннән еракта тордылар;
җанымны эзләп йөрүчеләр мине кыстылар, миңа усаллык теләүчеләр бушны сөйләделәр һәм көн
саен явызлык итәргә уйладылар. 14Мин исә саңгырау шикелле ишетмәгән булып тордым, һәм
телсез шикелле дәшми тордым. 15Ишетми торган һәм җавап бирә алмый торган кеше кебек
булып тордым. 16Чөнки Сиңа Ходай өметләндем, и Ходай Аллам, Син ишетерсең. 17Чөнки мин
әйттем: “Дошманнарым минем сәбәпле сөенешмәсеннәр иде”, дидем: аякларым какшаган
чагында үзләрен эре тоттылар. 18Мин яраланырга әзер, һәм газабым һаман алдымда. 19Чөнки
кануннан язганымны әйтеп күрсәтермен һәм гөнаһым өчен көенермен. 20Дошманнарым исә тере
һәм миннән бигрәк ныгыдылар, һәм мине тиешсез көе күрәлмый торганнары күбәйделәр.
21Миңа яхшылыгым өчен яманлык кайтаручылар, яхшы эшкә тырышканым өчен өстемнән
ялганладылар. 22И Ходай Аллам, мине ташлама, миннән бизмә. 23И мине саклаучы Ходай, миңа
булышуны аңыңда тот.

Утыз сигезенче псалом (мәдхия).
1*В конец. Идифуму. Песнь Давида*
*(Ахырга. Едутун өчен. Давытның җыры).*

2Мин әйттем: телем белән гөнаһ кылмас өчен юлларымнан язмам, дип; гөнаһлы кеше алдымда
карышып торган чагында, авызымны тыеп тордым. 3Юашланып һәм телсезләнеп тордым,
яхшылык хакына дәшми тордым, һәм авыртуым яңарды. 4Эчемдә йөрәгем ялкынланды, һәм
исәп тотканда ут янып торды; телем белән әйттем: 5и Ходай, кайчан үләсемне әйт, һәм көннәрем
исәбе ни хәтле икән, тагы ни хәтле торасымны белсәм иде. 6Менә көннәремне сөямләп[4] кенә
куйгансың, Синекеңә караганда минем торуым юк кына. Чынлап та, бар да мәшәкать, һәрбер
кешенең торуы мәшәкать кенә. 7Чынлап, кеше күләгәдәй йөри, юкка гына мәшәкатьләнә: мал
җыя, һәм кем өчен җыйганын белми. 8Әле дә өметләнгәнем кем? Ходай түгелме? Һәм мине
тотучы Син. 9Кануннан язганнарымның барысыннан мине коткар: мине мыскыл итәргә
акылсызга ирек бирдең. 10Бу Синнән булганга күрә, авызым ачмый телсезләнеп тордым.
11Кыеныңны миннән читкә ал, кулың авырлыгыннан югалып беттем шул. 12Кешене кануннан
язганлыгы өчен оялтып, аңа кыен тидердең, һәм җанын тоҗым кебек нечкәрттең: чынлап,
һәрбер кеше юк нәрсә. 13И Ходай, догамны ишет, һәм инәлгәнемә колагың сал, күз яшьләремә
дәшми калма, чөнки мин Синдә читтән килгән кеше кебек, бар аталарым шикелле читтән килеп
торучы. 14Мине бушайт, үлеп китеп юк булганчы, тынычлансам иде.

---

[4] Сөям – озынлык үлчәве, якынча 18 см.

Утыз тугызынчы псалом (мәдхия).
1*В конец. Псалом Давида*
*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

2Ходайга бик нык өмет иттем, һәм Ул миңа аң салды, инәлгәнемне ишетте. 3Котчыгаргыч баздан
һәм баткак саздан мине чыгарды, һәм аякларымны таш өстенә торгызды, һәм атлауларымны
юнәлтеп җибәрде. 4Һәм Аллабызга җырлый торган яңа җыруны авызыма салды: күбесе күреп
куркырлар һәм Ходайга өметләнерләр. 5Ходай исеменә өметләнгән һәм бушка да, ялган
котырыкка да күз салмаган кеше бәхетле. 6И Ходай Аллам, Син күп могҗизалар кылгансың, һәм
Син уйлаганча уйлардай берәү дә юк; белдердем һәм сөйләдем, аларның саны исәптән тышкары
күбәйгән. 7Корбанны һәм бүләкне теләмәдең, миңа тән әзерләдең, тулаем яндыру корбанын һәм
гөнаһ өчен *корбанын* сорамадың. 8Шул чакта әйттем: менә барам дип, язмада минем турда

язылган. [9]И Аллам, Синең иркеңне кылуны теләдем, һәм кануның минем эчемдә. [10]Зур җыен
эчендә дөресеңне сөйләдем; менә телемә каршылык итмәм. И Ходай, Үзеңә билгеле.
[11]Дөресеңне күңелемдә яшереп тотмадым, чыныңны һәм коткаруыңны әйттем, рәхимеңне һәм
чыныңны зур җыеннан яшермәдем. [12]Син исә Ходай, юмартлыгыңны миннән алма, рәхимең һәм
чының һаман мине якласыннар иде. [13]Чөнки исәпсез бәла-каза мине чорнап алды, кануннан
язганнарым мине чолгап алдылар, һәм күзләрем карый алмады; башымдагы чәчләремнән дә
бигрәк күбәйделәр, һәм йөрәгем мине калдырды. [14]И Ходай, мине коткарырга күңел ит, и Ходай,
миңа булышырга ашык. [15]Җанымны алырга эзләүчеләр барысы да оятка һәм хурлыкка
калсыннар, миңа усаллык теләүчеләр оятка калып, кире чиксеннәр. [16]Миңа *мыскыллап*: яхшы,
яхшы ди торганнары оятлы булсыннар. [17]И Ходай, Сине эзләүчеләр бар да Сиңа сөенешеп
куанышсыннар, һәм Синең саклавыңны сөючеләр һаман әйтсеннәр: Ходай данлансын, дип.
[18]Мин исә ярлы һәм мескен, минем өчен Ходай кайгырыр. Миңа булышучы һәм мине саклаучы
Син, и Аллам, озаклама.

Шөкер:

Кырыгынчы псалом (мәдхия).

*[1]В конец. Псалом Давида*

*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

[2]Ярлы һәм мескен өчен кайгыртучы бәхетле, кыен көнне Ходай аны коткарыр. [3]Ходай аны
сакласын, һәм аны тере тотсын, аны җирдә бәхетле итсен, һәм аны дошманнары кулына
төшермәсен. [4]Чирләп яткан урнында Ходай аңа хәл бирер, чирләп яткан урнында аны саугa
әйләндерер. [5]Мин әйттем: и Ходай, мине ярлыка, җанымны савыктыр, чөнки Синең алда гөнаһ
кылдым, дип. [6]Дошманнарым минем турыда яман әйттеләр: “Ул үлеп, исеме кайчан юкка чыгар
икән?”, диделәр. [7]Мине күрергә дип, кергәне юкны сөйләде: күңеле эчендә дөрессезлекне
уйлады, аннары тышка чыгып, киңәшләште. [8]Дошманнарым бар да минем турда
пышылдаштылар, миңа усаллык итәргә уйладылар. [9]Миңа канунга каршы сүз әйттеләр: “Әллә
ул яткач торыр микән?”, диделәр. [10]Чөнки минем белән тату торган, ышанган кешем, икмәгемне
ашаган кеше, ул да мине абындырырга дип үкчәсен күтәрде. [11]Син исә Ходай, мине ярлыка һәм
мине торгыз, һәм аларга кайтарырмын. [12]Дошманым минем турда сөенмәсә, шуннан Синең мине
ратканыңны белермен. [13]Усал булмаганыма күрә, Син мине кабул итеп, Үз алдыңда гомергә
ныкладың. [14]Исраил Алласы Ходай гомердән гомергә данлаулы, амин, амин.

Кырык беренче псалом (мәдхия).

*[1]В конец. В научение. Сынам Кореевым. Псалом Давида.*

*(Ахырга. Нәсыйхәт. Корах уллары өчен. Давытның мәдхиясе).*

[2]Болан чишмә суына барасы килгән кебек, и Алла, җаным Сиңа барырга атлыгып тора. [3]Җаным
куәтле, тере Аллага сусап тора: Алла алдына кайчан гына барып күренермен? [4]Көн саен миңа:
“Аллаң кая синең?”, дигән чакларда, көн-төн күз яшьләрем миңа икмәк урнына булдылар.
[5]Искитәрлек урынга, Алла өенә сөенеч авазы белән, бәйрәм тавышы белән данлап керәсемне
исемә төшереп уйлагач, җаным эреп китте. [6]Әй җаным, ник кайгырасың? Һәм ник эчемне
пошырасың? Аллага өмет ит, чөнки Аны коткаручым һәм Аллам дип, данлармын. [7]Эчемдә
җаным моңаеп китте, шуңа күрә Сине Үрдүн җиреннән һәм Хәрмун тавыннан, кечкенә таудан
исемә төшерермен. [8]Шарлавыкларыңның авазында бер упкын икенчене чакыра: бар биек
дулкыннарың минем өстемнән үттеләр. [9]Көндез Ходай рәхимен күрсәтер, һәм төнлә Аңа
җырлармын, тере тотучы Аллама дога китерермен. [10]Аллага әйтермен: яклаучым минем, ник
мине оныттың? Һәм дошманнар рәнҗеткәндә ник моңаеп йөрим? [11]Сөякләрем уалып торганда,
дошманнарым: “Аллаң кая синең?” дип, көн саен мине мыскылладылар. [12]Әй җаным, ник
кайгырасың? Һәм ник эчемне пошырасың? Аллага өмет ит, чөнки Аны коткаручым һәм Аллам
дип, данлармын.

Кырык икенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. Не надписанный у евреев*

*(Давытның мәдхиясе. Гыйбриләрдә өстән язып куймаган).*

[1]И Алла, мине хөкем ит, яраусыз халык белән тартышуымны тикшер; ялганчы һәм юмалаучы
кешедән мине коткар. [2]Чөнки Син, Алла, мине ныклаучы. Ник мине борып җибәрдең? Һәм

дошманнарым рәнҗеткән чакта, ник моңаеп йөрим? [3]Яктыңны һәм чыныңны җибәр: алар мине
йөртеп изге тавыңа һәм йортыңа алып керерләр. [4]Һәм Алланың корбан урнына, яшьлегемне
сөендерүче Аллама якынлашырмын. И Алла, и Аллам, гөслә белән Сине данлармын! [5]Әй
җаным, ник кайгырасың? Һәм ник эчемне пошырасың? Аллага өмет ит, чөнки Аны коткаручым
һәм Аллам дип, данлармын.

Шөкер:

Кырык өченче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Сынам Кореевым. В научение*

*(Ахырга. Корах уллары өчен. Нәсыйхәт).*

[2]И Алла, әүвәле заманда, аталарыбыз көннәрендә, Син кылган эшне колагыбыз белән ишеттек,
аталарыбыз да безгә белдерделәр. [3]Синең кулың халыкларны бетереп, аталарыбызны
урнаштырган: ят халыкларны, кыен тидереп, куып чыгарган. [4]Чөнки аталарыбыз җирне үз
кылычлары белән алмаганнар һәм аларны үз көчләре коткармаган, әмма Синең кулың, һәм
Синең куәтең, һәм йөзеңнең яктысы *коткарган*, чөнки аларга ризалык иткәнсең. [5]Син Үзең
минем Патшам һәм минем Аллам, Ягъкубка котылу бирүче. [6]Синең белән дошманнарыбызны
җиңәрбез, һәм безгә карышучыларны исемең белән юкка чыгарырбыз. [7]Чөнки мин җәямә
ышанмыйм, һәм кылычым мине сакламас. [8]Чөнки кысучыларыбыздан безне Син сакладың һәм
безне күрәлмый торганнарны хур иттең. [9]Көн саен Алланы әйтеп мактанырбыз һәм Синең
исемеңне гомергә сөйләрбез. [10]Хәзер инде безне борып җибәрдең һәм хурлыкка калдырдың, и
Алла, чирүләребез белән дә чыкмыйсың. [11]Дошманнарыбыз алдында безне кире чигердең, һәм
безне күрәлмый торучылар безне таладылар. [12]Сарыкларны ашарга биргән кебек, безне итеп
бирдең һәм ят халыклар арасына безне тараттың. [13]Үз халкыңны бәясез бирдең, һәм сөенешеп
тавыш күтәрергә күп булмадык. [14]Күршеләребезгә безне мыскылга куйдың, әйләнебездә
торучыларга үртәләүгә һәм көлкегә калдырдың. [15]Ят халыклар арасында бездән мәсәл кылдың,
кешеләр безгә башларын чайкыйлар. [16]Көн саен хурлыгым күз алдымда, һәм йөземне оят
каплады, [17]хурлаучы һәм әләкченең тавышыннан, дошман һәм куучының йөзеннән. [18]Болар бар
да безгә килде, алай да Сине онытмадык һәм васыятеңне бозмадык. [19]Күңелебез дә Синнән
бизмәде, эзләребезне юлыңнан авыштырган булсаң да: [20]чөнки яманлык күргән җиребездә безне
юашландырдың һәм әҗәл күләгәсе безне каплады. [21]Әгәр Аллабызның исемен онытып, ят
аллага кулларыбызны күтәргән булсак, [22]боларны Алла сорамасмыни? Ул күңелдәге яшеренне
белә ләбаса. [23]Әмма Синең өчен көн саен үтереләбез, суясы сарыкларга тиңләшкәнбез. [24]И
Ходай, тор, ник йоклыйсың? Тор, бөтенләй үк ташлама. [25]Йөзеңне ник борасың?
Ярлылыгыбызны һәм кайгыбызны ник онытасың? [26]Чөнки җаныбыз тузан кебек кечеләнде,
эчебез җиргә ябышты. [27]И Ходай, тор! Безгә булыш һәм исемең хакына безне коткар.

Кырык дүртенче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Об имеющихся измениться. Сынам Кореевым.*

*В научение. Песнь о Возлюбленном*

*(Ахырга. Үзгәрәселәр хакында. Корах уллары өчен.*

*Нәсыйхәт. Сөйгән Яр турында җыр).*

[2]Күңелем яхшы сүз чыгара, эшләремне Патшага билгеле итәм: телем тиз язучы китапчының
камышы кебек. [3]Синең матурлыгың бар адәм улларыныкыннан да матуррак, авызыңнан дәүләт
аккан, шуңа күрә Алла Сине гомергә данландырган. [4]И куәтле, кылычыңны янбашыңа бәйлә,
[5]матурлыгыңны һәм әйбәтлегеңне *бәйлә*, көчән дә өлгер бул, чынлык та, сабырлык та, дөреслек
тә хакына патшалык ит; һәм уң кулың Сине искитәрлек йөртер. [6]И куәтле, Синең укларың бик
очлы, алар Патша дошманнарының йөрәкләренә *кадалырлар*, халыклар аяк астыңа егылырлар.
[7]И Алла, тәхетең гомердән гомергә. Патшалыгыңның таягы – дөреслек таягы. [8]Син дөреслекне
сөйгәнсең һәм канунсызлыкны күрәлмагансың, шуңа күрә, и Алла, Аллаң Сине сөенеч мае
белән өлештәшләреңнән артык майлаган. [9]Киемнәреңнән смирна һәм стакти, һәм кассия *исләре
кебек, хуш исләр аңкый*, фил сөякләрдән *эшләнгән* өйләрдән Сине сөендерәләр. [10]Патша кызлары
– кадереңдә, алтынлап, чуарлап бетергән киемнәр киеп, Кыз Патша уң ягыңда торган. [11]Әй Кыз,
ишет, һәм күр, һәм колагыңны сал, халкыңны да, атаң йортын да оныт. [12]Һәм Патша
матурлыгыңны теләр, чөнки Ул Синең Ходаең, һәм Аңа баш ырырсың. [13]Тур кызы бүләкләр
белән: халыкның байлары Синең йөзеңә инәлерләр. [14]Патша Кызының бар олылыгы үз эчендә;

Ул алтын чәчәк чуарлап матурлаган кием кигән. [15]Аның артыннан Патшага кызлар
китерелерләр, Аның иптәшләре Сиңа китерелерләр. [16]Сөенеч һәм куаныч белән Патша йортына
кертелерләр. [17]Аталарың урнына улларың булыр: аларны бөтен җиргә башлыклар итеп куярсың.
[18]Исемеңне тумыштан тумышка исемдә тотармын, шуңа күрә халыклар Сине гомердән гомергә
данларлар.

Кырык бишенче псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Чрез сынов Кореовых. О тайнах. Псалом*
*(Ахырга. Корах уллары өчен. Серләр турында. Мәдхия).*
[2]Алла – безнең сыенычыбыз һәм куәтебез, авыр кайгы килгән чакта булышучыбыз.
[3]Шунлыктан, җир тетрәп, таулар диңгез уртасына кузгалсалар да, курыкмабыз. [4]Аларның
сулары шаулап күтәрелгәннәр, Аның куәтеннән таулар калтыраганнар. [5]Инеш агымнары Алла
каласына сөенеч китерәләр: Югарыдагы Үзе тора торган урнын изгеләндергән. [6]Алла аның
уртасында, һәм ул кала какшамас: Алла аңа иртәдән үк булышыр. [7]Халыклар болганыштылар,
патшалыклар кузгалыштылар, Югарыдагы тавышын бирде: җир тетрәде. [8]Чирүләр Ходае безнең
белән, яклаучыбыз – Ягъкуб Алласы. [9]Килегез, Ходай эшләрен, Аның җирдә кылган
могҗизаларын күрегез: [10]җир читеннән сугышларны туктатып, җәяне ватыр, һәм сөңгене
сындырыр, һәм калканнарны ут белән яндырыр. [11]Тынычланыгыз һәм Алла Мин икәнне белегез:
халыклар арасында күтәрелермен, җирдә күтәрелермен. [12]Чирүләр Ходае безнең белән,
яклаучыбыз – Ягъкуб  Алласы.

Шөкер:

6-нчы кафисмадан соң,
Өч изгелек.
*Тропарьләр: 3-нче көйгә.*

Мактау Сиңа китерәмен, и Ходай, гөнаһларымның барысын да Сиңа белдерәмен, и Алла, Үзеңә кайтарып, мине ярлыка.

Шөкер: Бер вакытта салым җыючыны коткарганың кебек, и Аллам, мине дә коткар, һәм азгын хатынның күз яшен кире чигермәгәнең кебек, минем дә эчтән сулавымны кабул ит, и Коткаручым, һәм коткар мине.

Әле дә: Колларча Синең бөркәвеңә хәзер килеп сыенамын, и бозылусыз таза Кыз, нәфесләргә батып бетүдән мине аралап ал, и Алланы Тудырган Кыз, чөнки Син нәфесләрне Бетерүчене тудыргансың.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

Сиңа шөкер итәбез, и Ходай Аллабыз, безгә кылган бар яхшылыкларың өчен: беренче үсә башлаган чактан ук хәзергә чаклы ук без тиешсезләргә булганнары өчен; аларны без белгәнбез я белмәгәнбез, алар күренгән я күренмәгән булганнар, эшең белән я сүзең белән булганнары барысы да өчен Сиңа шөкер итәбез. Безгә мәхәббәтең сәбәпле бердәнбер туган Улыңны безнең өчен бирергә ризалык иткәнсең, инде мәхәббәтеңә яраулы булырга безне дә тиешле ит. Үз сүзең белән хикмәт бир, һәм Үзеңнән курку белән куәтеңнән безгә ныклык җибәр. Әгәр кыласыбыз килеп, я килмичә гөнаһ кылган булсак та, кичер, һәм гаепкә куйма, җаныбызны да изге итеп сакла; вөҗданы саф килеш һәм ахыры Синең кеше яратуыңа лаеклы килеш җаныбызны тәхетең каршысына китер. И Ходай, чынлыкта Сиңа инәлеп дәшүчеләрнең барысын да исеңә ал, безгә яхшылык я яхшылык түгелне теләүчеләрне дә исеңә ал, барыбыз да без кешеләр шул, һәм һәрбер кеше буш нәрсә. Шуңа күрә, и Ходай, Сиңа инәләбез: Синең игелекле күңеллелегеңнең зур рәхимен безгә бир.

**Җиденче кафисма.**

Кырык алтынчы псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Чрез сынов Кореевых. Псалом*
*(Ахырга. Корах уллары өчен. Мәдхия).*
[2]Бар халыклар да кул чабып, Аллага сөенеч авазы белән кычкырыгыз. [3]Чөнки Югарыдагы Ходай
– куркыныч, бөтен җиргә олуг Патша. [4]Халыкларны безгә буйсындырды, һәм кавемнәрне
аягыбыз астына салды. [5]Үз өлеше, Үзе сөйгән Ягъкубның ямен безгә бирде. [6]Алла сөенеп

кычкырган авазлар эчендә күтәрелде, Ходай быргы авазында *күтәрелде*. 7Җырлагыз Аллабызга,
җырлагыз! Җырлагыз Патшабызга, җырлагыз! 8Алла бөтен җиргә Патша икәненә күрә, барыгыз
да аңлап җырлагыз! 9Алла халыкларга Патша булды, Алла Үзенең изге тәхетендә утырып тора.
10Халык башлыклары Ибраһим Алласының алдына җыелдылар, чөнки Алла сайлаганнар җирдә
бик данландылар.

Кырык җиденче псалом (мәдхия).

1*Псалом песни. Сынам Кореевым. На второй (день) недели*

*(Җыр-мәдхия. Корах уллары өчен. Дүшәмбе көнне).*

2Ходай олы һәм Аллабызның каласында, Аның, бөтен җиргә төп сөенеч булган, изге тавында Ул
бик данлаулы. 3Бу Сион таулары олуг Патша каласының төн ягында. 4Алла ул каланы яклап,
шундагы зур өйдәгеләргә Үзен белдерә. 5Чөнки менә җир патшалары җыелып, бер җиргә
килгәннәр. 6Шуны күреп, аларның исләре киткән, каушаганнар, рәтләре беткән. 7Алар
калтырашканнар: анда бала тудыручы кебек газапланганнар. 8Давыллы җил белән Син Таршиш
көймәләрен ваткансың. 9Ишеткәнебезне чирүләр Ходае каласында, Аллабыз каласында күрдек:
Алла аны гомерлеккә корган. 10И Алла, рәхимеңне Синең халкың уртасында алдык. 11И Алла,
исемең кебек, даның да җир кырыеннан алып: уң кулың дөреслеккә тулы. 12И Ходай, кылган
эшләрең сәбәпле Сион тавы сөенсен һәм Яһүдия кызлары куансыннар. 13Сионны колачлап
әйләнегез, аның баганалары турысында сөйләгез; 14аңыгызны аның ныклыгына салыгыз, һәм
киләсе нәселгә әйтер өчен, аның өйләрен үлчәп алыгыз. 15Чөнки бу Алла гомергә һәм гомердән
гомергә безнең Аллабыз, Ул безне гомергә саклар.

Кырык сигезенче псалом (мәдхия).

1*В конец. Сынам Кореевым. Псалом*

*(Ахырга. Корах уллары өчен. Мәдхия).*

2Бар халыклар да моны ишетегез, дөньяда торучылар барыгыз да колак салыгыз: 3җирдән
яралганнар һәм адәм уллары, бай белән ярлы бергә! 4Авызым хикмәт әйтер һәм күңел уйларым –
белем. 5Мәсәлгә колагым салып торырмын, мәгънәсен гөслә уйнап аңлатырмын. 6Бәла көнне
нигә куркыйм? – Аягым канунсызлыгы чорнап алыр мине *шул чакта*. 7Әй үз көчегезгә
ышанучылар һәм байлыгыгыз күплеге белән мактанучылар! 8Туганың коткара алмагач, чит
кеше коткара алырмыни? Ул үзен Аллага һични биреп тә йола алмас, 9җанын да бәя биреп
*котылдыра алмас*, гомергә тырышып эшләсә дә. 10Һәм гомергә торырмы, үлемен күрмичә?
11Чөнки ул акыллылар үлгәнне, алар белән бергә акылсыз һәм уйсыз харап булганны,
байлыкларын ятларга калдырганны күрә. 12Аларның каберләре – *алар өчен* мәңге өйләре,
тумыштан тумышка тора торган урыннары, исемнәре белән җирләрен атаганнар *булсалар да*.
13Әмма кеше кадерлектә торганда *моны* аңламаган, ул акылсыз туарларга сабышып, алар кебек
булган. 14Аларның бу юллары үзләренә алдангыч, алай булса да аны ук телләре белән
хуплыйлар. 15Сарыкларны бәйләп салган кебек, аларны тәмугка салганнар, үлем аларны җыеп
тотар, һәм иртәгесен гаделләр аларга баш булырлар, тәмугта аларга булышу бетәр: даннарыннан
мәхрүм булганнар. 16Әмма Алла мине кабул итеп, җанымны тәмуг кулыннан коткарыр. 17*Шуңа
күрә* кеше баеган чакта я аның йорты данлы торган чакта курыкма. 18Чөнки үлгән чакта бер
нәрсә дә алмас, даны да аның артыннан бармас. 19Тере чагында аны данласалар да һәм аңа
яхшылык кылган чагында ул сиңа рәхмәт белдерсә дә, 20әмма ул аталарының нәселенә китәр:
гомергә якты күрмәс. 21Һәм кеше кадерлектә торганда аңламаган, ул акылсыз туарларга
сабышып, алар кебек булган.

Шөкер:

Кырык тугызынчы псалом (мәдхия).

*Псалом Асафа*

*(Асафның мәдхиясе).*

1Аллаларның Алласы, Ходай әйткән һәм кояш чыгышыннан кояш баешына чаклы җирдәге
*кешеләрне* чакырган. 2Сионнан Аның матурлыгының яме. 3Алла ачыктан-ачык килер, безнең
Аллабыз, һәм дәшми тормас: Аның алдында ут кабынып китәр һәм әйләнәсендә – бик каты
давыл. 4Ул Үз халкын тикшерергә югартын күкне дә, җирне дә чакырып китерер. 5Корбаннар
турында Алла белән сүз куешкан кешеләрен Аңа җыегыз. 6Күкләр Аның дөреслеген

белдерерләр, чөнки Алла – Хөкем Итүче. [7]Әй халкым, тыңлагыз, һәм сезгә әйтермен; әй Исраил!
Һәм сиңа таныклык итәрмен: Мин Алла – синең Аллаң. [8]Корбаннарың өчен Мин сине оялтмам,
яндырганнарың һаман күз алдымда. [9]Йортыңның бозауларын һәм көтүләреңнең кәҗә тәкәләрен
кабул итмәм. [10]Урмандагы киекләр бар да, тауларда көтелә торган туарлар һәм үгезләр Минеке
ич. [11]Һавадагы бар кошларны да беләмен, кырлар матурлыгы да алдымда. [12]Ашасым килсә,
синнән сорамам: дөнья да, аны тутырып торган нәрсәләр дә Минеке шул. [13]Мин бозау итен
ашыйммыни? Я кәҗә канын эчәммени? [14]Аллага данлау корбанын китер һәм Югарыдагы
алдында вәгъдә иткәннәреңне үтә, [15]һәм кайгылы көнеңдә Мине чакыр, һәм сине коткарырмын,
һәм син Мине данларсың. [16]Гөнаһлыга исә Алла әйткән: боерыкларымны ник сөйләгән буласың
һәм васыятемне авызың белән ник кабатлыйсың? [17]Әмма үзең өйрәткәнемне яратмадың һәм
сүзләремне артка ыргыттың: [18]каракны күргәч, аңа иярдең, һәм уйнашлык итүче белән бергә
катнаштың. [19]Авызың усаллыкны күбәйтте, һәм телең мәкер үреп ясады. [20]Утырган җиреңдә
туганыңны әләкләдең һәм анаң улына тозак салдың. [21]Моны кылдың, һәм дәшмәдем; канунга
каршыны уйладың: Мине үзеңә охшаттың. Мин сине оялтырмын һәм гөнаһларыңны күз алдыңа
китереп куярмын. [22]Әй Алланы онытучылар, тотып алынган чагыгызда коткаручысыз калмас
өчен, боларны аңлагыз. [23]Данлау корбаны Мине данлар: һәм шуның аркылы Мин аңа
коткаруымны күрсәтермен.

Илленче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Псалом Давида, когда вошел к нему Нафан пророк.*
[2]*После того, как он вошел к Вирсавии, жене Урия*
*(Ахырга. Давытның мәдхиясе. Батшеба белән булганнан соң Давыт*
*янына Натан пәйгамбәрнең килүенә нисбәтле мәдхия).*

[3]И Алла, Үзеңнең олы рәхимеңнән мине ярлыка һәм Үзеңнең күп юмартлыгыңнан
канунсызлыгымны әрчеп бетер. [4]Бигрәк мине канунсызлыгымнан ю һәм гөнаһымнан мине
тазарт. [5]Чөнки канунсызлыгымны тоямын һәм гөнаһым һаман күз алдымда тора. [6]Синең Үзеңә
үк гөнаһ кылдым һәм яман эшне күз алдыңда кылдым: Син Үз сүзеңдә туры һәм хөкемеңдә
мине тиешлечә гаепләрсең. [7]Менә мин канунсызлыкларда яралганмын, һәм анам мине нәфесен
сузып теләгән шул. [8]Менә Син чынны яратасың: хикмәтеңнең аермачык түгел яшереннәрен
миңа белдерттең шул. [9]Миңа һүссөп белән сибәрсең, һәм тазарырмын, мине юарсың, һәм кардан
да бигрәк агарырмын. [10]Миңа сөенеч һәм куаныч ишеттерерсең: уалган сөякләрем сөенерләр.
[11]Гөнаһларымнан йөзеңне бор һәм канунсызлыкларымны кичереп бетер. [12]И Алла, мине таза
күңелле ит һәм эчемдәге рухымны яңартып дөрес ит. [13]Үз йөзеңнән мине кума һәм Үзеңнең Изге
Рухыңны миннән алма. [14]Коткаруың сөенечен миңа кайтар һәм кодрәтле Рухың белән мине
ныкландыр. [15]Канунсызларны юлларыңа өйрәтермен, һәм бозык кешеләр Сиңа кайтырлар. [16]И
Алла, мине саклаучы Алла, кан *түгүдән* мине коткар! Телем Синең дөреслегеңне сөенеп әйтер.
[17]И Ходай! Телемне ачылдыр, һәм авызым Синең даныңны әйтер. [18]Корбан теләсәң китерер
идем, тик корбан яндыруга күңелең ятмый. [19]Аллага корбан – кайгылы рух, Алла кайгылы һәм
юаш күңелне кимсетмәс. [20]И Ходай, Үз игелегеңнән Сион тавына яхшылык ит, һәм
Иерусалимнең коймалары торгызылсыннар иде. [21]Аннары Син дөреслек корбанын, бүләк
күтәрүне һәм корбан яндыруны кабул итәрсең; аннары корбан урныңа бозаулар салырлар.

Шөкер:

Илле беренче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. В научение. Давида.*
[2]*Когда пришел идумеянин Доик и возвестил Саулу*
*и сказал ему: Давид пришел в дом Авимелеха.*
*(Ахырга. Эдоми Дуәг килеп: «Давыт – Әхимәликнең өендә!» – дип, Шаулга*
*хәбәр биргәннән соң, Давыт әйткән нәсыйхәт сүзләре).*

[3]Әй куәтле, ник усаллыгың белән мактнасың? Көн буе канунсызлык кыласың, [4]телең
дөрессезлекне әйтәсе итте: үткен пәке белән кискән кебек, юмалау белән кисәсең. [5]Яхшылыктан
бигрәк яманлыкны сөйдең, дөресне сөйләүдән бигрәк ялганны сөйдең. [6]Харап итә торган
һәртөрле сүзләрне, юмачы телне сөйдең. [7]Шуның өчен Алла сине бөтенләй кадалдырыр, сине
суырып алып, тора торган йортыңнан күчерер, һәм тереләр җиреннән тамырыңны *суырып алыр.*
[8]Гаделләр моны күреп куркышырлар, аннары аның турында әйтерләр: [9]”Менә Алланы үзенә

булышучыга куймаган кеше, әмма үзенең малы күплегенә ышанып, буш нәрсәсенә генә ныгып
торган кеше”, диярләр. [10]Мин исә – Алла өендә күп җимешле зәйтүн агачы кебек: Алла
рәхименә гомергә һәм гомердән гомергә өметләндем. [11]Кылган эшләреӊ өчен Сине гомергә
данлап сөйләрмен, һәм исемеңә өметләнермен, чөнки ул яраулыларың алдында яхшы.

Илле икенче псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Радостная хоровая песнь. В научение. Давида*
*(Ахырга. Шатлыклы кумәк җыр. Давытның нәсыйхәт сүзләре).*

[2]Акылсыз үз күңелендә: “Алла юк”, дип әйткән. Алар азганнар һәм канунсызлык кылып
ямьсезләнгәннәр: игелек кылучы юк. [3]Алланы аңлаучы, я эзләүче бар микән дип, Алла күктән
адәм улларына күз төшергән. [4]Бары берьюлы авышканнар, яраусыз булганнар: игелек кылучы
юк, берәү дә юк. [5]Канунсызлык кылучылар бар да, минем халкымны, икмәк ашаган кебек,
ашаучылар аңга килмәсләр микәнни? Ходайны искә алмаганнар. [6]Куркыныч юк җирдә
котчыгаргыч курыкканнар, чөнки кешегә генә яраулы булырга тырышканнарның сөякләрен
Алла чәчеп бетергән. Оятка калганнар, чөнки Алла аларны хур иткән. [7]Сионнан Исраилгә
котылуны кем бирер? Алла Үз халкын тоткыннан кайтаргач, Ягъкуб сөенер, һәм Исраил куаныр.

Илле өченче псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Песнь. В научение. Давида.*
[2]*Когда пришли зифеи и сказали Саулу: вот Давид не у нас ли скрылся?*
*(Ахырга. Җырлап. Зифлылар, килеп, Шаулга: «Давыт безнең якларда*
*качып ята», – дигәннән соң, Давыт әйткән нәсыйхәт сүзләре).*

[3]И Алла, Үз исемең хакына мине сакла һәм Үз кодрәтең белән мине хөкемдә якла. [4]И Алла,
догамны ишет, авызым әйткән сүзләремне тыңла! [5]Чөнки ятлар миңа каршы тордылар һәм
көчлеләр җанымны эзләделәр һәм Алланы үз алларында тотмадылар. [6]Менә миңа булышучы –
Алла һәм җанымны яклаучы – Ходай. [7]Дошманнарымның усаллыгын үзләренә кайтарыр:
чынлыгың белән аларны бетер. [8]Сиңа корбанны иректән китерермен, и Ходай, Синең исемеңне
данлап сөйләрмен, чөнки ул яхшы. [9]Чөнки Син мине һәрбер кайгыдан коткардың һәм күзем
дошманнарыма карап торды.

Илле дүртенче псалом (мәдхия).
[1]*В конец. Песнь. В научение. Асафа.*
*(Ахырга. Җырлап. Асафның нәсыйхәт сүзләре).*

[2]И Алла, догамны тыңла һәм инәлүемне ким күрмә. [3]Миңа аң сал һәм мине ишет: кайгылар
тотып, көеп беттем, [4]дошман сүзеннән һәм гөнаһлының кысуыннан каушадым, чөнки мине
канунсызга куйдылар һәм ачу белән миңа дошманлык иттеләр. [5]Эчемдә йөрәгем каушады, һәм
үлем куркынычы миңа төште, [6]куркыныч төшеп калтырадым, һәм караңгы мине ябып алды.
[7]Һәм мин әйттем: күгәрченнеке кебек канатлар миңа кем бирер? Очып китеп, тынычланыр идем.
[8]Менә качып китеп, чүлгә урнаштым. [9]Йөрәксез булудан һәм давылдан саклаучы Алланы
көттем. [10]И Ходай, *дошманнарны* батыр, һәм телләрен саташтырып бетер, чөнки калада
канунсызлык һәм даулашу күрдем. [11]Алар көне-төне кала коймаларыннан әйләнеп йөриләр,
аның уртасында кануннан язу белән кысанлык, һәм дөрессезлек. [12]Базарларында арттырып алу
һәм алдау өзелми. [13]Мине дошман хурласа, түзәр идем, һәм мине күрәлмый торган кеше минем
өстемнән күп сөйләшсә, аннан качып китәр идем. [14]Син исә үземдәй күргән кешем, киңәшчем
һәм якыным, [15]минем белән бергә кинәнеп, аш ашаган кешем, Алла өенә бер уй белән йөрешкән
кешем, *син мине хурлап сөйләштең.* [16]Мондыйларга үлем тисен һәм тере көенчә тәмугка
төшсеннәр, чөнки аларның өйләрендә, урталарында гел яманлык. [17]Мин Аллага инәлдем, һәм
Ходай мине ишетте. [18]Кич тә, иртә дә, көн уртасында да сөйләп белдерермен, һәм Ул
тавышымны ишетер. [19]Миңа якынлашучылардан җанымны тыныч көе саклар, чөнки минем
белән алар күп иде. [20]Алла ишетер һәм мәңгедән Бар аларны юашландырыр, чөнки алар
үзгәрмиләр һәм Алладан курыкмадылар. [21]Ул *аларга* кайтарырга кулын сузды: Аның васыятен
хурладылар. [22]Аның ачулы йөзеннән таралашып беттеләр. Күңелләре белән якынлашсалар да,
сүзләре майдан йомшак булса да, тик алар ук шикелле үткен. [23]Кайгыңны Ходайга сал, һәм Ул
сине асрап тотар: гадел кешене һичкайчан каушатмас. [24]Син исә Алла, аларны баткак базга

төшерерсең: кан түгүчеләр һәм юмачылар гомерләренең яртысына да җитмәсләр, ә мин, и Ходай, өметемне Сиңа салам.

Шөкер:

7-нче кафисмадан соң,
Өч изгелек.
*Тропарьләр: 5-нче көйгә.*

Хөкем Итүче утырган чакта, һәм фәрештәләр каршысында торган чакта, быргы авазы ишетелгән чакта, ялкын янып торган чакта, әй җаным, сине хөкемгә алып барганда ни эшләрсең? Ул чакта синең усал эшләрең килеп күренерләр, һәм яшерен кылган гөнаһларың беленерләр. Шуңа күрә ахырың булганчы, Хөкем Итүчегә дәшеп әйт: и Алла, мине тазарт, һәм мине ярлыка.

Шөкер: Барыбыз да уяу торыйк, һәм күп майлы яктырткычлар белән Мәсихне каршы алыйк, пулатының эченә керергә лаеклы булсак иде; ишегенең тыш ягына туры килгәне файдасыз гына Аллага дәшеп әйтер: мине ярлыка дип.

Әле дә: Күп гөнаһлар ятагында ятып, котылырга өметем кими бара, чөнки ялкаулыгым йокысы җаныма газап әзерли, әмма Син, Кыздан туган Алла, Сиңа җырларга мине торгыз, Сине данласам иде.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Ходай Аллам, Син игелекле һәм кеше сөючегә күрә, күп рәхимлелекләр миңа кылдың, аларны күрермен дип, көтмәгән идем дә. Һәм Синең яхшылыгыңа мин ни кайтарыйм, и Ходаем, и Ходай? Синең күп төрлечә данлый торган исемеңә шөкер итәмен, Синең әйтеп бетергесез игелекле күңеллелегеңә шөкер итәмен, Синең чагыштыргысыз озак түземлегеңә шөкер итәмен. Моннан болай да мине якла, һәм миңа булыш, мине барысыннан да каплап тор, и Иям, Синең алдыңда гөнаһ кылмасам иде. Син минем затымның гөнаһка егылучан икәнен беләсең шул, акылсызлыгымны да беләсең. Минем белеп тә, белмичә дә, иректән һәм ирексездән, төн вакытында да, көн вакытында да акылымда һәм уйлавымда кылган эшләремне Син беләсең. Үзең игелекле һәм кеше сөюче Аллага күрә, рәхимең чыгы белән боларны тазарт, и иң игелекле Ходай, һәм Үзеңнең изге исемең хакына безне коткар, Үзең белгән язмышларың белән. Чөнки Син Үзең якты, һәм чынлык, һәм терелек; һәм Сиңа дан китерәбез, Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

## Сигезенче кафисма.

Илле бишенче псалом (мәдхия).
1*В конец. О народе, удаленном от святынь. Давида. В столпописание.*
*Когда удерживали его иноплеменники в Гефе*
*(Ахырга. Изге нәрсәләрдән ераклаштырылган халык хакында. Давытның*
*Гәт шәһәрендә пелештиләр кулына эләккәннән соң язган баганадагы язуы).*
2И Алла, мине ярлыка, чөнки кеше мине таптады, көн буе миңа ябышып, мине тыгызлады.
3Дошманнарым көн буе мине таптадылар, чөнки югартын торып, миңа ябышучылар бик күп.
4Бер көнне дә курыкмам, чөнки Сиңа өметләнәм. 5Сүзләрем белән Алланы мактармын: Аллага
өметләндем, курыкмам, миңа тән ни кыла алыр? 6Көн саен сүзләремнән җирәнештеләр, бар
уйлаган уйлары – миңа яманлыкка. 7Яшеренеп утыралар, үкчәмне сагалыйлар, җаным бетүне
көтәләр шул. 8Аларны борып җибәрүе Сиңа бер нәрсә дә түгел: ачуың белән халыкларны түбән
төшерерсең. 9И Алла, тормышымны Сиңа билгеле иттем: Үз вәгъдәң буенча күз яшьләремне
алдыңда тотасың. 10Мин Сиңа инәлгән көнне дошманнарым кире китсеннәр иде: менә минем
Аллам дип, Син икәнне белдем. 11Алланы әйтеп мактармын, Ходайны сүз белән мактармын.
12Аллага өметләндем, курыкмам, кеше миңа ни кылыр? 13И Алла, Сине мактар өчен үтисе
вәгъдәләр өстемдә. 14Чөнки Син җанымны әҗәлдән, күзләремне елаудан һәм аякларымны
таюдан коткардың: терелләр дөньясында Ходайга яраулыны кылырмын.

Илле алтынчы псалом (мәдхия).
1*В конец. Не погуби. Давида. В столпописание.*
*Когда он убегал от Саула в пещеру*

*(Ахырга. Харап итмә. Давытның, Шаулдан качып,*
*мәгарәдә яшеренеп яткан чагында язган баганадагы язуы).*
2Мине ярлыка, и Алла, мине ярлыка; чөнки җаным Сиңа өметләнде, канунсызлык үтеп
киткәнче, канатларың күләгәсенә ышанып торырмын. 3Югарыгы Аллага, миңа яхшылык иткән
Аллага инәлеп дәшәрмен. 4Күктән *куәт* җибәреп, мине саклады, мине таптаучыларны хурлыкка
калдырды: Алла Үз рәхимен һәм чынлыгын җибәрде. 5Җанымны яшь арысланнар арасыннан,
куркып яткан җиремнән коткарды. Адәм уллары! Аларның тешләре сөңге белән уктай, һәм
телләре – үткен кылычтай. 6Күкләргә күтәрел, и Алла, һәм даның белән бөтен җир тулы!
7Аякларыма ау кордылар һәм җанымны кысрыкладылар: алдымда баз казыдылар һәм аңа үзләре
егылдылар. 8Күңелем әзер, и Алла, күңелем әзер: олылыгымда данлармын да, җырлармын да.
9Әй даным, тор, саз белән гөслә торыгыз! Мин иртүк торырмын. 10И Ходай, халыклар арасында
Сине данлап сөйләрмен, кавемнәр арасында Сиңа җырлармын. 11Чөнки рәхимең күкләргә чаклы
зур һәм чынлыгың – болытларга чаклы ук. 12Күкләргә күтәрел, и Алла, һәм даның белән бөтен
җир тулы.

Илле җиденче псалом (мәдхия).
1*В конец. Не погуби. Давида. В столпописание.*
*(Ахырга. Харап итмә. Давытның баганадагы язуы).*
2Әй адәм уллары, чынлап дөресне сөйләшсәгез, дөрес тикшерегез. 3Чөнки җирдә *торып,*
күңелегездә канунсызлык кыласыз, кулларыгыз дөрессезлек үрәләр. 4Гөнаһлылар тумыштан ук
ят булдылар, корсактан ук саташтылар, ялган сөйләштеләр. 5Аларның ярсуы еланныкы кебек,
колагын тыккан саңгырау аспидныкы кебек, 6иң оста сихерче сихерләгән чагында ул аның
сихерләгән сүзенә бирешми. 7Алла аларның авызларындагы тешләрен җимерер: Ходай
арысланнарның теш казналарын ватты. 8Агып үтә торган су кебек юкка чыгарлар: хәлләре
беткәнче *Ходай* җәясен киереп торыр. 9Балавыз эрегән кебек бетәрләр: өсләренә ут төшкәч,
кояшны да күрмәгәннәр. 10*Усаллыклары* күгән кебек, кечкенәдән дәү булганчы, *Ходай* ачуы
белән аларны тереләй юкка чыгарыр. 11Ходай кайтарганны күргәч, гадел кеше сөенер:
гөнаһлының канында кулларын юар. 12Шул чакта кеше әйтер: алай булгач, гаделгә җимеш бар
икән, җирдә аларга хөкем итүче Алла бар икән! – дияр.

Шөкер:

Илле сигезенче псалом (мәдхия).
1*В конец. Не погуби. Давида. В столпописание.*
*Когда Саул послал стеречь дом его, чтобы умертвить его*
*(Ахырга. Харап итмә. Давытның баганадагы язуы.*
*Шаул, Давытны үтермәкче булып, аның йортын күзәтер өчен*
*кешеләр җибәргән вакытка мөнәсәбәтле).*
2И Алла, дошманнарымнан мине аралап ал һәм миңа ябышучылардан мине коткар.
3Канунсызлык кылучылардан мине коткар һәм кан түгүчеләрдән мине сакла. 4Чөнки менә
җанымны тоттылар: канунсызлык кылмаган көе, гөнаһым юк көе, и Ходай, көчлеләр миңа
тотындылар. 5Канунсызлык кылмый туры тордым; торып каршыма кил һәм кара. 6Һәм Син, и
Ходай, чирүләр Алласы, Исраил Алласы, бар халыкларны ашыгып килеп күр, канунсызлык
кылучыларның берсен дә кызганмасаң иде. 7Кич белән алар кайтырлар һәм эт шикелле, ачыгып,
кала әйләнәсендә йөрерләр. 8Менә алар авызлары белән сөйләшәләр, әмма авызларында кылыч:
“Кем ишетсен?”, диләр. 9Һәм Син, и Ходай, алардан көләрсең: бар халыкларны хур итәрсең.
10Куәтемне Синең аркылы саклармын, чөнки Син, и Алла, минем яклаучым. 11Аллам минем!
Рәхиме мине каршы алыр. Аллам минем! Дошманнарымны иткән *хөкемен* миңа күрсәтер.
12Аларны үтермә, кануныңны оныткан көе калмасыннар иде; и яклаучы Ходаем, Үз куәтең
белән аларны таратып кечеләндер, 13авызларының гөнаһы өчен, телләренең сүзе өчен.
Горурланган чакларында тотылып алынсыннар, каргаулары һәм ялганлаулары сәбәпле бетүләре
билгеле булыр, 14котчыгаргыч үлеп югалырлар. Аннары Ягъкубны да, кырыйларыннан алып
җирне дә Алла тотып торганны белерләр. 15Кич белән алар кайтырлар һәм эт шикелле, ачыгып,
кала әйләнәсендә йөрерләр. 16Ашамлык табар өчен үзләре таралырлар, туенмасалар,
зарланашырлар. 17Мин исә Синең куәтеңне данлармын һәм иртәдән үк рәхимеңә сөенермен,

чөнки Син миңа кайгылы көнемдә сыенып җирем һәм яклаучым булдың. [18]Булышучым минем! Сиңа җырлыйм, чөнки Алла – яклаучым минем, и Аллам, рәхимем минем!

Илле тугызынчы псалом (мәдхия).

*[1]В конец. Об  имеющих измениться. В столпописание. Давида. В научение. [2]Когда он сожег Средоречие Сирийское и Сирию Совальскую и возвратился Иоав и поразил Едома в Соляной долине, двенадцать тысяч*

*(Ахырга. Үзгәрәселәр хакында. Давытның баганадагы язуы. Нәсыйхәт. Арам-Наһараимгә һәм Арам-Собага каршы Давыт алып барган сугыштан кайтып килгән Йоавның Тоз үзәнендә унике меңлек Эдом гаскәрен тар-мар итүенә мөнәсәбәтле).*

[3]И Алла, безне борып җибәрдең һәм безне түбән төшердең, безгә ачуың килде, алай да безне кызгандың. [4]Җирне тетрәтеп рәтен бетердең, җимерелгән җирләрен төзәт, чөнки ул кузгалды. [5]Үз халкыңа катылык күрсәттең, шәраб эчерткән кебек, безгә кайгы эчерттең. [6]Синнән куркучыларга җәядән качарга билге бирдең, [7]сөеклеләрең котылыр өчен. Уң кулың белән мине сакла һәм ишет мине! [8]Алла Үзенең изге урнында әйткән: “Сөенермен, һәм Шәкемне бүләрмен, йортлары торган үзәнне дә үлчәрмен. [9]Гилыгад – Минеке, Менашше дә – Минеке, һәм Эфраим – Мин куйган нык башлык, Йәһүдә – Мин куйган патша. [10]Моаб – өметем савыты, Эдомга итегемне сузармын: ят нәселләр Миңа буйсындылар”, дигән. [11]Нык калага мине кем кертер? Я Эдомга чаклы мине кем алып барыр? [12]И безне борып җибәргән Алла, чирүләребез белән чыкмас булган Алла, Син кертми кем кертсен? [13]Кайгыбызда безгә булыш, кеше булышуы юк нәрсә шул. [14]Алла белән куәтебезне күрсәтербез һәм Ул безне кысучыларны юкка чыгарыр.

Алтмышынчы псалом (мәдхия).

*[1]В конец. Песнь. Давида. Псалом*

*(Ахырга. Җырлап. Давытның мәдхиясе).*

[2]И Алла, инәлүемне ишет, догама аң сал. [3]Йөрәгем көенгән чагында җир читләреннән Сиңа инәлеп дәштем: Син мине таш өстенә күтәрдең, миңа юл күрсәттең. [4]Чөнки Син ышанганым булдың, дошманнан *кереп сакланырга* нык ышыклагыч *булдың*. [5]Син тора торган төшкә гомергә урнашырмын, канатларың бөркәвенә ышыкланып торырмын. [6]Чөнки Син, Алла, догаларымны ишеттең, исемеңнән куркучыларга өлеш бирдең. [7]Патшага көннәр өстенә көннәр өстәрсең, *гомере* елларын тумыштан тумышка *сузарсың*. [8]Алла алдында ул гомергә торыр. Аның рәхимен һәм чынын кем белеп җитә алыр? [9]Шушылай көн дә, көн дә вәгъдәләремне үтәп, Синең исемеңә гомергә җырлармын.

Шөкер:

Алтмыш беренче псалом (мәдхия).

*[1]В конец. Чрез Идифума. Псалом Давида*

*(Ахырга. Едутун өчен. Давытның мәдхиясе).*

[2]Җаным Аллага буйсынмый, кемгә буйсынсын? Мине коткаручы Ул ич. [3]Чөнки Ул – минем Аллам һәм коткаручым, яклаучым, инде какшамам. [4]Бер якка авышкан диварны, сөрлеккән койманы аудырырга торган кебек, сез барыгыз да кайчанга чаклы кешене басып үтерергә торырсыз? [5]Шуңа күрә кадеремне бетерер өчен, киңәшкә йотыгышып йөгерделәр: авызлары белән игелек теләделәр, һәм күңелләрендә каргадылар. [6]Әй җаным, Аллаңа гына буйсын, чөнки өметләнгәнем Ул. [7]Чөнки Ул – минем Аллам һәм коткаручым, яклаучым, үзгәрмәм. [8]Мине саклаучы һәм данландыручы – Алла, миңа булышучы – Алла, өметем дә Аллада. [9]Әй халыкларның бөтен җыены, Аңа өмет итегез, күңелләрегезне Аңа агылдырыгыз, чөнки Алла – безнең булышучыбыз. [10]Чынлап, адәм уллары буш нәрсә генә, адәм уллары алдавыч үлчәү *кулланып* ялганчы булганнар, алар буш нәрсә генә булганлыктан бергә *кушылалар*. [11]Дөрессезлеккә ышанып тормагыз һәм талап алуны теләмәгез: байлык агылып килгәндә, аңа күңелегезне салмагыз. [12]Алланың бер әйтүендә шушы ике *нәрсә* ишеттем: кодрәт – Алланыкы, [13]рәхим дә, и Ходай, Синеке, чөнки Син һәрбер кешегә эшләренә карап кайтарырсың.

Алтмыш икенче псалом (мәдхия).

*[1]Псалом Давида, когда он был в пустыне Иудейской*

*(Давытның Яһүдия чүлендә әйткән мәдхиясе).*

2И Алла, и Аллам, иртәдән үк Синең алдыңда торам. Кеше үтә алмаслык, сусыз һәм буш җирдә
тәнем ни хәтле кибенеп тора, шул хәтле җаным Сиңа сусап тора. 3Кодрәтеңне һәм олылыгыңны
күрергә изге өеңә керә торган идем. 4Чөнки рәхимең яшәүләрдән күп яхшы. Авызым Сине
мактар. 5Шулай терелегемдә Сине данлармын, исемең хакына кулларымны күтәрермен. 6Көр
нәрсә һәм май белән туенгандай, авызым сөенечле теле белән Сине мактап, җаным туенсын иде.
7Яткан урнымда чагында ук Сине исемә төшереп, иртәдән үк Синең турда сагыш тоттым; 8чөнки
Син миңа булышучы булдың һәм канатларың бөркәвендә сөенеп торырмын. 9Җаным Сиңа
кушылды, уң кулың мине кабул итте. 10Җанымны гаебе юк көе эзләүчеләр исә җир астына
төшәрләр, 11кылыч белән чабылырлар, төлкеләргә җим булырлар. 12Патша исә Аллага сөенер,
Аның белән ант итүче һәркем макталыр, чөнки дөрес түгелне сөйләшүчеләрнең авызлары
ябылган.

Алтмыш өченче псалом (мәдхия).

1*В конец. Псалом Давида.*

*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

2И Алла, Сиңа инәлгәндә авазымны ишет, дошман куркытуыннан җанымны коткар. 3Яманлык
кылучылар җыеныннан, дөрессезлек кылучы күплегеннән мине ябып тор, 4телләрен кылыч
шикелле үткенләгәннәр, гаепсезгә яшертен атыйк дип, зәһәрле җәяләрен корганнар: 5аңа
тоймастан атарлар һәм курыкмаслар. 6Яман сүзләрендә нык торалар, ауны яшерен салырга сүз
куешканнар: “Аларны кем күрер?”, дигәннәр. 7Канунга каршы эшне кылырга эзләгәннәр, иң
яманын эзләп, хәлләре беткәннәр; шундый кеше якынлашыр, һәм күңелен белер хәл юк. 8Әмма
Алла күтәрелер! Алар ясаган яра балалар аткан укныкы кебек кенә. 9Телләре үзалдына
хәлсезләнгән, аларны күрүчеләр барысы да каушаганнар. 10Һәрбер кешенең коты чыккан,
аннары Алла эшләрен әйткәннәр, һәм кылган эшләрен аңлаганнар. 11Гадел кеше Ходайга сөенер,
һәм өметен Аңа салыр, һәм дөрес күңелләләр бар да макталырлар.

Шөкер:

8-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 5-нче көйгә.*

Гөнаһлар тирәнлеге эченә батучы мине өмет өзү дулкыннары какшаталар: әмма мине каршы ал, и Мәсих, Үзең барына да куәтле күрә, и барын да Йөртүче, һәм нәфессезлек тыныч җиренә чыгар, игелекле күңеллелегеңә күрә, и Коткаручы, һәм коткар мине.

Шөкер: Әй җаным, монда син вакытлы гына, тегендә исә мәңге; хөкем итү урнын һәм тәхеттә Хөкем Итүчене күрәмен, һәм Аның каты сүзеннән калтырыйм; инде җаным кайт, хөкем итү кичерә торган вакыт түгел шул.

Әле дә: Өметләре беткәннәрнең өмете, булышучысы юкларга булышучы, үзләрен Сиңа тапшыручыларны яклаучы, и Алланы тудырган изге Иям Кыз, Үзеңнән булышу безгә дә җибәр.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И юмарт һәм рәхимле Ходай, озак түзүчән һәм күп рәхимле, догамны ишет һәм инәлгән авазыма аң сал, яхшылык билгесен миңа күрсәт, Синең чынлыгыңда йөрер өчен мине Үз юлыңа бастыр; Синең изге исемеңнән куркырга дип, күңелемне сөендер, чөнки Син олы һәм могҗизалар кылучы. Син бер генә Алла, и Ходай, һәм аллалар арасында Сиңа охшаулысы юк. И Ходай, Синең исемеңә өметләнүчеләргә булышыр өчен, аларны юатыр өчен, һәм барысын да коткарыр өчен, Син рәхимеңдә көчле һәм ныклыгыңда игелекле Алла: Ата, һәм Ул, һәм Изге Рух, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

## Тугызынчы кафисма.

Алтмыш дүртенче псалом (мәдхия).

1*В конец. Псалом, песнь. Давида. Песнь Иеремии и Иезекииля,*
*народа переселенного, когда хотели они выходить (из плена)*
*(Ахырга. Давытның җыр-мәдхиясе. Иремия белән Яхәзкил,*
*күчерелгән халыкның әсирлектән чыкмакчы булып җыры).*

[2]И Алла, Сиңа Сионда җырлау тиешле, һәм Сиңа Иерусалимдә дога китерерләр. [3]Догамны ишет,
һәрбер кеше Сиңа килер. [4]Канунсызларның сүзләре безне алҗыттылар, һәм бозыкларыбызны
Син тазартырсың. [5]Син сайлап алган кеше бәхетле, йортларыңа урнашыр! Өеңнең игелекләре
белән туенырбыз: өең изге, [6]дөреслеге искитәрлек. Җирнең һәрбер читендә торучыларның һәм
ерак диңгездә торучыларның ышанганы, и саклаучы Аллабыз, безне ишет! [7]Куәтең белән
тауларны булдыручы, куәтне биленә чолгагансың. [8]Диңгез тугайларын болгатучы, аның
дулкыннарының шаулавына кем чыдар? Халыклар каушарлар, [9]һәм җирдә торучылар
билгеләреңнән куркырлар. Иртә һәм кич башларын матурларсың. [10]Җиргә килеп, аны
эчерткәнсең, аның байлыгын күбәйткәнсең: Алла иделе сулар белән тулы, аларга[5] ашамлык
әзерләгәнсең, шушылай булган булдыруың. [11]Җирнең буразналарын эчерт, аның ашлыкларын
уңдыр, ул тамчылардан үстереп сөенер. [12]Ел әйләнәсен игелегең белән бәхилләрсең, һәм
басуларың көрлеккә туенырлар. [13]Чүлнең матур җирләре күперенерләр, һәм түбә җирләр
сөенечкә чорналырлар. [14]Сарык тәкәләре *йонга* киенерләр, һәм үзән җирләр бодайларны
уңдырырлар, дәшеп җырлашырлар.

[5] Адәмнәргә.

Алтмыш бишенче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Песнь псалма воскресения*

*(Ахырга. Терелеп тору җыр-мәдхиясе).*

[2]Җирдәгеләр барыгыз да Аллага сөенеп кычкырыгыз, Аның исеменә җырлагыз, Аны данлап
мактагыз. [3]Аллага әйтегез: эшләрең ничек котчыгаргыч! Куәтең күплегеннән дошманнарың
Синең алдыңда ялганчы булырлар. [4]Җирдәгеләр бар да Сиңа башырып, Сиңа җырласыннар иде,
и Югарыдагы, исемеңне данласыннар иде. [5]Килегез һәм Алла эшләрен күрегез: Аның адәм
улларына боеруына карагач, Ул бик куркыныч. [6]Диңгезне коры җиргә алмаштырган, инеш
аркыллы җәяүләп чыкканнар, шуңа Аның хакына сөенештек. [7]Куәте белән гомергә башкарып
тора: Аның күзләре халыкларны күреп торалар, Аның ачуын китерүчеләр күтәрелешмәсеннәр.
[8]Әй халыклар, безнең Алланы данлагыз һәм Аны мактау тавышын ишетерлек итегез. [9]Ул
җанымны тере көе тотты һәм аякларымны какшатмады. [10]Чөнки Син, Алла, безне сынадың,
көмешне эретеп караган кебек, безне эретеп карадың. [11]Тозакка безне керттең, аркабызга бәла-
каза салдың. [12]Баш өстебезгә кешеләрне мендердең, уттан һәм судан үтеп чыктык, алай да безне
тыныч җиргә чыгардың. [13]Синең өеңә корбан яндырырга керермен, [14]кайгылы чагымда авызым
сөйләп һәм телем әйтеп вәгъдә иткәннәремне Сиңа китерермен. [15]Яндырырга, хуш исе белән
бергә көр тәкәләр Сиңа китерермен, үгезләр белән кәҗә тәкәләре Сиңа китерермен. [16]Әй
Алладан куркучылар, барыгыз да килеп тыңлагыз, җаныма ни кылганын сезгә белдерермен.
[17]Аңа авызым белән дәштем һәм телем белән Аны мактап күтәрдем. [18]Күңелемдә дөрессезлек
күргән булсам, Ходай мине ишетмәсен. [19]Шунлыктан Алла мине ишетте, догамның авазына аң
салды. [20]Догамны чигермичә, мине Үз рәхименнән буш калдырмаган Алла данлаулы.

Алтмыш алтынчы псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Песнь. Псалом песни Давида*

*(Ахырга. Җырлап. Давытның җыр-мәдхиясе).*

[2]И Алла, безгә игелекле бул һәм безне бәхиллә, безгә йөзеңне яктырылдыр һәм безне ярлыка.
[3]Җир өстендә юлыңны белсәк иде, бар халыклар да коткаруыңны белсеннәр иде! [4]И Алла,
халыклар Сине данлап сөйләсеннәр иде! Бар халыклар да Сине данлап сөйләсеннәр иде!
[5]Халыклар сөенешеп куанышсыннар, чөнки Син кешеләрне дөреслек белән хөкем итәсең һәм
халыкларны җир өстендә йөртерсең. [6]И Алла, халыклар Сине данлап сөйләсеннәр иде! Бар
халыклар да Сине данлап сөйләсеннәр иде! [7]Җир җимешен бирде: и Алла, и Аллабыз, безне
бәхиллә! [8]И Алла, безне бәхиллә, җирнең һәрбер читендә торучылар Синнән куркып торсыннар
иде!

Шөкер:

Алтмыш җиденче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Псалом песни. Давида*

*(Ахырга. Давытның җыр-мәдхиясе).*

2Алла торсын, һәм дошманнары таралышып бетсеннәр, һәм Аны күрәлмый торганнар Аның
йөзеннән качсыннар! 3Төтен таралган кебек, таралып бетсеннәр, балавыз уттан эрегән кебек,
гөнаһлылар Алла йөзеннән югалсыннар! 4Ә гадел кешеләр Алла алдында сөенешеп
куанышсыннар, сөенечкә кинәнсеннәр. 5Аллага җырлагыз, Аның исемен данлагыз, кояш
баешына Килүчегә юл әзерләгез – Аның исеме Ходай – һәм Аның алдында сөенешегез.
6Үксезләр атасының һәм тол хатыннарны яклаучының йөзеннән каушасыннар: Алла Үзенең изге
урнында. 7Алла юашларны өйгә урнаштыра, богаудагыларны куәте белән иркенгә чыгара,
кабердәгедәй кысылып торучыларны рәнҗетүчеләрне югалтып бетерә. 8И Алла, Син халкың
алдыннан юл башлап йөргән чакта, чүлдән үткән чагыңда, 9җир тетрәгән, Синайда күренгән
Алла алдында, Исраил Алласы алдында күкләр эрегәннәр. 10И Алла, Син Үз халкыңа яңгырны
мул яудыргансың, хәле беткән чагында, Син аны ныгыткансың. 11Ул җирдә җәнлекләрең
торганнар, и Алла, игелегеңнән Син аларны ярлыларга әзерләп торгансың. 12Сөенеч әйтүчеләргә
Ходай зур куәте белән сүз иңдерер. 13Чирүләр Патшасы өен ямьләндерер өчен, сөеклесенә
табышны бүлешкән. 14Алар үзләренә тигән җиргә урнашкач, канатлары көмешләгән, һәм
җилкәсе алтындай ялтырап торган күгәрчен шикелле, рәхәтләнеп торалар. 15Шушы җирдәге
патшаларны Күктәге тараткан чакта, ул җир Салмон өстендәге кар кебек агарган. 16Алла тавы,
көр тау, сөтле тау, көр тау. 17Әй сөтле таулар, нигә күтәреләсез? Бу тау – Алла Үзе торырга
күңел иткән тау, чөнки анда Ходай гомергә урнашыр. 18Алла арбасы – ун меңнән артык,
әйләнәсендә куәтлеләр мең-мең, аларның уртасында Синайда изге кодрәте күренгән Ходай.
19Югары күтәрелгәнсең, тоткындагыларны Үзеңә коллыка алгансың, кешеләр Сиңа бүләкләр
китергәннәр, буйсынмаганнар да арасына Син урнашсын өчен. 20Ходай Алла данлаулы, Ходай
көн дә, көн дә данлаулы, саклаучы Аллабыз безне өлгертер. 21Аллабыз – безне саклаучы Алла,
үлем капкасы да Ходайныкы, Ходай кулында. 22Алла дошманнарының башларын ватыр,
гөнаһлары эчендә йөрүчеләрне түбәләреннән үк яньчер. 23Ходай әйткән: “Аларны Башан
*тавыннан* борып кайтарырмын, диңгез төбеннән үк табармын, 24аягың, этләреңнең телләре
дошманнарың канына чылансын өчен”, дигән. 25И Алла, баруыңны күргәннәр, изге өйдәге
Патша Алламның баруын күргәннәр: 26җыручылар янында алда башлыклар барганнар, уртада
тимпан[6] уйнаучы кызлар барганнар. 27Әй Исраил тумасыннан чыканнар, җыеннарда Алла
Ходайны данлагыз. 28Анда иң кече – Беньямин *нәселе* сөенешеп торган, хакимнәре Йәһүдә
башлыклары да шунда булганнар, Зәбулун башлыклары, Нәфтали башлыклары *булганнар*. 29И
Алла, куәтеңне күрсәт, и Алла, шушы безгә кылганыңны ныкла! 30Иерусалимдәге келәү өең
хакына патшалар Сиңа бүләкләр китерерләр. 31Камышлыктагы киектәйләргә – үгезләр җыенына
халыклар таналары арасында – көмеш белән сыналганнарны яптырырга тый, сугышасы килеп
торган халыкларны таратып бетер. 32Мисырдан киләүчеләр килерләр, Хәбәшстандагылар
кулларын Аллага алдан сузарлар. 33Әй җирдәге патшалыклар, Аллага җырлагыз, 34күк өстендәге
күккә кояш чыгышыннан менгән Ходайга җырлагыз! Менә Ул Үз тавышын куәтле итәр.
35Аллага дан китерегез! Аның олылыгы Исраилдә, һәм куәте болытлар өстендә *күренә*.
36Әүлияләрендә кодрәтен күрсәтүче Алла – Исраил Алласы: Ул Үз халкына ныклык һәм куәт
бирер. Алла данлаулы!

[6] Шөлдерле барабан.

Шөкер:

Алтмыш сигезенче псалом (мәдхия).

1*В конец. Об имеющих измениться. Псалом Давида*
*(Ахырга. Үзгәрәселәр хакында. Давытның мәдхиясе).*

2И Алла, мине сакла, чөнки сулар җанымны басарга җиттеләр. 3Тирән сазга баттым һәм басып
торыр җир юк; диңгез тирәнлекләренә кердем, һәм давыл мине батырды. 4Дәшә-дәшә хәлем
бетте, тамагым корылды, Алламнан *ярдәм* көткәнлектән күзләрем талыкты. 5Мине бушка
күрәлмый торучылар башымдагы чәчләремнән дә күбәйделәр, мине гаепсез көе куучы
дошманнарым көчәйделәр: мин алмаганымны да түләсе. 6И Алла! Син акылсызлыгымны
беләсең, гөнаһларым да Сиңа яшерен түгел. 7И Ходай, чирүләр Ходае, Сиңа өмет иткәннәр
минем хакымда оятка калмасыннар иде, и Исраил Алласы, Сине эзләүчеләр минем хакымда
хурлыкка калмасыннар иде! 8Чөнки Синең өчен хурлыкка түздем, битемне оят каплады. 9Ага-
энеләремә ят булдым һәм анам улларына чит булдым. 10Чөнки Синең өеңә күңел бирүе мине

билəп алды, һəм Сине хурлаучыларның хурлаулары миңа да тиде. [11]Ураза тотып, җанымны
юашландырдым, шуның өчен дə мине хурладылар. [12]Өстемə алама кием кидем һəм алар мине
мəсəлгə тоттылар. [13]Капка төбендə утыручылар мине мыскыл иттелəр, һəм шəраб эчүчелəр дə
мине керештереп җырлаганнар. [14]Ə мин, и Алла, Сиңа инəлəмен: и Алла, игелек кылырга вакыт,
рəхимең күплектəн, саклавың чын булганлыктан мине ишет. [15]Сазлыкка батып китүдəн мине
сакла; мине күрəлмый торучылардан һəм тирəн сулардан да котылсам иде. [16]Су давылы мине
батырмасын иде, чоңгыл мине йотмасын иде, коеда ябылып калмасам иде. [17]И Ходай, рəхимең
игелекледəн мине ишет, юмартлыгың күплектəн миңа кара. [18]Бəндəңнəн йөзеңне борма, чөнки
мин кайгырам, мине тиз ишет, [19]җаныма аң салып, аны коткар, дошманнарым сəбəпле мине
коткар. [20]Мине мыскылганны да, хурлаганны да, һəм оялтканны да белəсең шул; мине
рəнҗетүчелəр бар да Синең алдыңда. [21]Җаным мыскыллауны һəм читенлекне көтте;
кайгырышучы көткəн идем, тик булмады, юатучылар да көткəн идем, тик очратмадым. [22]Һəм
ашамлыкка миңа үт бирделəр, һəм сусаган чагымда миңа серкə эчерттелəр. [23]Сыйланып
утырулары аларга ау булсын, һəм кайтару булсын, һəм тозак булсын. [24]Күзлəре күрмəс өчен
караңгылансын, һəм сыртларын мəңгегə бөк. [25]Ачуыңны аларга кой, һəм ачуыңның ярсуы
аларны тотып алсын. [26]Йортлары буш калсын, һəм өйлəрендə торучы булмасын иде. [27]Чөнки
Син яралаганны алар куып бардылар, һəм яраларымның авыртуын көчəйттелəр.
[28]Канунсызлыклары өстенə канунсызлык тагы өстə, һəм Синең алдыңда дөрескə чыга
алмасыннар иде. [29]Терелəр китабыннан сөртелеп бетсеннəр һəм гаделлəр рəтенə язылмасыннар
иде. [30]Мескен һəм газаплanучы мин, и Алла, мине саклауны Үзеңə алсаң иде. [31]Алламның
исемен җыру белəн мактармын, мактау белəн Аны олылармын. [32]Мөгезле һəм аерым тояклы
яшь бозаудан да бигрəк Аллага *бу* яраулы булыр. [33]Ярлылар *моны* күреп куансыннар. Алланы
эзлəгез, һəм җаныгыз тере торыр. [34]Чөнки Ходай ярлыларны ишетте һəм богаудагыларын да
ташламады. [35]Күклəр дə, җир дə, диңгез һəм аның эчендə торучылар бар да Аны мактасыннар
иде! [36]Чөнки Алла Сионны саклар, һəм Яһүдия калалары торгызылырлар, анда урнашып, аны
билəп торырлар. [37]Бəндəлəреңнең нəселе аны билəр, һəм исемеңне сөючелəр анда урнашырлар.

Алтмыш тугызынчы псалом (мəдхия).

[1]*В конец. Давида. В воспоминание о том, что спас меня Господь*

*(Ахырга. Давытның, Ходай мине коткарган дип, искə төшерү өчен, язганы).*

[2]И Алла! Миңа булышуны аңында тот. И Ходай! Миңа булышырга тиз кил. [3]Җанымны
эзлəүчелəр оятка һəм хурлыкка калсыннар, миңа усаллык телəүчелəр оятка калып, кире
чиксеннəр. [4]Миңа *мыскыллап*: “Яхшы, яхшы!”, ди торганнары оялып, тиз үк кире китсеннəр. [5]И
Алла, Сине эзлəүчелəр бар да Сиңа сөенеп куанышсыннар, һəм Синең саклавыңны сөючелəр:
“Ходай олылансын” дип, һаман əйтсеннəр. [6]Мин исə ярлы һəм мескен, и Алла, миңа булыш:
миңа булышучы һəм мине коткаручы – Син, и Ходай, озаклама.

Шөкер:

9-нчы кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьлəр: 6-нчы көйгə.*

Куркыныч көнне исемə китерəмен дə кылган яман эшлəрем өчен елыймын. Үлемсез Патшага ничек итеп җавап бирермен? Я мин азгын булып, нинди кыюлык белəн Хөкем Итүчегə карармын? И игелекле күңелле Ата, и бердəнбер туган Ул, и Изге Рух, мине ярлыка.

Шөкер: Елау үзəне буйлап Син кушкан төшкə килеп җиткəч, и Рəхимле, дөрес хөкем итəргə утырган чагыңда, минем яшерен кылган эшлəремне ачыклап күрсəтмə, фəрештəлəрең алдында мине оятка калдырма, əмма мине кызган, и Алла, һəм мине ярлыка.

Əле дə: Сиңа сыенып килүчелəрнең өмете һəм ябучысы, и Алланы Тудырган Кыз, и дөнья өчен игелекле яклаучы, Үзең тудырган кеше сөюче Аллага, тəнсез фəрештəлəр белəн, җаннарыбызны һəртөрле газаптан коткарырга дип, тырышып инəл, Син бер генə данлаулы.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Ходай Алла Иябез, Син Үзең генə минем җанымның чирлəрен дə, аны ни белəн савыктырырга икəнен дə белүче, Үзеңнең күп рəхимең һəм юмартлыкларың хакына аны Үзең белгəнчə савыктыр. Чөнки кылган эшлəремнəн җаныма салырга бəйлəвеч тə юк, май да юк,

бәйләр әйбер дә юк. Әмма Син гаделләрне түгел, әмма гөнаһлыларны тәүбәгә чакырырга
килүче, юмартлык кылып, ярлыка, кичер аны. Минем бик күп оят эшләремнең язуын ертып,
мине Үзеңнең дөрес юлыңа бастыр. Синең чынлыгыңда йөреп, яманның укларыннан кача алсам
иде, һәм шулай гаепләнмичә Синең куркыныч тәхетең каршысына килсәм иде, Синең иң изге
исемеңне җырлап һәм данлап гомергә, амин.

**Унынчы кафисма.**

Җитмешенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. Сынов Ионадавовых и первых пленников.*

*Не надписан у евреев.*

*(Давытның мәдхиясе. Йонадаб улларыныкы һәм беренче әсирләрнеке.*

*Гыйбриләрдә өстән язып куймаган).*

[1]И Ходай, өметемне Сиңа салдым, гомергә оятка калмасам иде. [2]Дөреслегең белән мине
коткар һәм иркенгә мине чыгар, колагың миңа сал һәм мине сакла. [3]Мине яклаучы Алла бул һәм
мине сакларга нык урын бул, чөнки ныклыгым һәм сыенганым – Син. [4]И Аллам! Гөнаһлының
кулыннан, кануннан язучының һәм кыерсытучының кулыннан мине коткар. [5]Чөнки Син Ходай
– түземлек биручем, и Ходай, яшьтән үк өметем иткәнем – Син. [6]Тумыштан ук Сиңа беректем,
анам эченнән үк мине ябучы – Син. Сиңа һаман җырлыйм. [7]Күп кешеләргә искиткеч булдым,
һәм Син – куәтле булышучым. [8]Авызым *Сине* мактау белән тулы булсын иде, даныңны,ямеңне
көн буе җырласам иде. [9]Картлыгымда мине ташлама, егәрем кими башлагач, мине калдырма!
[10]Чөнки дошманнарым да, җанымны сагалаучылар да бергә киңәш итешеп әйттеләр: [11]"Алла
аны ташлады, барып тотыгыз аны инде, чөнки аны коткаручы юк", диделәр. [12]И Аллам! Миннән
читкә китә күрмә. И Аллам! Миңа булышуны аңында тот. [13]Җанымны әләкләүчеләр оятка калып
югалсыннар иде, миңа яманлык эзләүчеләр оятка һәм хурлыкка каплансыннар иде. [14]Ә мин
һаман Сиңа өмет итәрмен һәм Сине төрлечә мактармын. [15]Дөресеңне һәм коткаруыңны авызым
көн буе сөйләр, чөнки мин китап остасы түгел. [16]Ходай куәтендә йөрермен. И Ходай! Тик Синең
дөресеңне генә исемә алырмын. [17]И Аллам! Яшь чагымнан бирле миңа өйрәткән
могҗизаларыңны әлегә чаклы белдерермен. [18]И Аллам, мин картайганчы, һәм бик картайганчы,
куәтеңне буласы бар нәселләргә белдергәнче, мине ташлама. [19]И Алла, кодрәтеңне, югартын ук
торган дөреслегеңне, миңа кылган зур эшләреңне *белдерермен;* и Алла, Сиңа охшашырлык кем
бар? [20]И Алла, Син миңа күп авыр кайгылар күрсәттең, алай да Үзең үк мине тагы
тереләндердең, һәм мине җир упкынынннан чыгардың. [21]Олылыгыңны миңа күп күрсәттең,
борылып мине тынычладың, һәм мине тагы җир упкынынннан чыгардың. [22]И Ходай, халыклар
арасында Сине данлап сөйләрмен, и Алла, чыныңны саз уены белән *данлармын,* и Исраилнең
Изгесе, Сиңа гөслә белән җырлармын. [23]Сиңа җырлаган чагымда авызым да, Син коткарган
җаным да сөенерләр. [24]Миңа яманлык эзләүчеләр оялып хурлыкка калгач, телем дә
дөреслегеңне көн буе мактап торыр.

Җитмеш беренче псалом (мәдхия).

*О Соломоне. Псалом Давида*

*(Сөләймән турында. Давытның мәдхиясе).*

[1]И Алла, патшага хөкемеңне бир, һәм патша улына дөреслегеңне *бир*: [2]халыкларыңны дөрес
хөкем итсен иде һәм ярлыларыңны гадел тикшерсен иде. [3]Таулар халыклар өчен тынычлык
алсыннар иде һәм түбә җирләр дөреслек *алсыннар иде*. [4]Ярлы кешеләрне хөкем итәр, һәм
мескеннәр улларын саклар, әләкчене дә юашландырыр. [5]Кояш торган тиңенте торыр һәм айдан
элек тумыштан тумышка *торыр*. [6]Йонга яуган яңгыр кебек, һәм җиргә тама торган тамчы кебек
төшәр. [7]Ай алынганчы, Аның көннәрендә дөреслек белән күп тынычлык ялтырап торырлар.
[8]Диңгездән диңгезгә чаклы һәм иделләрдән җир кырыена чаклы биләп торыр. [9]Хәбәш кешеләре
Аңа егылып башырырлар һәм дошманнары туфрак яларлар. [10]Таршиш патшалары һәм атаулар
Аңа бүләкләр китерерләр, Гарәбстан патшалары һәм Саба *җире* дә Аңа бүләкләр китереп
бирерләр. [11]Җир патшалары барысы да Аңа башырырлар, бар халыклар да Аңа коллык итәрләр.
[12]Чөнки ярлыны һәм булышучысы юк мескенне көчледән коткарыр. [13]Ярлыны һәм мескенне
кызганыр, мескеннәрнең җаннарын да коткарыр. [14]Аларның җаннарын акча арттырудан һәм
дөрессезлектән саклар, һәм Аның исеме алар алдында кадерле. [15]Ул тере торыр, һәм Аңа

Гарәбстан алтыны бирелер; исемен әйтеп һаман инәлерләр, көн буе Аны данларлар. 16Җирдә,
таулар өстендә ныклык булыр, Аның җимеше Ливаннан да биек күтәрелер, каласындагылары да
җир үләне кебек яшәрерләр. 17Аның исеме гомергә данланып торыр, исеме кояштан элек үк бар;
җирдәге нәселләр бар да Аның аркылы игелек табарлар, бар халыклар да Аны олыларлар.
18Исраил Алласы Ходай данлаулы, бер генә могҗизалар кылучы. 19Аның данлыклы исеме
гомергә һәм гомердән гомергә данлаулы. Һәм Аның даны белән бар җир тулы булып торыр.
Амин, амин.

Шөкер:

*Окончились песни Давида, сына Иессеева*
*(Ишай углы Давытның догалары шушында тәмамлана).*

Җитмеш икенче псалом (мәдхия).
*Псалом Асафа*
*(Асафның мәдхиясе).*

1Исраил Алласы дөрес күңеллеләргә ничек игелекле! 2Аякларым исә аздан гына авышмадылар,
табаннарым аздан гына таймадылар. 3Чөнки канунсызлык кылучылар, гөнаһлылар тыныч
торганны күреп, көнчелегем килде. 4Чөнки аларның үлүләрендә газап юк һәм яралары да озакка
бармый. 5Кеше газапланып эшләгән кебек, газапланмыйлар, һәм кешеләр күргән кыенны алар
күрмиләр. 6Шуңа күрә аларны горурлык бөтенләй биләп алган, дөрессезлекләренә һәм
бозыкларына киенгәннәр. 7Дөрессезлекләре көрлекләреннән чыга, аны күңелдән сөйгәннәр.
8Яман уйлап сөйләшкәннәр, Югарыгы турысында ялган сөйләшкәннәр. 9Авызларын күккә
күтәргәннәр, һәм телләре җиргә җәелгән. 10Шунлыктан кешеләрем дә шуңа авышалар, һәм
аларның гомер көннәре тулы. 11Алар: “Алла ничек белсен? Һәм Югарыдагының белерлеге
бармыни? 12Менә шул гөнаһлы кешеләр үк бу гомердә яхшы көн күрәләр, байлыкта торалар”,
диләр. 13Һәм мин әйттем: “Күңелемне гадел тотарга бушка тырышмадыммы? Кулларымны да
гаепсезләр белән бушка юмадыммы? 14Көн дә үземне яралатып, иртә саен үземне бушка
әрләтмәдемме?”, дидем. 15Шулай әйткәнемчә сөйләсәм, Синең улларыңның нәселе алдында
гаепле булыр идем. 16Аннары моны ничек аңлыйм икән, дип уйладым; бу миңа читен булды,
17Алланың изге өенә кергәнче, *кергәч* аларның ничек бетәрен белдем. 18Шулай явызлыкларына
күрә, Син аларга кыен куйгансың, горурланган чакларында аларны түбән төшердең. 19Алар
ничек бөлделәр! Тоймастан таралдылар, канунсызлыклары өчен харап булдылар! 20Йокыдан
торучының төше шикелле, и Ходай, калаңда аларның төсен юкка чыгарырсың. 21Йөрәгем янып
һәм эчләрем үзгәргән чакта, 22чак булган аңламаганмын, Синең алдыңда туар шикелле
булганмын. 23Алай да мин һаман Синең белән, уң кулымнан мине тотып тордың. 24Үз киңәшең
белән мине йөрттең, һәм дан белән мине кабул иттең. 25Күктә минем өчен ни бар? Һәм җирдә дә
Синнән бүтәнне ни телим? 26Күңелем дә, тәнем дә *Сиңа* эри. И Алла, Син күңелемнең Алласы
һәм гомерлек өлешем. 27Чөнки менә, үзләрен Синнән биздерүчеләр харап булырлар, Синнән
бүтәнгә табынучының һәрберсен югалтып бетердең. 28Ә минем өчен Аллага кушылу, өметемне
Ходайга салу, Сион кызының капкалары төбендә бар даныңны сөйләү – яхшы.

Җитмеш өченче псалом (мәдхия).
*В научение. Асафа*
*(Асафның нәсыйхәте).*

1И Алла, ник *безне* бөтенләй үк борып җибәрдең? Үз көтүеңдәге сарыкларыңа ник ачуың
ярсыды? 2Әүвәлдән үк Үзең тапкан, Үзең коткарган җыеныңны, таягың саклый торган
өлешеңне, шушы Үзең урнашкан Сион тавын исеңә ал. 3*Дошманнарның* горурлыкларына каршы
кулыңны бөтенләй күтәр. Алар изге өеңдә ни хәтле яманлык кылдылар! 4Сине күрәлмый
торучылар бәйрәмең уртасында мактаныштылар, әләмнәребез урнына, белмәгәнлекләре буенча,
*келәү өенең* капкасы өстенә югары үз әләмнәрен куйдылар. 5Урманда агач кискән кебек, аның
ишекләрен балталар белән кистеләр, 6кискеч һәм чукмар белән аны җимерделәр. 7Изге өеңне ут
белән яндырдылар, исемең тора торган өйне җиргә аударып шакшыландырдылар. 8Аларның
тарафчылары бергәләшеп үз күңелләрендә әйттеләр: “Килегез, Алланың бар бәйрәмнәрен җир
өстеннән бетерик”, диделәр. 9Үз билгеләребезне күрмәдек: инде пәйгәмбәребез дә юк, безгә ни
буласын инде берәү дә белми. 10И Алла, дошман кайчанга чаклы хурлап торыр? Исемеңне

мәңгегә сансыз итеп торырмыни? [11]Үзеңнең уң кулыңны куеның эченнән ник бөтенләй үк ерак
тотасың? [12]Мәңгедән бар Патшабыз Алла, коткаруны җир уртасында кылган. [13]Син тотуыңның
куәтен диңгездә күрсәткәнсең, Син еланнарның башларын су эчендә яньчегәнсең. [14]Син елан
башын яньчеп, үзен Хәбәш кешеләренә ашамлыкка биргәнсең. [15]Син чишмәләр һәм инешләр
чыгартkансың, Син зур иделләрне киптергәнсең. [16]Көн дә Синеке, төн дә Синеке, таңны да,
кояшны да Син булдыргансың. [17]Җирнең бар кырыйларын Син булдыргансың, җәйне дә, язны
да Син куйгансың. [18]Боларны исеңә ал: дошман Ходайны рәнҗеткән, һәм акылсызлар Синең
исемеңне сансыз иткәннәр. [19]Сине сөйләүче җанны җанварларга бирмә, мескеннәреңнең
җаннарын бөтенләй үк онытма. [20]Үз васыятеңә күз сал, чөнки җирнең караңгы *җирләре*
кануннан язучыларның йортлары белән тулганнар. [21]Юаш кеше хурланып, борылып китмәсен
иде: ярлы да, мескен дә исемеңне мактарлар. [22]И Алла, тор, Үз эшеңне якла, акылсыз Сине көн
саен хурлаганны исеңә ал. [23]Синең инәлүчеләрнең авазларын онытма! Сине күрәлмый
торучыларның горурлыгы һаман Сиңа җитсен иде.

Шөкер:

Җитмеш дүртенче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Не погуби. Псалом песни Асафа*

*(Ахырга. Харап итмә. Асафның җыр-мәдхиясе).*

[2]Сине данлап сөйләрбез, и Алла, Сине данлап сөйләрбез һәм Синең исемеңә сыенырбыз. Мин
Синең бар могҗизаларыңны әйтеп белдерермен. [3]*Алла әйтә*: “Вакыт тапкач, дөрес хөкем
итәрмен. [4]Җир дә, аның өстендә торучылар бар да эреп беттеләр: Мин аның баганаларын
беркеттем”, ди. [5]Канунсызлык кылучыларга әйттем: канунсызлык кылмагыз, дидем; һәм гөнаһ
кылучыларга: көчегез белән мактанмагыз. [6]Көчегез белән мактанып, горурланмагыз, һәм Алла
турысында дөрессезлек сөйләшмәгез, дидем. [7]Чөнки кояш чыгышында да, кояш баешында да,
чүлдәге тауларда да *Аннан качып калыр хәл юк*. [8]Чөнки Алла – Хөкем Итүче, берәүне төшерә,
һәм берәүне күтәрә. [9]Чөнки шәраб тулы касә Ходайның кулында, ул касәдәге шәраб су
катнаштырмаган, *әмма көчәйтә торган* катнашма катнаштырган, аны берәүдән берәүгә сона,
әмма аның әчесе кимемәс, анысын җирнең барча гөнаһлылары эчәрләр. [10]Мин исә Ягъкуб
Алласына гомергә сөенеп җырлармын. [11]“Һәм Мин гөнаһлыларның көчләрен бетерермен,
аннары гадел кеше куәтләнер”, *ди Алла*.

Җитмеш бишенче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Песнь. Псалом Асафа. Песнь об Ассириянине*

*(Ахырга. Җырлап. Асафның мәдхиясе. Ашшур кешесе турында җыр).*

[2]Алланы Яһүдиядә белеп торалар, Исраилдә Аның исеме олы. [3]Аның урны Салимда булган һәм
тора торган өе Сионда. [4]Анда Ул нык җәяләрне, сугыш коралларын, кылычны да, сугышны да
бетерде. [5]Син борынгы таулар өстеннән искитәрлек яктыртасың. [6]Күңелләре акылсызлар бар да
болганышып беттеләр, бай кешеләр бар да йокыга китеп, кулларында һичнәрсә дә тапмадылар.
[7]И Ягъкуб Алласы, Син кисәткәнлектән атта утыручылар йокымсырадылар. [8]Син бик
куркытырлык, һәм Сиңа каршы кем тора алыр? Теге чактан ачуың *күренде*: [9]күктән хөкемеңне
ишеттердең: [10]Алла җирдәге барча сабырларны коткарырга торгач, җир куркып тып-тын булды.
[11]Шуңа күрә кешеләр уйларында Сине данларлар, һәм бар уйлары белән Сине *кадерләп* бәйрәм
итәрләр. [12]Ходай Аллабызга инәлегез һәм вәгъдә иткәннәрегезне кылыгыз. [13]Башлыкларның
җаннарын алучы, җир патшаларына куркыныч, котчыгаргыч *Аллага* әйләнәсендәгеләр бар да
бүләкләр китерерләр.

Җитмеш алтынчы псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Чрез Идифума. Псалом Асафа*

*(Ахырга. Едутун өчен. Асафның мәдхиясе).*

[2]Авызым белән Ходайга дәштем, тавышым белән Аллага *инәлдем* – һәм Ул миңа аң салды.
[3]Кайгылы көнемдә Алланы эзләдем, төнлә дә кулларымны Аңа *күтәрдем* – һәм алданып
калмадым. Җанымны юаттырасым килмәде. [4]Алланы исемә алгач, сөенеп тордым, *үзалдыма
гына* исәпләгәч, җаным моңаеп торды. [5]Күзләрем каравылчыларныкыннан күбрәк
йомылмадылар, эчем пошты һәм сөйләшмәдем. [6]Әүвәлге көннәрне уйлап, борынгы гомерләрне
искә төшереп, өйрәндем. [7]Төнлә күңелемдә исәп тоттым һәм җаным көенде: [8]”Әллә Ходай *безне*

гомергә ташлар һәм тагы ризалык кылмас? [9]Әллә рәхимен бөтенләй өзәр? *Әллә* нәселдән нәселгә
сөйләшүен туктатыр? [10]Әллә Алла кызганасысын онытыр? Әллә ачуы килеп юмартлыгын
туктатыр?" *дидем.* [11]Аннары әйттем: "Менә хәзер болай үзгәрү Алланың уң кулыннан булганны
*аңлый* башладым", дидем. [12]Ходай эшләрен исемә төшердем, чөнки әүвәлге могҗизаларыңны
исемә китерермен. [13]Синең бар эшләреңнән өйрәнермен һәм бар кылмышларың турында
уйлармын. [14]И Алла, Синең юлың изгедә. Безнең Алла кебек, тагы нинди алла олы? [15]Син –
могҗизалар кылучы Алла, халыклар арасында куәтеңне күрсәткәнсең. [16]Халкыңны, Ягъкуб
белән Йосыф улларын Үз куәтең белән коткаргансың. [17]Сулар Сине күргәннәр, и Алла, сулар
Сине күреп куркышканнар, упкыннар кайнап торганнар. [18]Сулар бик каты шаулаганнар,
болытлар күкрәгәннәр, чөнки укларың алардан үтеп чыкканнар. [19]Күкрәгән тавышың күк
җәеменә җәелгән, яшеннәрең дөньяны яктыртып җибәргәннәр, җир какшап тетрәгән. [20]Синең
юлың диңгездән үткән, һәм сукмакларың күп сулардан *үткәннәр*, эзләреңне дә белерлек түгел.
[21]Мусаның һәм Һарунның куллары белән халкыңны, сарыкларны йөрткәндәй, йөрткәнсең.

Шөкер:

10-нчы кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 6-нчы көйгә.*

Синең киләсе куркынычлы көнеңнән котым чыгып куркамын, и Мәсих, һәм күндерә алмаслык хөкемеңнән куркып, и Ходай, гөнаһларым күп булганга күрә, котым чыгып калтырыйм. Әмма ахыры булганчы, рәхимле Аллага күрә, мине кайтарып коткар, и күп рәхимле Коткаручым.

Шөкер: Хөкем урнына тәхетләр куелгач, и Ходай, һәм хөкемең каршысына кешеләр килеп баскач, патша сугышчыдан олы булып саналмас, иясе колыннан алдынгы булмас, һәркем үз эшләреннән я данланыр, я хурланыр.

Әле дә: И Алла Анасы, иң таза Кыз, Син зур олылыкны алырга тиешле булгансың, чөнки Өчледән Берсен, терелек бирүче Мәсихне, җаннарыбызны коткарырга дип, тәнләндереп тудыргансың.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Ходай Аллабыз, Син рәхимеңә бай һәм юмартлыгыңны белеп җиткезер хәл юк, асылың буенча бер генә гөнаһсыз, һәм безнең өчен гөнаһтан тыш кеше булгансың. Минем шушы сәгаттә сызланып инәлгән авазымны ишет, чөнки мин яхшы эшләрдән ярлы һәм мескен, йөрәгем дә эчемдә каушады. Чөнки Син, и Югарыдагы Патша, күкнең һәм җирнең Ходае, бар яшьлегемне гөнаһлар эчендә үткәргәнлегемне беләсең. Тән нәфесләремнең юлыннан йөреп, җеннәргә көлке булдым, бөтенләй шайтанга ияреп, нәфесләр сазлыгында һаман саен аунап яттым. Бала чагыннан ук уйлавым белән караңгыланып, хәзергә чаклы беркайчан да Синең изге иркеңне кыласым килмәде, әмма миңа килә торган нәфесләр токкынына бирелеп, җеннәргә көлкегә һәм мыскылга калдым. Синең гөнаһлыларга кисәткән түзә алмаслык ачуыңны һәм җәһәнәмдәге утын да акылымда һич тә уйламадым. Шуннан өметем өзелеп һәм Сиңа кайту уенда булмый торып, Синең дуслыгыңнан буш һәм ялангач калдым. Гөнаһның нинди төрен мин кылмадым икән? Җеннең нинди эшен эшләмәдем икән? Нинди генә оят һәм азгын эшне тырышып һәм арттырып кылмый калдым икән? Акылымны тән нәфесләрен исемә китереп шакшыландырдым, тәнемне нәҗес кылдым, рухымны гөнаһка кушылу белән шакшыландырдым. Мескен тәнемнең һәр әгъзасы гөнаһка эшләп хезмәт итүне яратты. Һәм мин мескен өчен кем еламас? Мин, хөкем ителгән өчен кем үкермәс? Мин бер генә, и Иям, ярсуыңны кузгаттым, мин бер генә ачуыңны ялкынландырдым, мин бер генә Синең алдыңда яман эш кылдым, әүвәлдән үк булган гөнаһлыларны кылган гөнаһларым белән күп тапкыр уздым, чагыштыргысыз һәм кичерелмәслек гөнаһ кылып. Әмма Син күп рәхимле, игелекле күңелле, кеше сөюче булуыңа күрә, һәм кешеләрнең кайтуларын көтеп торасың икән, менә мин дә түзә алмаслык һәм куркынычлы хөкем урның алдына үземне саламын. Һәм Синең иң таза аякларыңа тиенгән кебек, күңелемнең тирән җиреннән Сиңа дәшәмен: и Ходай, тазарт, и игелеккә Алмаштыручы, кичер, хәлсезлегемне ярлыка, аптырашыма иелә күр, инәлгәнемә аң сал, һәм күз яшьләремә дәшми калма. Мине тәүбәгә килүчене кабул ит, һәм адашканны борып кайтар, кабат кайтучыны кочагыңа ал һәм дога кылучыга кичер. Тәүбәне гаделләр өчен куймагансың шул, гөнаһ кылмаучыларга кичерү куймагансың, әмма мин гөнаһлы өчен тәүбәне куйгансың. Синең ачуың

китереп, ялангач һәм чишенгән килеш Синең алдыңда басып торамын, и күңелдәгене күрүче
Ходай, гөнаһларымны әйтеп биреп. Гөнаһларым авырлыгыннан сыгылып, югары күккә таба
карый алмыйм да, аны күрергә хәлем дә юк. Шуңа күрә күңелемнең күзләрен яктырылдыр,
тәүбәгә килергә күңел йомшаклыгын һәм төзәлү өчен кайгылы рух миңа бир. Игелекле өмет
белән, һәм чын инану белән теге дөньяга барсам иде. Синең иң изге исемеңне, Атаны, һәм
Улны, һәм Изге Рухны һаман данлап һәм мактап торсам иде, әле дә, һәрчакта да, гомердән
гомергә, амин.

## Унберенче кафисма.

Җитмеш җиденче псалом (мәдхия).

*В научение. Асафа.*

*(Асафның нәсыйхәте).*

1Әй халкым, кануныма аң сал, авызымның сүзләренә колагыгызны салыгыз. 2Авызымны
мәсәлләр китереп сөйләргә ачармын, әүвәлгене төс китереп сөйләрмен. 3Үзебез ишеткәнне һәм
белгәнне, аталарыбыз да сөйләгәнне *әйтеп бирермен*. 4Ходай кылган могҗизаларны, Аның
куәтен һәм данын буласы нәселгә белдерә килеп, үз оланнарыннан яшереп калдырмаганнар. 5Ул
Ягъкубка боерыклар биргән һәм Исраилгә канун куйган: аталарыбыз үзләренә кушканны
улларына да әйтсеннәр дип, 6аны буласы нәсел, туасы уллар белсеннәр дип, алар тугач, үз
улларына да белдерсеннәр дип. 7Өметләрен Аллага салсыннар һәм Алла эшләрен
онытмасыннар, Аның боерыкларын да кылсыннар дип. 8Аталары кебек рәнҗетүчән каршы зат
булмасыннар, күңелен туры тотмаган һәм рухы белән Аллага ышанып тормаган зат кебек
*булмасыннар* дип. 9Эфраим уллары сугыш көнендә җәяләрен киереп ата-ата, кире качканнар.
10Аллага биргән вәгъдәләрендә тормаганнар һәм Аның кануныннан йөреселәре килмәгән.
11Аның кылган яхшылыкларын һәм күрсәткән могҗизаларын онытканнар: 12аталарының күз
алдында, Мисыр җирендә, Соган кырында Аның кылган могҗизаларын *онытканнар*. 13Диңгезне
аерып, аларны аның аркылы үткәргән: суларны турсык белән куйгандай, куйган. 14Көндез болыт
белән һәм төне буе ут яктысы белән аларны алып барган. 15Чүлдә ташны ярылдырган һәм бик
тирән судан эчерткәндәй, аларны эчерткән. 16Таштан су чыгарган һәм суларны инешләр кебек
агылдырган. 17Алай да *алар* Аллага тагы гөнаһ кылганнар: Югарыгыны сусыз җирдә
рәнҗеткәннәр. 18Җаннары теләгән ашамлыкны сорап, күңелләрендә Алланы сынаганнар.
19Аллага зарланып әйткәннәр: "Алла чүлдә аш әзерли алырмыни? 20Ташны ярса да, һәм сулар
аксалар да, инешләр ташысалар да, икмәк тә бирә алырмыни? Я Үз халкына аш әзерли
алырмыни?", дигәннәр. 21Шуңа күрә Ходай моны ишетеп, *аларны* яратмас булган:
Ягъкубныкылар арасында ут яна башлаган, һәм Исраилгә ачуы ялкынланган, 22чөнки алар
Аллага ышанмаганнар һәм Аның коткаруына өметләнмәгәннәр. 23Югартын болытларга боерган
һәм күкнең ишекләрен ачкан. 24Ашарларына аларга манна яудырган, һәм күк икмәген аларга
биргән. 25Адәм фәрештә икмәген ашаган, ашамлыкны аларга туярлык җибәргән. 26Күкне
төшлектән ачылдырып, куәте белән төшлек җилен истергән. 27Аннары аларга тузандай, күп ит
яудырган, һәм диңгез комыдай, күп канатлы кошлар *җибәргән*. 28Тора торган урыннарының
уртасына, чатырларының әйләнәсенә килеп төшкәннәр. 29Шуларны ашап, бик туйганнар, һәм
теләгәннәрен аларга китергән. 30Нәфесләре теләгәннән буш калмаганнар; ашамлыклары
авызларында чагында ук, 31аларга Алланың ачуы килеп, башлыкларын үтергән, һәм Исраилнең
сайланганнарын кырган. 32Шул эшләр булгач та, тагы да гөнаһ кылганнар һәм Аның
могҗизаларына ышанмаганнар. 33Көннәре бушта үтеп, гомерләре тиз югалган. 34Аларны үтергән
чакта, алар Аны эзләгәннәр, Аллага иртәдән үк тагы сыенганнар. 35Аларга булышучы Алла
икәнне һәм Югарыгы Алла аларны коткаручы икәнне исләренә китергәннәр. 36Авызлары белән
Аңа юмалаганнар һәм телләре белән Аңа ялганлаганнар. 37Күңелләре исә Аның алдында дөрес
булмаган һәм Аңа биргән сүзләрендә тормаганнар. 38Әмма Ул юмартлыгыннан аларның
гөнаһларын әрчегән, аларны бөтенләй бетермәгән; аларга килгән ачуын күп тапкыр
басылдырган һәм бөтен ачуын ялкынландырмаган. 39Аларның тән икәннәрен, бер киткәч, кире
кайтмый торган тын икәннәрен исенә алган. 40Ничә тапкыр Аны чүлдә рәнҗеткәннәр, сусыз
җирдә Аның ачуын китергәннәр! 41Янә тагы Алланы сынаганнар һәм Исраилнең Изгесен
ачуландырганнар. 42Ул аларны кысучының кулыннан коткарган көнне, күрсәткән куәтен
исләренә алмаганнар. 43Мисырда күрсәткән билгеләрне һәм Соган кырында кылган

могҗизаларны *исләренә алмаганнар*. [44]Мисырлылар эчә алмасыннар дип, инешләрен һәм
чишмәләрен канга алмаштырган. [45]Аларга йөдәткеч чебеннәр җибәргән, һәм аларны тешләп
бетергәннәр, һәм бакалар җибәреп, аларны шакшыландырган. [46]Ашлыкларын һәм җимешләрен
кортка, көчәнеп эшләгәннәрен саранчага ашаткан. [47]Йөзем агачларына боз суктырган һәм инҗир
агачларына кырау тидерткән. [48]Туарларына боз суктырган һәм малларын утка яндырткан.
[49]Аларга ачуын ялкынландырган, каты фәрештәләр аркылы ачу, һәм ярсу, һәм бәлаләр
җибәргән. [50]Ачуы барырга сукмак ясаган һәм җаннарын үлемнән коткармаган, аларның
туарларына да үләт тидерткән. [51]Мисырда элек туганнарны барын да үтергән, Хамныкылар
авылларында малларының иң яхшысын *кырылдырган*. [52]Үз халкын, сарыкларны торгызгандай,
торгызып йөрткән һәм көтү алып барган кебек, аларны чүлдән алып барган. [53]Аларны
ышанычлы алып йөргән, һәм курыкмаганнар, ә дошманнарын диңгез батырган. [54]Аларны
Үзенең изгелек тавына китергән, ул тауны Аның уң кулы тапкан. [55]Алар йөзеннән халыкларны
куып җибәргән, һәм җирләрен үлчәү җебе белән үлчәп, шобага салып, боларга биргән;
авылларына Исраил нәселләрен урнаштырган. [56]Тик алар Югарыгы Алланы сынап бик
рәнҗеткәннәр һәм боерыкларын тотмаганнар. [57]Аталары кебек *Алладан* авышып бизгәннәр,
кыек җәя кебек булганнар. [58]Түбә җирләрендә Аның ачуын китергәннәр һәм сыннары белән
Аның хәтерен калдырганнар. [59]Алла ишетеп, Исраилне яратмас булган, аны бик хурга
калдырган. [60]Кешеләр арасында торган урны – Шилоһтагы келәү чатырын ташлаган. [61]Аларның
ныкларын тоткынга биргән һәм юньлеләрен дошман кулына *тапшырган*. [62]Үз халкын кылычка
чабылырга калдырган һәм Үз өлешен яратмас булган. [63]Егетләрен ут ашаган, кызлары да
туйның елау җыруыннан буш калганнар. [64]Корбанчылары кылычтан егылганнар, һәм тол
хатыннары өчен елаучы булмаган. [65]Шуннан соң, шәраб эчеп йокыга киткәч, кызуланып торган
батыр кебек торып, [66]Ходай дошманнарын артларыннан куган, аларны гомергә хурга калдырган.
[67]Йосыф йортын чигергән, һәм Эфраим нәселен сайламаган. [68]Йәһүдә нәселен, Үзе сөйгән Сион
тавын сайлаган. [69]Җирдә келәү өен күктәге урны кебек торгызган, аны гомергә беркеткән. [70]Үз
бәндәсе Давытны сайлаган, һәм сарык көтүеннән аны кабул иткән; [71]Үз өлеше Исраилне һәм Үз
бәндәсе Ягъкубны көтеп йөртер өчен аны савым *терлекләр* арасыннан алып китергән. [72]Ул
аларны юаш күңел белән көтеп йөрткән, һәм куллары белән оста йөрткән.

Шөкер:

Җитмеш сигезенче псалом (мәдхия).

*Псалом Асафа*

*(Асафның мәдхиясе).*

[1]И Алла, мәҗүсиләр Синең җиреңә килделәр, Синең изге өеңне шакшыландырдылар.
[2]Иерусалимне буш алачык кебек иттеләр, бәндәләреңнең гәүдәләрен һава кошларына ашамлык
иттеләр, ярауларыңның тәннәрен җир киекләренә *ашаттылар*. [3]Аларның каннарын Иерусалим
әйләнәсендә су кебек койдылар, һәм аларны күмүче булмады. [4]Күршеләребезгә мыскылга,
әйләнәбездә торучыларга үртәләүгә һәм көлкегә калдык. [5]И Ходай, кайчанга чаклы туктаусыз
ачуланып торырсың? Ярсуың кайчанга чаклы ут шикелле ялкынланыр? [6]Сине белмәгән
халыкларга, һәм Синең исемеңә сыенмаган патшалыкларга ачуыңны кой. [7]Чөнки алар Ягъкуб
нәселен ашап бетерделәр һәм ул торган урны буш калдырдылар. [8]Элекке канунсызлык
кылганнарыбызны исеңә китермә, и Ходай, юмартлыгың безне каршы алсын, чөнки без бик
ябыктык. [9]И коткаручы Аллабыз, исемең данланыр өчен безгә булыш. И Ходай, Үз исемең
хакына безне коткар һәм гөнаһларыбызны әрче. [10]Мәҗүсиләр һичбер чакта: “Аларның Алласы
кая?” дип әйтмәсеннәр иде; һәм бәндәләреңнең каннарын түккәннәре өчен, мәҗүсиләргә үч
кайтарылу күз алдыбызда күренсен иде. [11]Богаудагыларның кайгырганы Синең алдыңа җитсен
иде, үтерелгәннәрнең улларын зур куәтең белән сакла. [12]И Ходай, күршеләребезгә, аларның
Сине хурлаган хурлаулары өчен, куеннарына җиде тапкыр кайтар. [13]Без исә Синең халкың һәм
көтүеңнең сарыклары, и Алла, Сине гомергә данлап сөйләрбез, Синең даныңны тумыштан
тумышка белдерербез.

Җитмеш тугызынчы псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Об имеющих измениться. Откровение. Асафа. Псалом.*

*(Ахырга.Үзгәрәселәр хакында. Шәһадәт. Асафның мәдхиясе).*

2И Исраилне көтеп Йөртүче, аң сал, сарыкны йөрткәндәй, Йосыфны алып Йөрүче, херувимнәр
өстендә Утыручы, күрен! 3Эфраим, һәм Беньямин, һәм Менашше алдында куәтеңне кузгалдыр
һәм безне коткарырга кил. 4И Алла, безне Үзеңә бор һәм йөзеңне яктырылдыр, һәм котылырбыз.
5И чирүләр Алласы Ходай, бәндәләрең догасына кайчанга чаклы ачулы торырсың? 6Кайчанга
чаклы безне күз яше катнашкан икмәк белән туйдырырсың һәм күз яшен безгә туйганчы
эчертерсең? 7Күршеләребезнең теленә безне калдырдың һәм дошманнарыбыз безне ярсыттылар.
8И чирүләр Алласы Ходай, безне Үзеңә бор, һәм йөзеңне яктырылдыр, һәм котылырбыз.
9Мисырдан йөзем агачын күчереп, халыкларны куып җибәреп, алар урнына аны утырткансың.
10Аның алдыннан юл башлап баргансың һәм тамырларын утырткансың, ул җирне тутырган.
11Күләгәсе тауларны каплаган, һәм учарлары Алланың әрбет агачларыннан узган. 12Үрентеләрен
диңгезгә чаклы һәм сарынтыларын инешләргә чаклы җәелдергән. 13Ник аның коймаларын
җимердең соң? Юл белән узучылар бар да аны өзеп-өзеп алалар. 14Урмандагы дуңгыз аның
тамырларын актарды, һәм кыр киеге яфракларын ашады. 15И чирүләр Алласы, инде борыл, һәм
күктән күз сал, шушы йөземгә килеп игелек ит. 16Уң кулың утыртканны булдырып җиткез, һәм
Үзеңә беркеткән Адәм Улына *игелек белән кара*. 17*Йөзем* утка яндырылган һәм казып
бетерелгән: каты каравыңнан юкка чыккан. 18Кулың уң кулың кешесе өстендә, һәм Үзеңә
беркеткән Адәм Улы өстендә торсын. 19Синнән бизмәбез, безне терелдерерсең, һәм Синең
исемеңә сыенырбыз. 20И чирүләр Алласы Ходай, безне Үзеңә бор, һәм йөзеңне яктырылдыр, һәм
котылырбыз.

### Сиксәнче псалом (мәдхия).

1*В конец. О точилах. Псалом Асафа*
*(Ахырга. Йөзем савытлары турында. Асафның мәдхиясе).*

2Булышучы Аллабызга сөенешегез, Ягъкуб Алласына сөенеп кычкырыгыз! 3Мәдхия алыгыз,
ямьле тавышлы саз белән гөслә һәм тимпан бирегез. 4Яңа ай башында, бәйрәмегез сөенеч
көнендә, быргы кычкыртыгыз. 5Чөнки Ягъкуб Алласының ирке һәм Исраилгә боеруы шулай.
6Моны, Йосыф Мисыр җиреннән чыккач, аңа белдергечкә куйган; шул чакта ул үзе белмәгән
телне ишеткән. 7*Алла* аның җилкәсеннән авыр йөкне төшергән, анда кулы тубал белән балчык
ташып талыккан икән. 8Кайгыңда Миңа дәштең, һәм сине коткардым, давыл эченнән сине
ишеттем, сүзгә китергән су янында сине сынадым. 9"Әй халкым, ишет, һәм сиңа таныклап куям,
әй Исраил, әгәр мине тыңласаң! 10Синең яңа аллаң булмасын, ят аллага табынма. 11Мисыр
җиреннән сине чыгаручы Ходай Аллаң – Мин шул: авызыңны ач, һәм аны тулы итәрмен".
12Алай да халкым авазымны тыңламады, һәм Исраил Миңа аң салмады. 13Шунлыктан аларны
күңелләре тартканга ирек җибәрдем: уйлаганнарына барсыннар. 14Әгәр дә халкым Мине
тыңлаган булса, Исраил Минем юлларымнан йөргән булса, 15аның дошманнарын һич нәрсәсез
юашландырыр идем һәм аларны рәнҗетүчеләрне кулым белән басар идем. 16Аның алдында
Ходайның дошманнары алданып калырлар иде, һәм имин торуы гомергә китәр иде. 17Тук бодай
төше белән аны туйдырыр идем һәм таштан бал чыгарып аны тукландырыр идем.

Шөкер:

### Сиксән беренче псалом (мәдхия).

*Псалом Асафа*
*(Асафның мәдхиясе).*

1Алла аллалар җыенында торып, аллаларны урталарында тикшерер. 2Кайчанга чаклы
дөрессезлек белән тикшереп гөнаһлыларны якларсыз? 3Үгине һәм мескенне яклагыз, юашка һәм
ярлыга дөреслек итегез. 4Ярлыны һәм мескенне аралап алыгыз, гөнаһлының кулыннан аны
котылдырыгыз. 5Моны белмәделәр, аңламадылар, караңгыда йөриләр; җирнең бар нигезләре
кузгалышсыннар иде. 6Мин әйттем: сез – аллалар, һәм барыгыз да – Югарыгының уллары.
7Әмма сез кешеләр үлгән кебек, үләсез, һәм башлыклар башлыкларыннан төшкән кебек,
төшәсез. 8И Алла, тор, дөньяны хөкем ит, чөнки Син бар халыкларны тотып торырсың.

### Сиксән икенче псалом (мәдхия).

1*Песнь-псалом. Асафа*
*(Асафның җыр-мәдхиясе).*

[2]И Алла, Сиңа кем охшашыр? И Алла, дәшми торма һәм сабырланма.[3]Чөнки менә дошманнарың
шаулаша башладылар һәм Сине күрәлмый торучылар башларын күтәрделәр. [4]Халкыңа явыз уй
белән яманлык иттеләр һәм изгеләреңә каршы киңәшләштеләр. [5]Алар әйткәннәр: “Килегез,
аларны халык арасыннан бетерик, һәм моннан болай Исраил исеме искә алынмасын”, дигәннәр.
[6]Бер уй белән бергәләшеп киңәшләшкәннәр, Сиңа каршы сүз куешканнар: [7]Эдом җирендәгеләр
һәм Исмаиллеләр, Моаб белән Һаҗәр нәселләре, [8]Гебал белән Аммон, һәм Амалик нәселләре,
Турда торучылар белән ят нәселләр *сүз куешканнар,* [9]аларга Ашшур да ияргән, алар бар да Лут
улларына булышканнар. [10]Мидьянга һәм Сисерага, Кыйшон суы буенда Ябингә кылганча,
аларга кыл; [11]Эн-Дорда бетерелеп, җиргә тирес булдылар. [12]Аларның башлыкларын, Ореб белән
Зиебны һәм Зебах белән Салмунны егылдырган кебек, егылдыр, бар башлыкларны да *егылдыр;*
[13]Алар әйткәннәр: “Алланың изге өен үзебезгә алыйк”, дигәннәр. [14]И Аллам, аларны әйләнә
торган тәгәрмәчтәй ит, җилдән тирбәнә торган камыштай ит. [15]Ут урманны өткән кебек, ялкын
тауларны яндырган кебек, [16]аларны да шулай давылың белән куарсың һәм ачуың белән аларны
болгатып бетерерсең. [17]Йөзләрен хурлыкка капландыр, и Ходай, һәм Синең исемеңне эзләрләр.
[18]Оялып гомердән гомергә болганышып бетсеннәр һәм, хурлыкка калып, юкка чыксыннар.
[19]Исемең – Ходай икәнне белсеннәр, бөтен җиргә Югарыгы Алла бер Син генә.

### Сиксән өченче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. О точилах. Сынам Кореевым. Псалом*

*(Ахырга. Йөзем савытлары турында. Корах уллары өчен. Мәдхия).*

[2]И чирүләр Ходае, Синең тора торган өең бик сөйкемле! [3]Җаным Ходай йортына үләрлек
булып, барасы килеп тора, күңелем дә, тәнем дә: тере Аллада булырбыз дип, сөенешеп торалар.
[4]Чөнки чыпчык та торыр урын табадыр, күгәрчен дә балалары торырга оя ясыйдыр, Синең
мәзбәхләрең *минем өчен шулай ук,* и чирүләр Алласы, и Патшам һәм Аллам. [5]Синең өеңдә
торучылар бәхетле: гомердән гомергә Сине мактарлар. [6]Яклаучысы Син булган кеше, *Сиңа*
баруны күңелендә тотучы, [7]елау үзәненнән Син кушкан төшкә баручы кеше бәхетле, чөнки
канун Куючы аңа игелек итәр. [8]Шундыйлар остарыдан-остара куәтләнерләр, Сионда *аларга*
аллаларның Алласы күренер. [9]И Ходай, чирүләрнең Алласы, догамны ишет, и Ягъкуб Алласы,
тыңла. [10]И безне яклаучы Алла, кара, һәм майлаганыңны карап күр. [11]Чөнки Синең өеңдә
үткәргән бер көн генә дә мең көннән артык: Аллам өенең ишеге төбендә генә торуны
гөнаһлылар өйләренең эчендә торудан бигрәк теләдем. [12]Чөнки Ходай рәхимне һәм чынны сөя,
Алла дәүләт һәм олылык бирер. Усаллыксыз йөрүчеләрне Ходай яхшылыктан буш итмәс. [13]И
чирүләр Алласы Ходай, Сиңа өметләнүче кеше бәхетле.

### Сиксән дүртенче псалом (мәдхия).

[1]*В конец. Сынам Кореевым. Псалом*

*(Ахырга. Корах уллары өчен. Мәдхия).*

[2]И Ходай, Үз җиреңә игелек итеп, Ягъкубны тоткыннан кайтаргансың. [3]Халкыңның
канунсызлык кылганнарын кичергәнсең, бар гөнаһларын бетергәнсең. [4]Ачуыңны бөтенләй
басылдыргансың, ярсулы ачуыңнан туктаткансың. [5]И Коткаручыбыз Алла, безне кайтар, һәм
ярсуыңны бездән читкә җибәр. [6]Әллә Син безгә гомергә ачуланып торырсың? Әллә ачуыңны
тумыштан тумышка тотарсың? [7]И Алла, борылып безне тергезерсең, һәм халкың Синең хакында
куаныр. [8]И Ходай, безгә рәхимеңне күрсәт һәм безне Үзең сакла. [9]Алла Ходай эчемдә ни
әйткәнне тыңлыйм әле: Ул Үз халкына, һәм яраулыларына, һәм Үзенә чын күңелләреннән
кайтучыларга тынычлык бирер. [10]Шулай, җиребезне данлыктырыр өчен, Үзеннән куркучыларны
тиз коткара. [11]Рәхим белән чынлык очрашканнар, дөреслек белән тынычлык бер-берсен
үбешкәннәр. [12]Чынлык җир өстеннән ялтыраган, һәм дөреслек күктән иелгән. [13]Чөнки Ходай
яхшылык итәр, һәм җиребез җимешен булдырыр. [14]Дөреслек Аның алдыннан килер, һәм
аякларын юлга бастырыр.

Шөкер:

11-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 7-нче көйгә.*

Әй җаным, тәүбә белән төзәлергә булган чакта, күз яшең белән килеп, кайгырып дәш: и җаннарны һәм тәннәрне Дәвалаучы, күп гөнаһларымнан мине бушайт, и адәмне Сөюче. Азгын хатынга, талаучыга һәм салым җыючыга мине дә кушылдыр, һәм канунсызлыкларым кичерүен миңа бүләк ит, и Алла, һәм коткар мине.

Шөкер: Салым җыючының тәүбәсенә көнчелегем килмәде, һәм азгын хатынныкы кебек күз яшем булмады; болар кебек төзәлергә сукыр булуымнан аптыраштa каламын, әмма Үзеңнең игелекле күңеллелегең белән мине коткар, и Мәсих Алла, Үзең кеше сөючегә күрә.

Әле дә: И тазадан таза Алланы тудырган Кыз, югарыгы чирүләр белән бергә Үз Улыңа инәл, ахыры булганчы, гөнаһларыбыз кичерүен һәм зур рәхимен безгә бүләк итсен иде.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И кеше сөюче Ходай, Синең Аллалыгыңны белүнең фанисыз яктысын безнең күңелләребездә яктырт, һәм күңел күзләребезне ачылдырып, Яхшы Хәбәреңнең сүзләрен аңлат. Бәхеткә китерүче боерыкларыңнан куркуны да эчебезгә сал, тән нәфесләрен барысын да басып бетереп, рухи тормыш белән торсак иде, Сиңа яраулы рәвештә уйлап та, эшләп тә. Чөнки Син җаннарыбызны да, тәннәребезне дә яктыртучы, и Мәсих Алла, һәм Сиңа дан китерәбез, була башлаусыз Атаң белән, һәм иң изге, һәм игелекле, һәм тере итүче Рухың белән, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

## Уникенче кафисма.

Сиксән бишенче псалом (мәдхия).

*Молитва Давида*

*(Давытның догасы).*

1 И Ходай, колагыңны салып, мине тыңла, чөнки мин ярлы һәм мескен. 2 Җанымны сакла, чөнки
мин яраулыны кылам, и Аллам, Сиңа өметләнүче бәндәңне коткар. 3 И Ходай, мине ярлыка,
чөнки көн буе Сиңа инәлеп дәшәм. 4 Бәндәңнең җанын сөендер, чөнки җанымны Сиңа күтәрдем.
5 Чөнки Син, Ходай, игелекле һәм сабыр, Сиңа инәлеп дәшүчеләрнең барысына да күп рәхимле.
6 И Ходай, догамны тыңла, инәлгән авазыма аң сал. 7 Син мине ишеткәнгә күрә, кайгылы көнемдә
Сиңа инәлеп дәштем. 8 И Ходай, аллалар арасында Сиңа охшаулысы юк, һәм эшләреңә караганда
да Сиңа охшаулы юк. 9 И Ходай, Син булдырган халыклар барысы да алдыңа килеп Сиңа
башырырлар, һәм исемеңне данларлар. 10 Чөнки Син олы, һәм могҗизалар кылучы, Син бер генә
Алла. 11 И Ходай, мине Үз юлыңнан йөрт, һәм чынлыгыңда йөрермен; исемеңнән куркып,
күңелем сөенсен иде. 12 И Ходай Аллам, бар күңелем белән Сиңа шөкер итәрмен, һәм исемеңне
гомергә данлармын. 13 Чөнки миңа кылган рәхимең зур һәм җанымны тәмугның иң төбеннән
коткардың. 14 И Алла, кануннан язучылар миңа карышып торалар, һәм көчлеләр җыелышып,
җанымны эзләделәр, һәм үз алларында Сине тотмадылар. 15 Тик Син, и Ходай Аллам, рәхимле
һәм юмарт, озак түзүчән һәм күп рәхимле, һәм чын. 16 Миңа күзеңне сал һәм мине ярлыка,
бәндәңә куәтеңне бир һәм бәндәңнең улын сакла. 17 Яхшылык билгесен миңа күрсәт: мине
яратмый торучылар *аны* күреп, оялсыннар иде, чөнки Син, Ходай, миңа булышып, мине
сөендердең.

Сиксән алтынчы псалом (мәдхия).

1 *Сынам Кореевым. Псалом песнь*

*(Корах уллары өчен. Җыр-мәдхия)*

2 Аның нигезләре изге таулар өстендә: Ходай Сион капкаларын Ягъкубның бар авылларыннан
артыграк сөя. 3 И Алла каласы, сине бик данландыра торган сүзләр әйтелгән. 4 Мине белүчеләр
арасында Раабны һәм Бабылны исемә алырмын. Менә ят нәселләр һәм Тур белән Хәбәш
кешеләре дә анда булгаладылар. 5 Сионны *һәр* кеше әни дип әйтер, һәм анда бер Кеше туган, һәм
Югарыдагы аны Үзе торгызган. 6 Ходай халыкларны һәм башлыкларны тикшереп язган язуда
анда туганнарны да язар. 7 Чөнки бар сөенүчеләрнең торыр җире синдә.

Сиксән җиденче псалом (мәдхия).

1 *Песнь-псалом. Сынам Кореевым. В конец. Радостная хоровая песнь.*
*Для ответа. В научение. Емана Израильтянина*

*(Җыр-мәдхия. Корах уллары өчен. Ахырга. Шатлыклы күмәк җыр.*
*Җавапка. Эзрах нәселеннән булган Һеманның нәсыйхәте).*
2И мине коткаручы Ходай Алла, көндез Сиңа инәлеп дәштем, төнлә дә Синең алдыңда булдым.
3Догам Сиңа җитсен иде, инәлүемә колагың сал. 4Чөнки җаным көек белән тулды һәм
тормышым тәмугка якынлашты. 5Кабергә төшерелә торганнарга тиң булдым, булышучысы юк
кеше кебек, 6үлекләр арасына озатылган кеше кебек булдым; үтерелеп, кабердә ятучылар кебек
булдым, Син инде аларны исеңә алмыйсың һәм кулыңнан борып аларны җибәргәнсең. 7Бик
тирән базга, караңгы төшкә һәм үлем караңгысына мине салдылар. 8Ярсуың миңа көчәйде, бар
дулкыннарыңны да миңа бәрелдергәнсең. 9Белешләремне янымнан ерак җибәрдең: алар миннән
җирәнделәр, тоткынга бирелдем һәм чыгар хәлем юк. 10Күектән күзләрем күрмәсләнде: и Ходай,
көн буе Сиңа инәлдем, кулларымны Сиңа күтәреп тордым. 11Үлекләргә могҗизалар
кылырсыңмыни? Я дәвалаучылар терелтеп, үлгәннәр Сине данларлармыни? 12Кабердә ятучы
*кеше* рәхимеңне һәм харап булган төштә *үлгән кеше* чынлыгыңны әйтә алырмыни?
13Могҗизаларың караңгыда беленермени? Һәм онытылган җирдә дөреслегең *күренермени*?
14Әмма мин, и Ходай, Сиңа инәлдем, иртәдән үк догам алдыңа барыр. 15И Ходай, җанымны
Үзеңнән ник куасың? Йөзеңне миннән ник борасың? 16Ярлы мин һәм яшьтән үк читенлектә
торам: данлыклы идем, кимгә калдым, хәлем дә бетте. 17Ачуларың өстемнән үттеләр,
куркытуларың мине йөдәттеләр: 18су шикелле мине чолгап алдылар, барысы да бергә көн буе
мине тотып тордылар. 19Кыенда торган чагымда дустымны һәм якынымны, белешләремне дә
янымнан ерак җибәрдең.

Шөкер:

Сиксән сигезенче псалом (мәдхия).
1*В научение. Ефама Израильтянина*
*(Эзрах нәселеннән булган Эйтанның нәсыйхәте).*
2И Ходай, рәхимнәреңне гомергә данлап җырлармын, чынлыгыңны авызым белән тумыштан
тумышка әйтермен. 3Чөнки Син әйткәнсең: “Рәхим гомергә китәр”, дигәнсең – чынлыгың
күкләрдә ныкланыр. 4”Сайлаганнарыма васыять куйдым, бәндәм Давытка ант иттем: 5нәселеңне
гомергә ныгытырмын һәм тәхетеңне тумыштан тумышка торгызырмын”, дидем. 6И Ходай,
могҗизаларыңны күкләр данларлар, чынлыгыңны изгеләр җыенында *сөйләрләр*. 7Чөнки
болытлар өстендәгеләрнең кеме Ходайга тиңләшә алыр? Алла улларының кайсысы Ходайга
охшашлы була алыр? 8Алла изгеләр җыенында данлаулы, әйләнәсендәгеләргә олы һәм
барысына да куркыныч. 9И чирүләр Алласы Ходай, Сиңа охшашырлык кем бар? И Ходай, Син
куәтле, һәм чынлыгың әйләнәңдә. 10Син диңгез куәтен тотып торасың, аның күтәрелә торган
дулкыннарын тыелдырасың. 11Син горурны яраланган кешедәй юашландыргансың,
дошманнарыңны куәтле кулың белән тараткансың. 12Күкләр дә Синеке, җир дә Синеке, дөньяны
да, аны тутырып торучыларны да Син булдыргансың. 13Төн ягы белән диңгез ягын Син
булдыргансың; Тавор белән Хәрмун Синең исемеңә сөенешерләр. 14Синең куәтең нык, кулың
куәтләнсен һәм уң кулың күтәрелсен! 15Дөреслек белән туры хөкем – тәхетеңнең ныклыгы:
рәхим белән чынлык йөзең алдыннан килерләр. 16Сөенеп кычкыруны белүче кешеләр бәхетле. И
Ходай, йөзеңнең яктысында йөрерләр, 17Синең исемеңә көн буе сөенешерләр һәм дөреслегең
белән күтәрелерләр. 18Чөнки куәтләрен макталдыручы – Син, һәм игелегең белән куәтебез
күтәрелер. 19Чөнки яклаучыбыз – Ходай, һәм Исраилнең Изгесе – патшабызны яклаучы. 20Бер
вакытта, улларыңа күренеп сөйләшкән чакта Син әйткәнсең: “Куәтлегә булыштым, халкым
арасыннан сайлаганымны күтәрелдердем: 21Үз бәндәм Давытны очратып, аны изге маем белән
майладым. 22Чөнки кулым аны яклар һәм куәтем аны ныгытыр. 23Дошман аңа бернәрсә дә кыла
алмас, һәм канунсызлыкның улы аңа усаллык тидерә алмас. 24Дошманнарын аның алдында
чабып өзәрмен һәм аны күрәлмый торучыларны кырып бетерермен. 25Чынлыгым һәм рәхимем
аның белән, һәм ул исемем белән куәтләнер. 26Кулын диңгезләр өстенә куярмын һәм уң кулын
иделләр өстенә *салырмын*. 27Ул Миңа инәлеп дәшәр: “Атам минем Син, Аллам һәм котылдыра
торган Яклаучым”, дияр. 28Һәм Мин аны иң олы итеп куярмын, җирдәге патшалардан да
артыграк күтәрелдерермен. 29Рәхимемне аннан гомергә алмам, һәм аңа биргән вәгъдәм дөрес
булыр. 30Нәселен гомердән гомергә сузармын, һәм тәхетен күктәге көннәр кебек *гомерлек
итәрмен*. 31Әгәр дә аның уллары канунымнан язсалар һәм Минем иркемнән йөрмәсәләр,
32дөресләндергечләремне бозсалар һәм боерыкларымны кылмасалар, 33канунсызлыклары өчен

аларга таяк белән килермен, һәм дөрессезлекләре өчен яралармын, [34]алай да рәхимемне алардан
алмам, чынлыгымны үзгәртмәм. [35]Куйган васыятемне бозмам һәм авызымнан чыккан сүзләрдән
танмам. [36]Бер тапкыр Үземнең изгелегемне алып ант иттем, Давытка ялганлармынмыни?
[37]Нәселе гомергә торыр, һәм тәхете алдымда кояш кебек [38]һәм тулы ай кебек, гомергә нык
торыр, һәм күктәге таныкчы *шуңа* туры", дигәнсең. [39]Тик инде Син, майлаганыңа ачуың килеп,
аны кимсеттең һәм борып җибәрдең. [40]Бәндәңә биргән васыятеңне боздың, җирдә аның изге
урнын кадерсезгә калдырдың. [41]Бар коймаларын җимердең, нык калаларының ныклыгын
бетердең. [42]Юлдан узучылар аны бөлдерделәр, күршеләренә ул көлкегә калды. [43]Аны
кысучыларның уң кулын куәтләндердең, бар дошманнарын сөендердең. [44]Кылычына булышмый
башладың һәм сугышта аны якламадың. [45]Якты данын аның алдың, тәхетен җиргә аудырдың.
[46]Гомер көннәрен кыскарттың, оятка аны калдырдың. [47]И Ходай, кайчанга чаклы бөтенләй
карамый торырсың? Ачуың кайчанга чаклы, ут кебек янып торыр? [48]Гомеремнең нәрсә икәнен
исеңә ал, әллә адәм улларын бушка гына булдырдың? [49]Кешеләр арасыннан берәү-берәү торып,
үлми калганы бармы? Үз җанын тәмуг кулыннан коткарганы бармы? [50]И Ходай, чынлыгың
белән ант итеп, Давытка әүвәл биргән рәхимнәрең кая соң? [51]И Ходай, күп халыклардан
бәндәләреңне кимсетүләрен, эчемдә тота торган хурлыкны исеңә ал; [52]дошманнарыңның
хурлаганнарын, и Ходай, майлаганыңның даны үзгәрүен хурлаганнарын исеңә ал. [53]Ходай
гомергә данлаулы. Амин, амин.

Шөкер:

Сиксән тугызынчы псалом (мәдхия).

[1]*Молитва Моисея, человека Божия*

*(Алла колы Мусаның догасы).*

[2]И Ходай, тумыштан тумышка сыендыручыбыз безгә Син булдың. [3]Таулар булганчы, дөнья да
булдырылмастан элек, гомердән гомергә Син бар. [4]"Әй адәм уллары, кире кайтыгыз", дип
әйтсәң дә, кешене юкка чыгарып бетермә. [5]Чөнки мең ел Синең күз алдыңда, и Ходай, кичәге
үткән көн чаклы генә, һәм төндәге сак чаклы гына. [6]Кешеләрнең гомерләре юк кына: иртә белән
яшәреп, чәчәк атып, кичкә таба шиңеп һәм коелып, корып беткән үлән кебек үтәрләр. [7]Чөнки
Синең ачуыңнан хәлебез бетте, һәм ярсуыңнан йөдәүгә калдык. [8]Канунсызлыкларыбызны
алдыңда тотасың, гомеребез йөзең яктысында *күренеп тора*. [9]Көннәребез кимеде һәм хәтерең
калганлыктан юкка чыктык. [10]Гомеребез, тожым өзелгәндәй, өзелеп китә; гомеребездә торган
яшебез җитмешкә чаклы, егәрле булсак, сиксәнгә чаклы җитә, ул гомер дә күбесенчә читенлектә
һәм сызлануда үтә; алай да алар безгә үгет биреп, безне сабыр итәләр. [11]Ачуың бик каты
килгәнне кем белеп җиткезсен? Һәм куркыткан чагыңда ярсуыңның чамасын кем исәпләп
җиткезсен? [12]Миңа *рәхимле* уң кулыңны, аннары күңелләрен хикмәт белән ныгытканнарны
күрсәт. [13]И Ходай, безгә кара, кайчанга чаклы *карамый торырсың*? Үз бәндәләреңне кызгана
күр. [14]И Ходай, иртә белән рәхимеңә тулыланып, сөенешеп куанышсак иде, [15]безне
юашландырган көннәрең өчен, безгә кыен күрсәткән көннәрең өчен, бар көннәребездә дә
сөенешсәк иде. [16]Үзең булдырган бәндәләреңә күз сал, һәм аларның улларын Үзең йөрт. [17]Безгә
Ходай Аллабызның яктылыгы булсын иде, һәм кулларыбыз эшләрен безгә яхшыга әйләндер,
кулларыбыз эшен яхшыга әйләндер.

Туксанынчы псалом (мәдхия).

*Хвалебная песнь. Давида. Не надписан у евреев*

*(Давытның мактау җыры. Гыйбриләрдә өстән язып куймаган).*

[1]Югарыгы *Ходай* булышып торган кеше күктәге Алланың бөркәве эченә урнашыр. [2]Ходайга
әйтер: "Яклаучым минем Син һәм сыендыручым, ышанып торган Аллам", дияр. [3]Чөнки Ул сине
тотарга йөрүченең тозагыннан һәм әләк сүздән коткарыр. [4]Җилкәсе белән сине каплап торыр,
һәм канатлары астында курыкмый торырсың, чынлыгы калкан кебек, сине ябып торыр. [5]Төндәге
куркынычтан, көндез атылып килгән уктан, [6]караңгыда була торган зыяннан, чирдән, һәм төш
вакытындагы җеннән курыкмассың. [7]Сул ягыңда меңләп егылырлар, һәм уң ягыңда ун меңләп
*кырылырлар*, сиңа исә якынлашмас та. [8]Тик күз салып кына, усалларга кайтарылганны күрерсең.
[9]Чөнки, "Син, Ходай, ышанып торганым" *дип әйтүең белән*, Югарыгыны сыендыручың иттең.
[10]Яманлык сиңа тимәс, һәм йортыңа авыру якынлашмас. [11]Чөнки Үз фәрештәләренә сине һәрбер
йөрешеңдә сакларга кушар. [12]Кулларына күтәреп сине алып барырлар, аягың ташка сөртенмәс.

[13]Аспид һәм василиск[7] *дигән еланнарны* яньчерсең, арысланны һәм аждаһаны таптарсың.
[14]"Миңа өмет иткәне өчен, аны коткарырмын, исемемне белгәне өчен, аны каплап торырмын.
[15]Миңа ялварса, аны ишетермен, кайгысында булышырмын, аны аралап алырмын һәм аны
данландырырмын, [16]аны күп яшәтермен һәм коткарганымны аңа күрсәтермен".

---

[7] Юха елан.

Шөкер:

12-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 7-нче көйгә.*

Азгын хатынның да, Петернең дә күз яшләрен кабул иткәнсең, и Ходай, һәм эч күңеленнән кайгырып инәлгән салым җыючыны да аклагансың; миңа да күңел йомшаклыгы белән егылып инәлүчегә юмартлык кыл, и Коткаручы, һәм мине ярлыка.

Шөкер: Салым җыючыны кабул иткәнең кебек, и Ходай, мине дә кабул ит, азгын хатынны тазартканың кебек, мине дә тазарт, и Иям, Кәнгандагы хатынны ярлыкаганың кебек, мине дә ярлыка, Үзеңнең олы рәхимең буенча.

Әле дә: И Яктының Анасы, Алланы тудырган данлаулы Кыз, Мәсих Аллага инәл, җаннарыбызга иртә таң белән бергә зур рәхимен яктыртсын иде.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Ходай Аллам, Син бер генә игелекле һәм кеше сөючe, бер генә рәхимле һәм сабыр, бер генә чын һәм гадел, бер генә юмарт һәм рәхимле Аллабыз. Мин гөнаһлы һәм яраусыз бәндәңә Синең куәтең килсен иде, һәм күңел өемне Яхшы Хәбәреңнең өйрәтүе белән ныгытсын иде. И Иям һәм кеше Сөюче, игелекле күңелле, минем эчемләрне дә, бар әгъзаларымны да Үз иркең белән яктырт; һәртөрле усаллыктан һәм гөнаһтан мине тазарт, шайтанның һәрбер эшеннән һәм миңа бәйләвеннән мине шакшысыз һәм бозылусыз килеш саклап тор. Үзеңнең игелегең хакына Сиңа яраулы итеп аңларга, уйларга, Син теләгәнчә тормыш итәргә, Синең куркытуыңнан куркынып торырга миңа бүләк ит. Ахыргы тыным чыкканчы, Сиңа яраулыны кылып торсам иде. Үзеңнең әйтеп бетерә алмаслык рәхимең хакына, җанымны да, тәнемне дә, акылымны һәм уйларымны, саклаган өй кебек, карышучыларның авыннан саклап тор. И Ходаем, и Ходай, Үзеңнең игелекле күңеллелегең белән мине ябып тор, һәм мин гөнаһлы да, шакшы да, тиешсез дә бәндәңне ташлама. Чөнки Син минем Яклаучым, и Ходай, һәм Синең турыда минем җыруым һаман. Һәм Сиңа дан китерәбез, Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

**Унөченче кафисма.**

Туксан беренче псалом (мәдхия).

[1]*Псалом песни. В день субботний*

*(Җыр-мәдхия. Шимбә көнне.)*

[2]Ходайны сөйләп данлау, и Югарыдагы, Синең исемеңә җырлау, [3]иртә белән рәхимеңне һәм төн
саен чыныңны әйтеп белдерү, [4]ун кыллы саз белән, гөслә белән җырлау – яхшы. [5]Чөнки
булдырган нәрсәләрең белән мине куандырдың, и Ходай, һәм кулларың эшләренә сөенермен.
[6]Эшләрең ни хәтле зурайдылар, и Ходай, Синең уйларың бик тирән. [7]Акылсыз кеше моны
белмәс һәм уйсыз кеше моны аңламас. [8]Үлән тишелеп үскән шикелле, гөнаһлылар, канунсызлык
кылучылар барысы да гомердән гомергә югалыр өчен күренеп үсәләр, [9]Син исә, и Югарыдагы
Ходай, мәңге. [10]Чөнки менә дошманнарың, и Ходай, менә дошманнарың юкка чыгарлар, һәм
канунсызлык кылучылар барысы да таралашып бетәрләр. [11]Ә минем куәтем бер мөгезле киекнең
мөгезе кебек күтәрелер, һәм картлыгым зәйтүн агачыдай яшәрер. [12]Күзем дошманнарның
*бетүен* күрер, һәм колагым миңа яманлык итеп каршы торучыларга *кайтарганны* ишетер.
[13]Гадел кеше хөрмә агачы кебек яшьнәп торыр, Ливан тавындагы эрбет агачы кебек үрчер.
[14]Ходай өендә утыртылып, Аллабызның йортларында яшьнәп торырлар. [15]Ямьле
картлыкларында да артырлар һәм рәхәтлектә торырлар. [16]Ходай Аллабызның турылыгын һәм
Аңарда турысызлык югын белдерерләр.

Туксан икенче псалом (мәдхия).

*В день перед субботой, когда населилась земля. Хвалебная песнь. Давида*
*(Шимбә алды көнне, җирдәгеләр булдырганнан соң. Давытның мактау җыры).*

1Ходай патшалык итә, олылык кигән, Ходай куәтне өстенә кигән һәм биленә чолгаган, шуңа
күрә дөньяны кузгалмаслык итеп беркеткән. 2Тәхетең әүвәлдән үк нык куелган: Син мәңгедән
бар. 3Инешләр шаулаганнар, и Ходай, инешләр каты шаулаганнар, 4күп сулар шаулаганда,
иделләр дулкыннарын күтәрелдерәләр: 5диңгезнең биек дулкыннары искиткеч, биектәге Ходай
бигрәк тә искитәрлек, 6әйткән сүзләрең бик дөрес. И Ходай, Синең өең гомергә изге булырга
тиеш.

Туксан өченче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. В четвертый (день) недели*
*(Давытның мәдхиясе. Чәршәмбе көнне).*

1Үч кайтаручы Алла – Ходай, үч кайтаручы Алла олылык белән күренгән. 2И дөньяны Хөкем
Итүче, күтәрел дә горурларга тиешлечә кайтар. 3Кайчанга чаклы гөнаһлылар, и Ходай, кайчанга
чаклы гөнаһлылар мактанышып торырлар? 4Кайчанга чаклы дөрес түгелне әйтеп сөйләрләр?
Канунсызлык кылучылар барысы да аны нигә чаклы сөйләшерләр? 5И Ходай, халкыңны
юашландырганнар һәм өлешеңә усаллык иткәннәр. 6Тол хатынны һәм үгине үләрлек иткәннәр
һәм читтән килгәнне дә үтергәннәр. 7Һәм әйткәннәр: “Ходай күрмәс һәм Ягъкуб Алласы
белмәс”, дигәннәр. 8Әй кешеләрнең акылсызлары, акылга килегез, әй уйсызлар, берчакта сез дә
уйга килегез. 9Колак бирүче ишетмимени? Я күзне булдыручы күрмимени? 10Халыкларга үгет
бирүче, кешене акылга өйрәтүче оялтмасмыни? 11Ходай кешенең шундый уйлары буш нәрсә
икәнен белә. 12Син акыллыландырасы кеше, и Ходай, һәм канунныңнан Син өйрәтәсе кеше
бәхетле. 13Шулай итеп, кыен көннәрендә аңа, гөнаһлыга баз казылганчы, тынычлык бирерсең.
14Чөнки Ходай Үз халкын борып җибәрмәс һәм Үз өлешен ташламас, 15дөреслек хөкемгә
кайтуга кадәр *ташламас*, һәм дөреслекне тотучы туры күңеллеләр *аны күрерләр*. 16Яманлык
итүчеләргә минем өчен кем каршы торыр? Я канунсызлык кылучыларга каршы минем яклы кем
булыр? 17Миңа булышучы Ходай булмаса, җаным тиз үк тәмугка төшәр иде. 18”Аягым авышты”
дигәч тә, и Ходай, рәхимең миңа булышты. 19Күңелемдә кайгыларым күбәйгән чакта,
юатуларың җанымны сөендерделәр. 20Канунсызлык кылучыларга, боерганны тотарга читенлек
кылучыларга Синең яныңда урын булмасын. 21Гаделнең җанын тотарлар һәм гаепсез канны
хөкем итәрләр. 22Әмма мине сыендыручы Ходай булды һәм Аллам ышанычлы булышучым
булды. 23Канунсызлыклары өчен Ходай аларга кайтарыр, һәм яманлыклары өчен Ходай
Аллабыз аларны юкка чыгарыр.

Шөкер:

Туксан дүртенче псалом (мәдхия).

*Хвалебная песнь. Давида. Не надписан у евреев*
*(Давытның мактау җыры. Гыйбриләрдә өстән язып куймаган).*

1Килегез, Ходайга сөенешик, коткаручы Аллабызга сөенеп дәшик. 2Аның йөзе алдына Аны
данлап барыйк, мәдхияләр җырлап, Аңа сөенеп кычкырыйк: 3Алла – олы Ходай һәм бөтен
җиргә олы Патша дип. 4Кырыйларыннан алып җир Аның кулында, һәм биек таулар да Аныкы
дип. 5Диңгез – Аныкы, аны Ул булдырган, һәм коры җирне дә Аның куллары булдырган дип.
6Килегез, Аңа егылып башырыйк, һәм булдыручы Ходаебыз алдында елашыйк. 7Чөнки Ул
безнең Аллабыз, һәм без Аның көтүенең халкы, кулының сарыклары. Ичмаса Аның тавышын
бүген тыңласагыз иде. 8*Ходай әйтә:* “Чүлдә Мине сынап, ачуымны китергән көннәрдәге кебек,
күңелләрегезне катыландырмагыз; 9анда аталарыгыз Мине сынадылар, Мине сынадылар, һәм
эшләремне күрделәр. 10Ул зат Мине кырык ел рәнҗетте, һәм әйттем: күңелләрендә һаман
саташалар, юлларымны белмәделәр. 11Шуңа күрә ачуым килеп, ант иттем, алар тынычлыгыма
кермәсләр, дидем”.

Туксан бишенче псалом (мәдхия).

*Хвалебная песнь Давида. Когда строился дом, после пленения. Не надписан у евреев*
*(Давытның мактау җыры. Әсирлектән чыккач, йорт салган чагында.*
*Гыйбриләрдә өстән язып куймаган).*

[1]Ходайга яңа җыру җырлагыз, Ходайга җирдәгеләр барыгыз да җырлагыз. [2]Ходайга җырлагыз,
Аның исемен данлагыз, Аның коткаруын көннән көнгә сөйләгез. [3]Халыклар арасында Аның
данын белдерегез, бар кешеләр арасында могҗизаларын *әйтегез*. [4]Чөнки Ходай олы һәм бик
мактаулы, аллаларның барысына да куркыныч. [5]Чөнки халыкларның аллалары барысы да –
җеннәр, ә Ходай күкләрне булдырган. [6]Аның алдында дан белән матурлык *тора*, изге өендә
изгелек белән ямьлелек *тора*. [7]Әй халык тумалары, Ходайга китерегез, Ходайга дан белән кадер
китерегез. [8]Ходайга, Аның исеменә дан китерегез, бүләкләр алып, Аның йортына керегез. [9]Изге
йортында Ходайга башырыгыз. Аның йөзе алдында бөтен җир калтырап торсын. [10]Халыкларга
әйтегез: Ходай патшалык итә, дөньяны кузгалмастай итеп нык беркеткән, дигез; Ул халыкларны
туры хөкем итәр. [11]Күкләр куансын һәм җир сөенсен, диңгез һәм аны тутырып тора торган
нәрсәләр кузгалышсыннар. [12]Басулар һәм андагылар барысы да сөенешсеннәр; урмандагы
агачлар барысы да куанышсыннар. [13]Ходай алдында һәммәсе дә куанышсыннар, чөнки Ул килә,
җирне тикшерергә килә; дөньяны гадел тикшерер һәм халыкларны чынлыгы белән хөкем итәр.

## Туксан алтынчы псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. Когда земля его устроялась. Не надписан у евреев*

*(Давытның мәдхиясе. Аның җире җайга салынганда. Гыйбриләрдә өстән язып куймаган).*

[1]Ходай патшалык итә, җир сөенсен, күп атаулар куанышсыннар! [2]Аның әйләнәсендә болыт
белән караңгы тора, дөреслек белән туры хөкем – тәхетенең төзеклеге. [3]Аның алдыннан ут
килеп, әйләнәсендәге дошманнарын көйдерер. [4]Яшеннәре дөньяны яктырткannar, *Аны күреп,*
җир калтырап торган. [5]Ходай йөзеннән таулар балавыз кебек эрегәннәр, бөтен җиргә Ходай
йөзеннән. [6]Күкләр Аның чынлыгын белдергәннәр, һәм бар халыклар олылыгын күргәннәр.
[7]Сыннарга табынучылар, сыннары белән мактанучылар барысы да оятка калсыннар. Әй
Ходайның фәрештәләре, барыгыз да Аңа башырыгыз. [8]Сион ишетеп сөенгән, и Ходай, кылган
эшләрең сәбәпле, Яһүдия кызлары куанышканнар. [9]Чөнки Син бөтен җиргә Югарыгы Ходай,
аллаларның барысыннан да бик югары күтәрелгәнсең. [10]Әй Ходайны сөючеләр, усаллыкны
яратмагыз! Ходай яраулыларының җаннарын саклый, гөнаһлының кулыннан аларны коткарыр.
[11]Гаделгә якты яктырган һәм күңелләре дөресләргә сөенеч килгән. [12]Әй гаделләр, Ходайга
сөенегез, һәм изгелеген искә алып сөйләгез.

Шөкер:

## Туксан җиденче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

[1]Ходайга яңа җыру җырлагыз, чөнки Ул искитәрлек эш кылган: аны[8] Аның уң кулы коткарган
һәм изге куәте *коткарган*. [2]Ходай Үзенең коткаруын белдергән, халыклар алдында дөреслеген
күрсәткән. [3]Үзенең Ягъкубка итәсе рәхимен һәм Исраил йортына кыласы чынлыгын исенә
алган: җирнең бар кырыендагылары да Аллабызның коткаруын күрделәр. [4]Җирдәгеләр барыгыз
да Аллага сөенеп кычкырыгыз, Аны данлагыз, һәм сөенешегез, һәм җырлагыз! [5]Ходайга гөслә
белән, гөслә белән һәм мәдхия авазы белән җырлагыз! [6]Патша Ходай алдында бакыр быргылар
кычкыртыгыз һәм мөгез быргылар авазын чыгарыгыз! [7]Диңгез дә, аны тутырып тора торган
нәрсәләр дә, дөнья да, анда торучылар барысы да кузгалышсыннар! [8]Инешләр бергәләшеп кул
чапсыннар, таулар да *Ходайның йөзе алдында* куанышсыннар. [9]Ходай алдында һәммәсе дә
куанышсыннар, чөнки Ул килә, җирне тикшерергә килә, дөньяны гадел тикшерер һәм
халыкларны чынлыгы белән хөкем итәр.

[8] Ягъни еврей халкын.

## Туксан сигезенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

[1]Ходай патшалык итә: халыклар калтырап торсыннар! Ул херувимнәр өстендә утыра: җир
тетрәсен! [2]Ходай Сионда олы, һәм бар халыклардан да югары. [3]Синең олы исемеңне бик
куркыныч һәм изге, дип әйтсеннәр. [4]Туры хөкемне сөю патшага кадер китерә. Син турылыкны
куйгансың, Ягъкубка дөрес хөкем биргәнсең. [5]Ходай Аллабызны күтәрегез һәм аягы астына

башырыгыз, чөнки ул изге. 6Муса белән Һарун Аның корбанчылары, Шемуил да Аның исеменә
сыенучыларның берсе: алар Ходайга инәлгәннәр, һәм Ул аларны ишеткән. 7Болыт баганасы
эченнән аларга сөйләгән, чөнки аларга биргән боерыкны һәм Аның кушканын тотканнар. 8И
Ходай Аллабыз, Син аларны тыңлагансың! И Алла, Син аларга рәхимле булгансың һәм аларны
бар эшләрендә яклагансың. 9Ходай Аллабызны күтәрегез һәм Аның изге тавында башырыгыз,
чөнки Ходай Аллабыз изге.

Туксан тугызынчы псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. Хвалебный.*

*(Давытның шөкраннар мәдхиясе).*

1Җирдәгеләр барыгыз да Аллага сөенеп кычкырыгыз. 2Ходайга сөенеп эшләгез, Аның алдына
куанышып барыгыз. 3Ходай безгә Алла икәнне белегез, безне Ул булдырган, ә үзебез түгел, без
исә Аның кешеләре һәм Аның көтүенең сарыклары. 4Аның капкасыннан данлый-данлый,
йортына җырлый-җырлый керегез; Аны сөйләп данлагыз, исемен мактагыз. 5Чөнки Ходай
игелекле, Аның рәхиме мәңге, чынлыгы да тумыштан тумышка.

Йөзенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

1И Ходай, рәхимне һәм дөреслекне әйтеп, Сиңа җырлармын! 2Җырлармын да шиксез юлны
исәпләрмен: миңа кайчан килерсең? Өем эчендә күңелемдә усаллык тотмый йөрдем. 3Канунга
каршы эшне күз алдымда тотмадым, канунга каршылык кылучыларны яратмадым. 4Кәкре
күңеллене үземә ияртмәдем, миннән китеп яманга авышучы белән белеш булмадым. 5Үз якынын
яшертен әләкләүчене үземнән кудым, горур күзле һәм туемсыз күңелле белән ашка утырмадым.
6Җирдәге гаделләрне яныма утыртырга күзләрем белән эзләдем; шиксез юлдан йөрүче миңа
хезмәт итте. 7Горур кыланучы өем эчендә тормады; яман сөйләүчене күз алдымда дөрескә
куймадым. 8Иртә саен җирнең гөнаһлыларын барысын да кырып бетергәләдем, канунсызлык
кылучылар барысы да Ходай каласында бетсеннәр иде дип.

Шөкер:

13-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 8-нче көйгә.*

Игелекле күңелле күзең белән юашлыгымны күр, и Ходай, чөнки гомерем аз-азлап кими бара, һәм кылган эшләремнән миңа котылу юк. Шуңа күрә инәләмен: игелекле күңелле күзең белән юашлыгымны күр, и Ходай, һәм коткар мине.

Шөкер: Хөкем Итүче алдында торган кебек, кайгырт, әй җаным, һәм куркыныч көннең сәгате турыда уйлап тор, чөнки рәхим кылмаган кешеләргә хөкем рәхимсез. Мәсих Аллага дәшеп әйт: и күңелдәгене Күрүче, гөнаһ кылдым, хөкем иткәнче, мине ярлыка.

Әле дә: Синең куркынычлы һәм дәһшәтле, һәм күндерә алмаслык хөкемеңнең көнен һәм сәгатен уема китереп, и Мәсих, явыз кебек калтырыйм. Оятлы һәм яман эшләрем бар шул, аларны бер мин генә тырышып кылдым. Шуңа күрә куркынып, Сиңа егылып, сызланып дәшәмен: Үзеңне Тудырганның догалары хакына, и күп Рәхимле, коткар мине.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И изге Ходай, югарыда торып, Үзеңнең үтә күрүчән күзең белән бар булдырган нәрсәләреңә дә карыйсың. Җаныбызның да, тәнебезнең дә муеннарын сыгылтып, и Изгедән Изге, Сиңа инәләбез: Үзеңнең тора торган изге урныңнан күренми торган колыңны суз һәм барыбызны да бәхилләә. Әгәр дә, Синең алдыңда иректән я ирексездән гөнаһ кылган булсак та, Үзең игелекле һәм кеше сөюче Аллага күрә, кичер, дөньядагы игелекләрен дә безгә бүләк итеп. Синеке шул, ярлыкарга да, коткарырга да, и Аллабыз, һәм Сиңа дан китерәбез, Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

**Ундүртенче кафисма.**

Йөз беренче псалом (мәдхия).

[1]*Молитва бедного, когда он унывает и изливает пред Господом моление свое*
*(Ходай алдында хәсрәтен сөйләп эчен бушаткан мазлумның догасы).*
[2]И Ходай, догамны тыңла, һәм үкерүем Сиңа җитсен иде. [3]Йөзеңне миннән борма: мин
кайгырган көнне миңа колагың сал, мин инәлеп дәшкән көнне мине тиз ишет. [4]Чөнки көннәрем
төтендәй үттеләр, һәм сөякләрем коры утын кебек киптеләр. [5]Үлән кебек киселдем, һәм йөрәгем
корыды, икмәк ашавым да исемнән китте. [6]Сулкылдап торганлыгымнан сөягем итемә ябышты.
[7]Чүлдәге кошка охшаштым, җимерелгән өйгә кереп тора торган ябалак кебек булдым.
[8]Йокламадым, өй түбәсендә бер башы утырган кош шикелле булдым. [9]Көн саен дошманнарым
мине хурладылар, һәм элек мине мактаучылар соңыннан каргадылар. [10]Икмәк урнына көл
ашадым һәм эчемлегемне яшь белән катнаштырдым. [11]Болар ачуыңнан һәм ярсуыңнан булды,
мине күтәреп бәрдең шул. [12]Гомерем күләгә кебек авышты, һәм үлән кебек корып беттем. [13]Син
исә Ходай мәңге торасың, һәм Сине искә алу тумыштан тумышка. [14]Син торып Сионны кызгана
күр, чөнки аны кызганырга вакыт инде, чөнки вакыт җиткән инде. [15]Чөнки бәндәләрең Сионның
ташларын да яратканнар һәм туфрагын да кызганышалар. [16]Ходай исеменнән халыклар һәм
Аның олылыгыннан җир патшалары барысы да куркышырлар. [17]Чөнки Ходай Сионны торгызыр
һәм олылыгы белән күренер. [18]Юашларның догасына күз салган һәм инәлүләрен ким күрмәгән.
[19]Бу эш киләсе тумышка язылып калсын, һәм буласы халыклар Ходайны мактарлар. [20]Чөнки
Ходай югарыгы олы урныннан иелеп караган, күктән җиргә күз салган, [21]богаудагыларның
кайгыруын ишетер өчен, үтерелгәннәрнең улларын чишеп җибәрер өчен, [22]Сионда Ходай
исемен һәм Иерусалимдә Аның данын белдерсеннәр дип. [23]Ул чакта халыклар һәм патшалар
Ходайга табынырга бергә җыелырлар. [24]Куәтле *булган* чагында ул Аңа әйтте: “Гомеремнең
кайчан бетәрен миңа белдер. [25]Гомеремнең яртысында мине ала күрмә”, диде. Син Үзең
тумыштан тумышка торасың: [26]баштан ук Син Ходай җирне коргансың һәм күкләр дә Синең
кулларыңның эшләре. [27]Алар бетәрләр, Син исә шул көе торасың, һәм бар да кием шикелле
тузарлар, аларны кием кебек төрерсең, һәм үзгәрерләр. [28]Әмма Син гел шул көе торасың, һәм
гомерең бетмәс. [29]Бәндәләреңнең уллары торырлар, һәм нәселләре гомергә төзек торырлар.

Йөз икенче псалом (мәдхия).
*Псалом Давида*
*(Давытның мәдхиясе).*
[1]Әй җаным, Ходайны данла, һәм күңелем, Аның изге исемен олыла! [2]Әй җаным, Ходайны данла
һәм сиңа кылган бар игелекләрен онытма: [3]Ул сиңа булган гөнаһларыңны кичерә, бар
авыруларыңны савыктыра, [4]бетүдән сине коткара, игелеге һәм рәхиме белән сине ябып тора,
[5]теләгеңне игелек белән булдыра, яшь куәтең бөркетнеке кебек яңарыр. [6]Ходай золымлык
күрүчеләрнең барысына да рәхимне һәм гаделлекне кыла. [7]Үз юлларын Мусага күрсәткән,
Исраил улларына Үз иркен белдергән. [8]Ходай юмарт һәм рәхимле, озак түзүчән һәм күп
рәхимле. [9]Ачуын һаман тотмас һәм хәтерен гомергә калдырмас. [10]Канунсызлыкларыбызга карап
безгә кылмады, һәм гөнаһларыбызга карап безгә кайтармады. [11]Җирдән күк ни хәтле ерак, шул
хәтле Ходай Үзеннән куркучыларга рәхимен күрсәтте. [12]Кояш баешыннан кояш чыгышы ни
чаклы ерак, шул чаклы канусызлыкларыбызны бездән ерак итте. [13]Ата үз улларын кызганган
кебек, Ходай Үзеннән куркучыларны кызганды. [14]Чөнки Ул безнең нидән булганыбызны
беләдер, туфрак икәнебезне онытмый. [15]Кеше үләнгә охшаулы: кырдагы чәчәк тиз чәчәк атып
бетергән кебек, аның гомер көннәре *тиз* үтәләр. [16]Рухы чыкты икән, ул тормас, торган урнын да
танымас. [17]Ходайның рәхиме исә Үзеннән куркучыларга гомердән гомергә бетми тора.
[18]Дөреслеге дә Аның васыятен саклап, боерыкларын кылуны истә тотучыларның улларының
улларында тора. [19]Ходай Үз тәхетен күк өстенә корган, һәм патшалыгы бар нәрсәне дә тотып
тора. [20]Әй нык көчле фәрештәләр, Ходай сүзен тыңлап кылучылар, барыгыз да Ходайны
данлагыз. [21]Әй Ходайның бар чирүләре, Аның хезмәтен итүчеләре, иркен кылучылары,
Ходайны данлагыз. [22]Әй Ходай булдырган нәрсәләр, Ходай кодрәтендәге һәрбер җирдә барыгыз
да Аны данлагыз. Әй җаным, Ходайны данла.

Шөкер:

Йөз өченче псалом (мәдхия).
*Псалом Давида о бытии мира*
*(Дөнья яшәеше хакында Давытның мәдхиясе).*

[1]Әй җаным, Ходайны данла! И Ходай Аллам! Син бик олы, данга һәм ямьлелеккә киенгәнсең.
[2]Син, кием кебек, өстеңә яктыны киеп торасың, күкне чатыр кебек корып торасың. [3]Югарыгы
урыннарыңны су белән ябып торасың, болытларны Үзеңә арба кебек итәсең, җил канатлары
белән очып йөрисең. [4]Фәрештәләреңне рух кебек итеп һәм хезмәт итүчеләрне ялкын ут кебек
итеп йөртәсең. [5]Җирне нигезләренә беркеткәнсең: ул гомердән гомергә авышмас. [6]Төпсез сулар
аны кием кебек чолгап торалар, таулар өстендә дә сулар тора. [7]Син кисәткәнлектән агып
китәрләр, күкрәгән тавышыңнан куркышырлар. [8]Таудай күтәрелеп, үзәндәй *тирән* төшеп
китсәләр дә, үзләренә дип Син куйган урында калалар. [9]Аларга чик куйгансың, шуннан чыкмый
торалар һәм кайтып җир өстен басмыйлар. [10]Елгалардан чишмәләр агызасың, таулар арасыннан
сулар ага. [11]Кыр киекләрен барысын да эчерәләр, кыр ишәкләре эчеп сусаганнарын бетерәләр.
[12]Сулар янында һава кошлары оялап торалар, ташлар арасыннан сайраганнары ишетелә.
[13]Югарыгы урыннарыңнан *су яудырып*, тауларга эчерәсең: үстергән җимешләрең белән
җирдәгеләр туеналар. [14]Туарларга үләннәр һәм кешеләргә ашамлыкка җирдә ашлыклар
үстерәсең. [15]Шәраб да кешенең күңелен сөендерә, май аның йөзен ялтырата. Икмәк тә йөрәген
ныкландыра. [16]Кырдагы агачлар, Син утырткан Ливан тавының эрбет агачлары яшьнәп үсәләр,
[17]алар өстендә кошлар оялый, барысыннан да югары челән оялап тора. [18]Биек тауларда
боланнар, ташлар арасында куяннар сыенып торалар. [19]Вакытларны белергә айны
булдыргансың, кояш үзе байый торган урнын беләдер. [20]Караңгыны җибәрәсең, шуннан төн
була, төнлә урмандагы бар киекләр чыгып йөриләр. [21]Яшь арысланнар акырышып җим эзлиләр
һәм Алладан ашарларына сорыйлар. [22]Кояш чыккач, алар җыелышып, үз өннәренә кайтып
яталар. [23]Аннары кеше үз эшенә чыгып, кичкә чаклы эшләп йөри. [24]И Ходай, эшләрең ни хәтле
олы! Барын да бик белеп булдыргансың. Булдырганнарың белән җир өсте тулган. [25]Менә олы
һәм киң диңгез, анда шуышып йөри торган исәпсез күп җәнлекләр, олы белән кече җәнлекләр
бар. [26]Анда зур көймәләр йөзәләр, Син булдырган зур елан уйнаклап йөри. [27]Барысы да вакытлы
вакытында ашамлык бирерсең дип, Синнән көтеп торалар. [28]Аларга бирсәң, җыеп алырлар,
кулыңны ачсаң, барысы да игелеккә туенырлар. [29]Йөзеңне борсаң, йөдәшерләр: рухларын
чыгарсаң, юкка чыгып, үз туфракларына кайтырлар. [30]Рухыңны җибәрсәң, тагы терелерләр, һәм
җирнең йөзен яңартырсың. [31]Ходайның даны гомергә торсын! Ходай Үз эшләренә сөенсен!
[32]Җиргә күзен салса, җирне тетрәтә, тауларга тиенсә, алар төтенләнәләр. [33]Гомеремдә Ходайны
данлап торырмын, үзем торган тиңенте Алламны олылармын. [34]Бу сөйләвем Аңа татлы тисен,
мин исә Ходайга куанырмын. [35]Гөнаһлылар җир өстендә бетсеннәр иде, һәм канунсызлык
кылучылар һич тә булмасыннар иде. Әй җаным, Ходайны данла!

Шөкер:

Йөз дүртенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя[9]).*

[1]Ходайны сөйләп данлагыз һәм Аның исеменә сыеныгыз, халыклар арасында Аның эшләрен
белдерегез. [2]Аны данлагыз һәм Аңа җырлагыз, Аның бар могҗизаларын сөйләгез. [3]Аның изге
исеме белән мактаныгыз, Ходайны эзләүчеләрнең күңелләре куансын. [4]Ходайны эзләгез һәм
ныгыгыз, Аның йөзен һаман эзләгез. [5]Аның кылган могҗизаларын исегезгә китерегез, Аның
могҗизаларын һәм авызыннан чыккан боерыкларын *искә алыгыз*. [6]Ибраһим нәселе – Алла
бәндәләре, Ягъкуб уллары – Аның сайлаганнары! [7]Ул – безнең Ходай Аллабыз, бөтен җир
өстендә Аның боерыгы. [8]Үзенең мәңге васыятен, мең тумышка әйткән сүзен, [9]Ибраһимга биргән
сүзен һәм Исхакка ант итеп әйткәнен исендә тота; [10]аны Ягъкубка боерык итеп һәм Исраилга
мәңгегә васыять итеп куйган: [11]"Өлешегезгә аерасы Кәнган җирен сиңа бирермен", дигән.
[12]Алар ул чагында аз икән, кечкенә генә һәм анда читтән килүче генә икән. [13]Халыктан халыкка
һәм бер патшалыктан икенче кешеләргә күчеп йөргәннәр. [14]Аларны кыерсытырга берәүгә дә
ирек бирмәгән һәм алар өчен патшаларга кыен тидергән: [15]"Майлаганнарыма тимәгез һәм
пәйгамбәрләремә уссалык итмәгез", дигән. [16]Җиргә ачлык җибәргән: җирдә ныкландыра торган
һәрбер ашлыкны бетергән. [17]Алардан элек бер кешене җибәргән: Йосыф коллыкка сатылган.
[18]Аякларын богаулап кысканнар, [19]сүзе килеп җиткәнче, тимердән җаны интеккән, Ходай сүзе
аны ялкынландырган. [20]Патша, җибәреп, аны чиштергән, халыклар башлыгы аны иркенгә

[9] Ходайны данлагыз!

чыгарган. [21]Аны үз өенә ия итеп куйган һәм үзенең бар малына башлык итеп куйган, [22]аның
башлыкларын һәм олыларын үз хикмәтенә өйрәтсен дип. [23]Аннары Исраил Мисырга кергән, һәм
Ягъкуб Хам җиренә килеп урнашкан. [24]*Алла* Үз халкын бик үрчеткән һәм аны дошманнарыннан
куәтлерәк иткән. [25]Аларны Үз халкына күрәлмаучы күңелле иткән, Үз бәндәләренә каршы
алардан хәйлә кордырган. [26]Үз бәндәсе Мусаны, Үзе сайлаган Һарунны җибәргән. [27]Аларга Хам
җирендә Үзенең билгеләрен һәм могҗизаларын *күрсәтергә* кушкан. [28]Аның сүзләренә каршы
торганнарына күрә, караңгы җибәреп, *көнне* караңгыландырган. [29]Суларын канга алмаштырган
һәм балыкларын үтереп бетергән. [30]Җир өсләрендә, патшаларның пулатларында да бакалар
кайнаган. [31]Ул әйткәч тә, йөдәткеч чебеннәр чыккан һәм бар тирәләренә черкиләр килгән.
[32]Яңгырларын бозга алмаштырган, җирләренә көйдерә торган ут җибәргән: [33]йөзем агачларын
һәм инҗир агачларын корыткан, алар тирәсендәге һәртөрле агачны ватып бетергән. [34]Ул әйткәч
тә, саранча һәм исәпсез күп кортлар килгәннәр: [35]җирләрендәге үләнне ашап бетергәннәр, һәм
басуларындагы бар җимешләрен да ашаганнар. [36]Алар җирендә элек туганнарны барын да
үтергән, малларының иң яхшысын *кырылдырган.* [37]Исраил нәселен алтынлы һәм көмешле итеп
чыгарган, алар затында берәү дә чирләмәгән. [38]Мисырга бик куркыныч төшкән, шунлыктан ул
алар чыкканга сөенгән. [39]Аларны бөркәп барырга болыт җәйгән, һәм төнлә яктыртырга аларга ут
*куйган.* [40]Алар сорагач, бытбылдыклар очып килгәннәр, һәм Исраилләрне күк икмәге белән
туйдырган. [41]Ташны ярылдырып су агызган, коры җирдән инешләр акканнар. [42]Чөнки Үз
бәндәсе Ибраһимга әйткән изге сүзен исенә төшергән. [43]Үз халкын сөендереп һәм
сайлаганнарын күңеллеләндереп чыгарган. [44]Аларга ят халыкларның җирләрен биргән, һәм чит
кешеләр эшләгәнгә ия булганнар, [45]Ул кушканны кылсыннар дип, һәм канунын тотсыннар дип.

Шөкер:

14-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 8-нче көйгә.*

Гөнаһларым кичерүен алсам иде дип, азгын хатын кебек Сиңа егыламын, һәм миро урнына эч күңелемнән күз яшләрен Сиңа китерәмен, и Мәсих Алла. Аңа юмартлык кылганың кебек, миңа да кыл, и Коткаручы, һәм гөнаһларым тазартуын бир; теге хатын кебек, мин дә Сиңа дәшәмен: эшләрем сазлыгыннан мине коткарып чыгар.

Шөкер: Әй җаным, нишләп үләсеңне исеңә китермисең? Нишләп, хөкемдә быргы кычкыртканчы, төзәлүгә таба борылмыйсың? Ул чакта тәүбәгә килергә вакыт юк ич. Салым җыючыны да, азгын хатынны да уеңа китер, болай дәшә торганнарны: Сиңа гөнаһ кылдым, и Ходай, мине ярлыка, дип.

Әле дә: Чынлап та тудыруың белән күктәге чирүләр рәтләреннән олырак күтәрелгәнсең, и һаман Кыз көе торучы, Алланы Тудыручы, Синең аркылы Аллалык белән баеп киткәнбез, туктаусыз Сине олылыйбыз.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

Сиңа шөкер итәбез, и безне коткаручы Ходай Аллабыз, чөнки Син барысын да тормышыбызга игелек булсын дип, кыласың. Узган төннең вакытында безне тынычландыргансың, яткан урныбыздан безне торгызгансың, Синең кадерле һәм данлаулы исемеңә башырырга дип, безне бастырып куйгансың. Шуңа күрә Сиңа инәләбез, и Ходай: безгә дәүләт һәм куәт бирсәнә, Сиңа, аңлы итеп, җырласак иде, һәм туктаусыз инәлсәк иде; Сиңа таба, безнең Коткаручыга һәм җаннарыбызга игелек Кылучыга, һаман көе карап торсак иде, куркынып һәм калтыранып котылу эшен кылып торып. И игелекле Күңелле, безне ишет һәм ярлыка, күренми торган дошманнарыбызны һәм безгә ябышучыларны аягыбыз астына егылдыр. Хәлебезгә күрә китергән шөкеребезне кабул ит, авызыбызны ачарга дип, безгә дәүләт һәм куәт бир, дөресләндергечләреңә дә безне өйрәт. Чөнки, ни дип дога кылырга да белмибез, әгәр Син, и Ходай, Үзеңнең Изге Рухың белән безне өйрәтмәсәң. Әгәр дә, шушы сәгаткә чаклы сүз белән, я эш белән, я уй белән, иректән я ирексездән гөнаһ кылган булсак та, безгә ташла, чиш, кичер. Әгәр канунсызлыкларыбызны тикшерсәң, и Ходай, и Ходай, кем чыдап тора алыр? Чөнки Синдә тазарту бар, Синдә йолып алу. Син бер генә изге, нык булышучы, һәм тормышыбызны яклаучы, һәм Сине данлыйбыз гомергә, амин.

**Унбишенче кафисма.**

Йөз бишенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

[1]Ходайны сөйләп данлагыз, чөнки Ул игелекле, чөнки рәхиме мәңге. [2]Ходайның кодрәтләрен
кем әйтеп бетерә алыр? Аның бар данын кем ишеттерә алыр? [3]*Туры* хөкемне тотучылар һәм
һәркайчан дөреслек кылучылар бәхетле. [4]И Ходай, халкыңа ризалык иткән чакта, безне исеңә ал,
безне килеп сакла, [5]сайлаганнарыңның игелекле тормышларын күрсәк иде, халкың сөенгәндә
сөенсәк иде, халкың белән бергә мактансак иде. [6]Аталарыбыз белән бергә гөнаһлы булдык,
канунсызлык кылдык, дөрессезлек кылдык. [7]Аталарыбыз Мисырда могҗизаларыңны
аңламаганнар, күп рәхимнәреңне исләрендә тотмаганнар һәм Кызыл диңгезгә җиткәндә *Сине*
рәнҗеткәннәр. [8]Әмма Ул Үзенең куәтен күрсәтер өчен, Үз исеме хакына аларны коткарган.
[9]Кисәтеп әйтүе белән Кызыл диңгез кипкән, һәм чоңгылдан, коры җирдән чыгарганча, аларны
чыгарган. [10]Күрәлмаучыларның кулыннан аларны саклаган, һәм дошманнар кулыннан аларны
коткарган. [11]Аларны кысучыларны су баскан: берсе дә калмаган. [12]Аның сүзенә ышанып, Аны
данлап җырлаганнар. [13]Алай да Аның эшләрен тиз онытканнар, Аның рөхсәтен көтмәгәннәр.
[14]Чүлдә нәфесләре яратканны теләгәннәр һәм сусыз төштә Алланы сынаганнар. [15]Сораганнарын
аларга биргән, җаннарын туендырган. [16]Туктаган станнарында Мусаның, Ходай корбанчысының
Һарунның ачуын китергәннәр. [17]Җир ярылып Датанны йоткан һәм Абирам җыенын упкан.
[18]Алар җыенында ут ялкынланган, гөнаһлыларны ялкын көйдергән. [19]Хореб *тавы* янында бозау
сыны ясаганнар да шул сынга башырганнар. [20]Алла данын үлән ашый торган бозау охшашына
алыштырганнар. [21]Үзләрен Саклаучыны, Мисырда зур эшләр кылучыны онытканнар, [22]Хам
җирендә могҗизалар, Кызыл диңгездә куркыныч эшләр кылучы Алланы *онытканнар*. [23]Сайлап
алган Мусасы Аның алдында кайгырып торып, аларны бетермә дип, Аның ачуын
басылдырмаган булса, Ул аларны кырып бетерәсе икән. [24]Һәм теләгән җирләрен яманлаганнар,
Алла сүзенә ышанмаганнар. [25]Үз чатырларында зарланганнар, Ходай авазын тыңламаганнар.
[26]Һәм аларга Үз кулын күтәргән, аларны чүлдә бетерим дип, [27]халыклар арасында алар нәселенә
кимчелек китереп, аларны төрле якка таратыйм дип. [28]Багал-Пигур *дигән сынга* табынганнар,
һәм җансызларга китергән корбанны ашаганнар. [29]Үз эшләре белән Алланы рәнҗеткәннәр,
шуннан соң аларга бик каты үләт ябышкан. [30]Пинхәс торып, *Алланың* күңелен йомшаткан,
аннары үләт басылган. [31]Аның бу эше дөрес эшкә саналып, нәселдән нәселгә гомергә калган.
[32]Су өчен зарланып Алланың ачуын китергәннәр, һәм Муса алар хакына кайгы күргән: [33]чөнки
аның җанын рәнҗеткәннәр, һәм авызыннан чыккан сүзләргә шикләнгән. [34]Ходай бетерергә
кушкан халыкларны бетермәгәннәр. [35]Әмма мәҗүсиләр белән кушылышып, алар эшләренә
күнеккәннәр. [36]Аларның сыннарына табынганнар, һәм шул аларны харап иткән. [37]Үз улларын
һәм кызларын җеннәргә корбанга китергәннәр. [38]Кәнган сыннарына китергән улларының һәм
кызларының гаепсез каннарын түккәннәр; шул кан аркылы җирләре үчеләнгән, [39]эшләреннән
шакшыланган, һәм үз кылмышлары белән азгынлык кылганнар. [40]Ходайның Үз халкына бик
каты ачуы килгән, һәм Үз өлешеннән җирәнгән. [41]Аларны дошманнар кулына тапшырган, һәм
аларны күрәлмый торучылар аларны үз кулларына алганнар. [42]Дошманнары аларны кысканнар,
һәм куллары астында юашланганнар. [43]Ул аларны күп тапкыр коткаргалаган, әмма алар
каршылыклары белән Аны рәнҗеткәннәр һәм канунсызлыклары аларны юашландырган. [44]Алай
да кайгырган чакларында Ходай аларны күргән, инәлгәннәрен ишеткән. [45]Үз васыятен исенә
алган, һәм күп рәхимлегә күрә аларны кызганган. [46]Аларны тоткынга алучыларның барысыннан
да аларны кызгандырган. [47]И Ходай Аллабыз, безне сакла, һәм халыклар арасыннан безне җый,
Синең изге исемеңне данласак иде, Синең даның белән мактансак иде. [48]Исраил Алласы Ходай
гомердән гомергә данлаулы. Һәм бар халыклар әйтерләр: амин, амин.

Шөкер:

Йөз алтынчы псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

[1]Ходайны сөйләп данлагыз, чөнки Ул игелекле, чөнки рәхиме мәңге. [2]Ходай коткарганнар,
дошманнар кулыннан Ул коткарганнар шулай әйтсеннәр; [3]төрле яклардан: кояш чыгышыннан

һәм кояш баешыннан, төн ягыннан һәм диңгез ягыннан җыйганнары да *шулай әйтсеннәр*.
[4]Сусыз чүлдә адашып йөргәннәр, кеше тора торган калага юл тапмаганнар. [5]Ачыгып һәм сусап
*йөргәннәр*, эчләрендә җаннары нечкәргән. [6]Алай да кайгырган чакларында Ходайга инәлгәннәр,
һәм Ул аларны бәлаләреннән коткарган. [7]Кеше тора торган калага керсеннәр дип, аларны туры
юлдан алып барган. [8]Ходайның рәхимнәрен Аның алдында сөйләсеннәр, һәм могҗизаларын
адәм уллары алдында *әйтсеннәр*! [9]Чөнки Ул ябыккан җанны туйдырган һәм ачыккан җанны
игелеккә тулыландырган. [10]Караңгыда һәм үлем күләгәсендә утырып торганнар, ярлылыкка һәм
тимергә богауланып торганнар. [11]Чөнки Алла сүзләренә каршы килгәннәр һәм Югарыдагының
киңәшен тыңламаганнар. [12]Эш эшләп күңелләре юашланган һәм хәлсезләнгәннәр, булышучы да
булмаган. [13]Алай да кайгырган чакларында Ходайга инәлгәннәр, һәм Ул аларны бәлаләреннән
коткарган. [14]Аларны караңгыдан һәм үлем күләгәсеннән чыгарган, богауларын да өзгән.
[15]Ходайның рәхимнәрен Аның алдында сөйләсеннәр, һәм могҗизаларын адәм уллары алдында
*әйтсеннәр*! [16]Чөнки Ул бакыр капкаларны ваткан һәм тимер бикләвечләрне сындырган.
[17]Канунсыз юлларыннан аларны чыгарган, канунсызлыклары өчен кимсетелгәннәр шул.
[18]Һәрбер ашамлыктан җаннары җирәнгән, һәм үлем капкасына якынлашканнар. [19]Алай да
кайгырган чакларында Ходайга инәлгәннәр, һәм Ул аларны бәлаләреннән коткарган. [20]Үз сүзен
җибәреп, аларны савыктырган, һәм харап булудан аларны коткарган. [21]Ходайның рәхимнәрен
Аның алдында сөйләсеннәр, һәм могҗизаларын адәм уллары алдында *әйтсеннәр*! [22]Аңа данлау
корбаны китерсеннәр һәм Аның эшләрен сөенеп сөйләсеннәр. [23]Көймәләр белән диңгездә
баручылар, зур сулар өстендә эшләр эшләүчеләр, [24]Ходайның эшләрен һәм Аның могҗизаларын
чоңгылда күргәннәр. [25]Ул әйтү белән каты давыл чыккан, һәм диңгез дулкыннары
күтәрелгәннәр. [26]Күккә чаклы күтәрелеп, төпсез җиргә чаклы төшәләр, җаннары кыен күреп
алҗыган. [27]Каушаганнар, исерек кеше кебек болганышканнар, һәм бар хикмәтләре юкка чыккан.
[28]Алай да кайгырган чакларында Ходайга инәлгәннәр, һәм Ул аларны бәлаләреннән чыгарган.
[29]Давылга кисәткәч тә, давыл тынычланган, дулкыннары да басылганнар. [30]Дулкыннар
басылганга сөенешкәннәр, һәм теләгән төшләренә аларны җиткергән. [31]Ходайның рәхимнәрен
Аның алдында сөйләсеннәр, һәм могҗизаларын адәм уллары алдында *әйтсеннәр*! [32]Халыклар
җыенында Аны күтәрсеннәр, һәм халык башлыклары җыенында Аны мактасыннар.
[33]Инешләрне чүлгә алмаштырган һәм сулы чишмәләрне киптергән. [34]Җимеш китерә торган
җирне, анда торучыларның усаллыклары өчен, тоз җиргә алмаштырган. [35]Чүлдә сулы күлләр
чыгарган һәм сусыз җирне су чыгара торган иткән. [36]Ачыкканнарны шунда урнаштырган, һәм
күп кешеле калалар корганнар, [37]басуларга ашлык чәчкәннәр һәм йөзем агачлары утыртканнар,
ашлык һәм җимеш үстергәннәр. [38]Аларны бәхилләгән, һәм бик күбәйгәннәр, туарларын да
киметмәгән. [39]Соңыннан кимегәннәр, яманлык һәм кайгы, кыен дә күреп интеккәннәр.
[40]Башлыкларына кимчелек китергән, һәм үтә алмаслык, юлсыз җирдә адашып йөрергә аларны
калдырган. [41]Ярлыга исә ярлылыгында булышкан, һәм Үз сарыкларыдай аны тынычландырган.
[42]Гаделләр моны күреп сөенерләр, ә һәрбер канунсызлык авызын ябар. [43]Акылы бар кеше моны
тотар, һәм Ходайның рәхимнәрен аңларлар.

Шөкер:

Йөз җиденче псалом (мәдхия).

[1]*Песнь. Псалом Давида*

*(Давытның җыр-мәдхиясе).*

[2]Күңелем әзер, и Алла, күңелем әзер: олылыгымда данлармын да, җырлармын да. [3]Әй даным,
тор, саз белән гөслә торыгыз, иртүк торырмын. [4]Халыклар арасында Сине данлап сөйләрмен, и
Ходай, кавемнәр арасында Сиңа җырлармын. [5]Чөнки рәхимең күкләрдән дә югары һәм
чынлыгың болытларга чаклы ук. [6]Күкләргә күтәрел, и Алла, һәм даның белән бөтен җир тулы.
[7]Сөеклеләрең котылыр өчен, уң кулың белән сакла һәм ишет мине. [8]Алла Үзенең изге урнында
әйткән: "Күтәрелеп Шәкемне бүләрмен һәм йортлары торган үзәнне үлчәрмен. [9]Гилыгад та
Минеке, Менашше дә Минеке, һәм Эфраим – Мин куйган башлык, Йәһүдә – Мин куйган патша.
[10]Моаб – өметем савыты, Эдомга итегемне салырмын. Ят нәселләр Миңа буйсындылар", дигән.
[11]Нык калага мине кем кертер? Я Эдомга чаклы мине кем алып барыр? [12]И безне борып
җибәргән Алла, чирүләребез белән чыкмас булган Алла, Син кертми кем кертсен? [13]Кайгыбызда
безгә булыш, кеше булышуы юк нәрсә шул. [14]Алла белән куәтебезне күрсәтербез, һәм Ул
дошманнарыбызны юкка чыгарыр.

Йөз сигезенче псалом (мәдхия).
*В конец. Псалом Давида*
*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*
[1]И Алла, данлавыма аң салмый калма! [2]Чөнки гөнаһлының авызы һәм юмачының авызы миңа
ачылдылар, минем өстән телләре белән юмалап сөйләштеләр; [3]мине күрәлмаганлыкны белгертә
торган сүзләр әйтеп, мине чорнап тордылар, һәм гаепсез көе миңа тотындылар: [4]мине сөю
урнына өстемнән ялганладылар, ә мин дога кылдым. [5]Яхшылык өчен миңа яманлык
кайтардылар, сөюем өчен мине күрәлмадылар. [6]Гөнаһлыны аңа баш итеп куй, һәм шайтан аның
уң ягында торсын. [7]Аны хөкем иткәндә гаепләнеп чыксын, һәм догасы гөнаһка саналсын.
[8]Гомер көннәре аз булсын, һәм дәрәҗәсен бүтән алсын. [9]Уллары үги калсыннар, һәм хатыны тол
калсын. [10]Уллары җирдән җиргә йөреп, соранып йөрсеннәр, йортларыннан куылып
чыгарылсыннар. [11]Аласы бар кеше бар нәрсәсен алып бетерсен, һәм тырышып тапканны ятлар
таласыннар. [12]Аны яклаучы булмасын, һәм үгиләренә юмартлык кылучы булмасын. [13]Балалары
харап булсыннар, исеме бер буында юкка чыксын. [14]Аталарының канунсызлыгы Ходай алдында
искә алынсын, һәм анасының гөнаһы әрчелмәсен. [15]Гөнаһлары һаман Ходайның күз алдында
булсыннар, һәм үзләрен искә алу җир өстеннән югалсын. [16]Чөнки рәхим кылуны исендә
тотмады, ярлы һәм мескен кешене куды, күңеле кайгылыны үтерергә йөрде. [17]Каргышны сөйде,
аңа каргыш тияр дә, бәхиллекне теләмәде, бәхиллек тә аннан китәр. [18]Каргышны киемдәй өстенә
киде, аның эченә су кебек керде, һәм сөякләренә май кебек *сеңде*. [19]Каргыш аңа киенә торган
киеме кебек булсын, һәм биленә һаман бәйли торган эзәре кебек булсын. [20]Өстемнән
ялганлаучыларга һәм җаныма каршы усалны әйтүчеләргә Ходайның кайтаруы шулай булыр.
[21]Әмма Син, и Ходай, и Ходай, миңа Үз исемең хакына кыл, чөнки рәхимең игелекле: [22]мине
коткар, чөнки мин ярлы һәм мескен, эчемдә йөрәгем дә каушады. [23]Авыша торган күләгә кебек
күчеп йөрдем, саранча кебек куылып йөрдем. [24]Ураза тотудан тезләрем талыкты, һәм май
булмаганлыктан тәнем үзгәрде. [25]Мин аларга көлке булдым: мине күреп башларын чайкадылар.
[26]И Ходай Аллам, миңа булыш, рәхимең хакына мине сакла. [27]Бу Синең кулыңнан булганны,
һәм моны Син кылганны, и Ходай, белсеннәр. [28]Алар каргарлар, ә Син бәхилләрсең, миңа
ябышучылар оятка калсыннар, бәндәң исә куаныр. [29]Өстемнән ялганлаучылар хурлыкка
киенсеннәр иде һәм кием белән *бөркәнгәндәй* оятларына бөркәнсеннәр иде. [30]Ходайны авызым
белән кычкырып данлап сөйләрмен, һәм күп *кешеләр* арасында Аны мактармын, [31]чөнки
куучылардан җанымны коткарыр өчен, мескеннең уң ягында торды.

Шөкер:

15-нче кафисмадан соң,
Өч изгелек.
*Тропарьләр: 1-нче көйгә.*

Чоңгыл шикелле гөнаһларым күп булды, и Коткаручы, һәм гөнаһларым белән бик тирән баттым шул. Петергә сузган кебек, миңа да кулыңны сузып, и Алла, мине коткар һәм ярлыка.

Шөкер: Яман уйлар һәм эшләр белән хөкемгә төштем, и Коткаручы, кабат Сиңа кайту уен миңа бир, и Алла, Сиңа дәшсәм иде: и игелекле яхшылык Кылучы, мине коткар һәм ярлыка.

Әле дә: И Алладан бәхетлелек алган һәм бозылусыз таза Кыз, мин шакшылыкта торучы һәм тиешсез эшләр һәм шакшы уйлардан нәҗес булган мескенне тазарт, и тазадан таза, иң изге Ана Кыз.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Ходай Иям Гайсә Мәсих, Син минем булышучым, мин үзем Синең кулыңда, миңа булыш, Сиңа гөнаһ кылырга мине калдырма, чөнки адашканмын, тәнемнең ирке артыннан барырга мине калдыра күрмә. Миннән бизмә, и Ходай, чөнки мин хәлсез. Син миңа файдалыны беләсең, гөнаһларым белән харап булырга мине калдырма. Мине ташлама, и Ходай, миннән читенмә, чөнки Сиңа сыендым. Синең иркеңне кылырга мине өйрәт, чөнки Син минем Аллам. Җанымны савыктыр, чөнки Сиңа гөнаһ кылдым. Үзеңнең рәхимең хакына мине коткар, чөнки мине рәнҗетүчеләр бар да Синең алдыңда, һәм миңа бүтән сыеныр урын юк, тик Син генә, и Ходай. Миңа ябышучылар бар да, җанымны бетерергә эзләүчеләр оятка калсыннар иде. Чөнки Син бер генә барына да куәтле Ходай, һәм Синең даның гомердән гомергә, амин.

**Уналтынчы кафисма.**

Йөз тугызынчы псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

[1]Ходай минем Ходаема әйткән: Мин дошманнарыңны аягың астына салганчы, утыр Минем уң
ягымда дип. [2]Ходай Сиңа Сионнан кодрәт таягын җибәрер, дошманнарың арасында баш булып
тор. [3]Куәтеңне күрсәтер көнне изгеләр яктысы алдында хакимлек Синдә булыр. “Таң йолдызы
булганчы, Мин Сине эчемнән тудырдым”. [4]Ходай ант иткән, һәм үкенмәс: Мәлик-Садыйкка
охшаулы Син гомергә корбанчы. [5]Ходай Синең уң ягыңда, ачуы килгән көнне патшаларны
кырып бетерде. [6]Халыкларны хөкем итәр, *җирне* үлекләр белән тутырыр, җирдә күп
кешеләрнең башларын ватыр, [7]юлда очраган чишмәдән эчәр, шуңа күрә башын күтәрер.

Йөз унынчы псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

[1]И Ходай, гаделләр киңәшендә һәм җыенында Сине бар күңелемнән данлап сөйләрмен. [2]Ходай
эшләре олы, Аның бар теләгәннәрен күрсәтеп торалар. [3]Аның эше сөйләрлек һәм бик ямьле,
дөреслеге дә гомердән гомергә тора. [4]Могҗизаларын истә тотарлык итеп кылган. Ходай рәхимле
һәм юмарт. [5]Үзеннән куркучыларга ашамлык биргән, Үз васыятен гомергә истә тотар.
[6]Мәҗүсиләрнең өлешен Үз халкына бирер өчен, аңа Үз эшләренең куәтен күрсәткән. [7]Аның
кулларының эшләре – чынны күрсәтү һәм хөкем итү, боерыклары барысы да дөрес, [8]гомердән
гомергә нык, чынлык һәм гаделлек белән куелганнар. [9]Үз халкына котылу җибәргән, Үз
васыятен гомергә куйган. Аның исеме изге һәм бик куркыныч. [10]Хикмәтнең башы Ходайдан
курку, шулай кылучыларның барысының да акыллары дөрес. Аның даны гомердән гомергә
тора.

Йөз унберенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа. Псалом*

*(Һалелуя).*

[1]Ходайдан куркучы кеше бәхетле, Аның боерыкларын бик яратыр. [2]Нәселе җирдә куәтле булыр,
гаделләрнең заты игелек табар. [3]Йортында дан белән байлык, һәм дөреслеге гомердән гомергә
тора. [4]Гаделләргә караңгыда якты яктыра: *Ходай* рәхимле, һәм юмарт, һәм гадел. [5]Яхшы кеше
юмартлык белән бирә, хөкемдә сүзләрен нык әйтер, шунлыктан гомергә какшамас. [6]Гадел кеше
гомергә истә торыр. [7]Усал сүздән курыкмас. [8]Күңеле Ходайга өметләнергә әзер, күңеле нык,
дошманнарын күргәндә курыкмас. [9]*Малын* ярлыларга өләшеп тараткан: дөреслеге гомердән
гомергә тора, куәте данланып күтәрелер. [10]Гөнаһлы кеше моны күреп газапланыр, тешләрен
шыкырдатыр һәм кибеп бетәр; гөнаһлының теләге юкка чыгар.

Шөкер:

Йөз уникенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

[1]Әй бәндәләр, Ходайны данлагыз, Ходайның исемен мактагыз. [2]Ходайның исеме әледән гомергә
данланып торсын. [3]Ходайның исеме кояш чыгышыннан кояш баешына чаклы данланып тора.
[4]Ходай бар халыклардан да югары, Аның даны күкләр өстендә. [5]Безнең Ходай Аллабыз кебек
кем? Югарыда торып, [6]күктә дә, җирдә дә *булып*, юашларга күз сала. [7]Ярлыны җирдән күтәрә,
һәм мескенне чүп арасыннан күтәрелдерә, [8]аны башлыклар белән, Үз халкының башлыклары
белән утыртыр өчен. [9]Бала китерми торган хатынны балаларына сөенә торган ана итеп, өйгә
урнаштыра.

Йөз унөченче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

1Исраил Мисырдан чыккач, Ягъкуб тумасы ят халык арасыннан чыккач, 2Яһүдия Ходайның
изгелеге булган, Исраил Аның өлеше булган. 3Диңгез күреп, агып киткән, Үрдүн кире кайткан.
4Таулар, тәкәләр кебек, һәм түбә җирләр, бәрәннәр кебек, сикерешкәннәр. 5Әй диңгез, сиңа ни
булды, ник агып киттең? Һәм сиңа Үрдүн, ни булды, ник кире кайттың? 6Әй таулар, ник тәкәләр
кебек, сикерештегез? Һәм түбә җирләр, ник бәрәннәр кебек, *сикерештегез*? 7Ходай йөзеннән,
Ягъкуб Алласының йөзеннән җир тетрәгән. 8Ул ташны сулы күлгә алмаштырган, һәм таш тауны
чишмәләргә *әйләндергән*. 9Безнең өчен түгел, и Ходай, безнең өчен түгел, әмма рәхимең хакына
һәм чынлыгың хакына Үз исемең данлат. 10Мәҗүсиләр: “Аларның Алласы кая?” дип, һич
берчакта да әйтмәсеннәр иде. 11Безнең Алла күктә дә, җирдә дә теләгәнен барын да булдырган.
12Мәҗүсиләрнең сыннары – көмеш белән алтын, кеше куларының эшләре: 13авызлары булса да,
сөйләшә алмыйлар; күзләре булса да, күрә алмыйлар; 14колаклары булса да, ишетә алмыйлар;
танаулары булса да, ис тоймыйлар; 15куллары булса да, кармалый алмыйлар; аяклары булса да,
йөри алмыйлар; тамаклары булса да, аваз чыгара алмыйлар. 16Аларны ясаучылар да, аларга өмет
итүчеләр барысы да алар кебек булсыннар. 17Исраил тумасы Ходайга өмет иткән; Ул – аларның
булышучысы һәм яклаучысы. 18Һарун тумасы Ходайга өмет иткән; Ул – аларның булышучысы
һәм яклаучысы. 19Ходайдан куркучылар Ходайга өмет иткәннәр; Ул – аларның булышучысы
һәм яклаучысы. 20Ходай безне исенә алып, безне бәхилләде: Исраил тумасын бәхилләде, Һарун
тумасын бәхилләде, 21Ходайдан куркучыларның кечеләрен дә, олыларын да бәхилләде. 22Ходай
сезгә дә, сезгә дә, сезнең улларыгызга да *бәхиллеген* арттырсын. 23Күкне дә, җирне дә булдырган
Ходай сезне бәхилләгән. 24Югарыгы күк Ходайныкы, ә җирне Ул адәм улларына биргән. 25Сине
үлекләр, и Ходай, тәмугка төшерелә торганнар данламаслар, 26әмма без, тереләр, Ходайны
әледән гомергә данларбыз.

Йөз ундүртенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

1Ходай инәлүемнең авазын ишеткәнгә сөендем. 2Миңа колагын салганга күрә, бар көннәремдә
дә *Аңа* сыенырмын. 3Үлем чирләре мине чорнап алдылар, тәмуг газаплары мине очраттылар,
хәсрәт һәм газап күреп, Ходай исеменә сыендым: 4и Ходай, җанымны коткар, дидем. Ходай
рәхимле һәм гадел, һәм Аллабыз ярлыкый. 5Балаларны саклаучы Ходай: мин кимгә калгач, мине
коткарды. 6Әй җаным, кабат тынычлан, чөнки Ходай сиңа игелек кылды. 7Җанымны әҗәлдән,
күзләремне яшь агызудан һәм аякларымны таюдан саклады. 8Тереләр җирендә Ходайга
яраулыны кылырмын.

Шөкер:

Йөз унбишенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

1Мин бик кимгә калдым дип әйткәндә дә ышанып тордым. 2Акылым китеп торганда: һәрбер
кеше буш нәрсә, дидем. 3Миңа кылган бар яхшылыклары өчен Ходайга ни кайтарыйм?
4Котылдыра торган касә алырмын да Ходай исеменә сыенырмын. 5Вәгъдә иткәннәремне бар
халкы алдында Ходайга китерермен. 6Ходайга яраучыларның үлүе Ходай алдында кадерле. 7И
Ходай, мин Синең бәндәң, Синең бәндәң, һәм Синең бәндәңнең улы; богауларымны өздең.
8Сиңа данлау корбанын китерермен дә Синең исемеңә сыенырмын. 9Вәгъдә иткәннәремне бар
халкы алдында Ходайга китерермен, 10Ходай өенең ишегалдында, әй Иерусалим, синең уртаңда.

Йөз уналтынчы псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

1Әй халыклар, барыгыз да Ходайны данлагыз, әй кешеләр, барыгыз да Аны мактагыз, 2чөнки
Аның рәхиме безгә беркетелгән, һәм Ходайның чынлыгы гомергә тора.

Йөз унҗиденче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

[1]Ходайны сөйләп данлагыз, чөнки Ул игелекле, чөнки рәхиме мәңге. [2]Исраил тумасы әйтсен:
чөнки Ул игелекле, чөнки рәхиме мәңге, дип. [3]Һарун тумасы әйтсен: чөнки Ул игелекле, чөнки
рәхиме мәңге, дип. [4]Ходайдан куркучылар барысы да әйтсеннәр: чөнки Ул игелекле, чөнки
рәхиме мәңге, дип. [5]Кысанлыкта торып Ходайга дәштем, һәм Ул мине ишетеп иркенгә *чыгарды*.
[6]Миңа булышучы Ходай, шуңа күрә курыкмам: кеше миңа ни кылыр? [7]Миңа булышучы Ходай,
шуңа күрә дошманнарыма *курыкмый* карармын. [8]Ходайга ышанып тору кешегә ышанып
торудан яхшырак. [9]Ходайга өмет итү башлыкларга өмет итүдән яхшырак. [10]Бар халыклар мине
чорнап алдылар, тик Ходай исеме белән аларга каршы тордым. [11]Мине әйләнеп чолгап алдылар,
тик Ходай исеме белән аларга каршы тордым. [12]Кортлар кәрәзне сарып алган кебек, мине
чорнап алдылар, һәм күгән янгандай, тиз кыздылар, тик Ходай исеме белән аларга каршы
тордым. [13]Төртеп җибәрделәр, тилпенеп егыла яздым, тик мине Ходай тотып алды. [14]Мине
ныклаучы һәм мине җырлатучы – Ходай, мине коткаручы Ул булды. [15]Гаделләр йортында
котылганга сөенү авазы: Ходайның уң кулы кодрәт кылган. [16]Ходайның уң кулы мине
күтәрелдерде, Ходайның уң кулы кодрәт кылган. [17]Үлмәмен, әмма тере торырмын, һәм Ходай
эшләрен сөйләрмен. [18]Ходай миңа каты кыен тидерде, алай да мине үлемгә бирмәде. [19]Дөреслек
капкасын миңа ачыгыз, аннан кереп, Ходайны сөйләп данлармын. [20]Бу – Ходай капкасы,
гаделләр шуннан керерләр. [21]Сине сөйләп данлармын, чөнки Син мине ишеттең һәм мине
коткаручы булдың. [22]Өй салучылар яраусыз күреп ташлаган таш почмак астына нигез булган:
[23]Ходайдан булган бу һәм күз алдыбызда искитәрлек. [24]Бу көн Ходай булдырган көн, шушы
көнне сөенешеп куанышыйк. [25]И Ходай, сакласана! И Ходай, өлгертсәнә! [26]Ходай исеменә
килүче данлаулы! Ходай өеннән сезгә игелек теләдек. [27]Ходай – Алла, һәм безгә күренгән.
Корбан урнының почмакларыннан җыелып, тыгызланып торып бәйрәм итегез. [28]Син – минем
Аллам, һәм Сине сөйләп данлармын. Син – минем Аллам, һәм Сине күтәрермен. Сине сөйләп
данлармын, чөнки Син мине ишеттең һәм мине коткаручы булдың. [29]Ходайны сөйләп данлагыз,
чөнки Ул игелекле, чөнки рәхиме мәңге.

Шөкер:

16-нчы кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 1-нче көйгә.*

Бүтән дөнья сине көтә, әй җаным, һәм Хөкем Итүче синең яшерендәге яман эшләреңне ачып, күрсәтәсе итә; җирдәге нәрсәләргә биренеп торма, әмма теге чактан элек Хөкем Итүчегә болай дәшеп инәл: и Алла, тазарт мине, һәм мине ярлыка.

Шөкер: Күп гөнаһлар һәм чамасыз яралар белән чорналганмын, и Коткаручы, гөнаһ кылып, Синең игелекле күңеллелегеңә инәләмен, и Мәсих: килеп мине савыктыр, и чирләп ятканнарны Дәвалаучы, һәм коткар мине.

Әле дә: Әй җаным, нигә пошмыйча гына ялкауланып яшисең? Гомереңдә кылган усал эшләреңне кичертергә нигә һич пошынмыйсың? Ходай сиңа ишегене япканчы төзәлергә тырыш, Алланы Тудыручыга килеп сыен һәм егылып дәш: и өмет беткәннәрнең өмете, Сиңа күп гөнаһ кылучы мине коткар, и иң таза Иям Кыз.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И изге Ходай, югарыда торып, Үзеңнең үтә күрүчән күзең белән бар булдырган нәрсәләреңә дә карыйсың. Җаныбызның да, тәнебезнең дә муеннарын сыгылтып, и Изгедән Изге, Сиңа инәләбез: Үзеңнең тора торган изге урныңнан күренми торган кулыңны суз һәм барыбызны да бәхиллә. Безнең иректән һәм ирексездән, сүз белән, я эш белән кылган һәрбер гөнаһларыбызны безгә кичер. И Ходай, күңел йомшаклыгын безгә бүләк ит, безнең күп гөнаһларыбызны тазартыр өчен, безгә ихлас күңелдән рухи күз яшләрен бүләк ит. Үзеңнең дөньяңа һәм без яраусыз бәндәләреңә дә Синең зур рәхимеңне бүләк ит. Чөнки Синең исемең, Атаның, һәм Улның, һәм Изге Рухның, мактаулы һәм данланып тора, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

**Унҗиденче кафисма.**

Йөз унсигезенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*
[1]Юлы шиксезләр, Ходай канунынннан йөрүчеләр бәхетле. [2]Аның таныткычларына өйрәнүчеләр
бәхетле, бар күңелләре белән Аны эзләрләр. [3]Канунсызлык кылмый торучылар Аның
юлларыннан йөриләр шул. [4]Син боерыкларыңны нык тотарга кушкансың. [5]Их, минем юлларым
төз булып, боерыкларыңны тотсам иде, [6]аннары барча боерыкларыңа карасам да, оялмас идем.
[7]Дөреслегеңнең тикшерүләренә өйрәнгәч, Сине туры күңелдән сөйләп данлармын.
[8]Боерыкларыңны тотармын, бөтенләй үк мине ташлама. [9]Яшь кеше үз юлын ничек итеп төзек
итәр? Синең сүзләреңне тотып *төзек итәр*. [10]Бар күңелемнән Сине эзләдем, боерыкларыңнан
мине биздермә. [11]Сүзләреңне күңелемә салдым, Сиңа гөнаһ кылмасам иде дип. [12]Син данлаулы,
и Ходай, боерыкларыңа мине өйрәт. [13]Авызыңның бар сүзләрен телем белән белдердем.
[14]Таныткычларыңның юлыннан йөреп, тулы байлыкка *кинәнгәндәй* кинәндем. [15]Боерыкларыңны
исәпләп, юлларыңны аңлармын. [16]Дөресләндергечләреңә өйрәнермен, сүзләреңне онытмам.
[17]Бәндәңә игелек ит: мине терелт, һәм сүзләреңне тотармын. [18]Күзләремне ачылдыр, һәм
кануныңдагы могҗизаларны аңлармын. [19]Мин җирдә узгынчы гына, боерыкларыңны миннән
яшермә. [20]Җаным һәрбер чакта Син кушканны теләүне сөйде. [21]Горурларны тыйгансың,
боерыгыңнан авышучылар каргаулы. [22]Хурлауны һәм кимсетүне миннән ал, чөнки
таныткычларыңны эзләдем. [23]Башлыклар утырган җирләрендә минем өстән әләкләгәннәр,
бәндәң исә дөресләндергечләреңне исәпләде. [24]Чөнки таныткычларың – миңа үгет, һәм
дөресләндергечләрең – миңа киңәш. [25]Җаным җиргә егылды, Үз сүзең буенча мине терелт.
[26]Юлларымны билгеле иттем, һәм Син мине ишеттең: боерыкларыңа мине өйрәт.
[27]Боерыкларыңның юлын миңа аңлат, һәм могҗизаларыңны исәпләрмен. [28]Моңайганлыктан
җаным йокымсырады, сүзләрең белән мине ныгыт. [29]Дөрессезлек юлын миннән ерак ит һәм
кануның белән мине ярлыка. [30]Чын юлны теләдем һәм Син кушканны онытмадым. [31]И Ходай,
таныткычларыңа бирендем, мине оятка калдырма. [32]Син күңелемне иркенләткәч,
боерыкларыңның юлыннан җитез йөрдем. [33]И Ходай, дөресләндергечләреңнең юлын миңа
канун итеп куй, һәм аны һаман эзләрмен. [34]Миңа акыл бир, һәм кануныңа өйрәнермен, аны бар
күңелемнән тотармын. [35]Боерыкларыңның сукмагына мине бастыр, чөнки шуны теләдем.
[36]Күңелемне таныткычларыңа авыштыр, ә малга *бирендермә*. [37]Күзләремне буш нәрсәгә
караудан бор, Үз юлыңда мине терелт. [38]Сүзеңне бәндәңә Үзеңнән куркып торырга куй.
[39]Исемнән китми торган хурлыгымны ал, чөнки Синең хөкемнәрең яхшы. [40]Менә
боерыкларыңны теләдем, дөреслегең белән мине терелт. [41]И Ходай, рәхимең миңа килсен иде,
Үз сүзең буенча мине сакла. [42]Мине хурлаучыларга җавапка сүз табармын, чөнки Синең
сүзләреңә өмет иттем. [43]Авызымнан чын сүзне бөтенләй үк алма, чөнки Синең хөкемнәреңә
өмет иттем. [44]Кануныңны һаман тотармын, гомергә һәм гомердән гомергә. [45]Боерыкларыңны
очраткач, иркен йөрдем. [46]Таныткычларың турысында патшалар алдында сөйләдем, һәм
оялмадым. [47]Боерыкларыңнан өйрәндем, аларны бик сөйдем. [48]Нык сөйгән боерыкларыңны
кылырга кулларымны күтәрдем, һәм дөресләндергечләреңне исәпләдем. [49]Бәндәңә әйтеп, мине
ышандырган сүзләреңне исеңә ал. [50]Сүзең – мине терелтеп торуы, бу – кайгылы чагымда мине
юатты. [51]Горурлар канунннан чамасыз яздылар, әмма мин кануныңнан авышмадым. [52]И Ходай,
борынгыдан була килгән хөкемнәреңне исемә төшереп, тынычландым. [53]Кануныңны ташлаучы
гөнаһлы кешеләрне *күргәч*, миңа көек төште. [54]Узгынчы кебек кенә торган җиремдә
дөресләндергечләреңне мактап җырладым. [55]И Ходай, төнлә Синең исемеңне исемә китереп,
кануныңны тоттым. [56]Шул булды миндә, чөнки дөресләндергечләреңне эзләдем. [57]И Ходай, Син
минем өлешем, кануныңны тотармын, дидем. [58]Йөзеңә бар күңелемнән инәлдем, Үз сүзең
буенча мине ярлыка. [59]Юлларыңны исәпләдем һәм аякларымны таныткычларыңа таба
юнәлттем. [60]Боерыкларыңны кылырга әзер булдым, һәм йөдәмәдем. [61]Гөнаһлылар бау белән
чорнагандай, мине чорнап алдылар, алай да кануныңны онытмадым. [62]Дөрес хөкем иткәнең
өчен Сине данларга төн уртасында торгаладым. [63]Синнән куркучыларга һәм боерыкларыңны
тота торганнарга барысына да мин катнаш. [64]И Ходай, рәхимең белән җир тулы, боерыкларыңа
мине өйрәт. [65]И Ходай, Үз сүзең буенча бәндәңә яхшылык кылдың. [66]Игелеккә һәм үгеткә,
акылга да мине өйрәт, чөнки боерыкларыңа ышандым. [67]Кимсетелүдән элек гөнаһ кылган идем,
аннан болай сүзеңне тоттым. [68]И Ходай, Син игелекле, һәм игелегең буенча
дөресләндергечләреңә мине өйрәт. [69]Горурларның дөрессезлеге өстемә күбәйде, мин исә бар
күңелемнән боерыкларыңа өйрәнермен. [70]Аларның күңеле катырган сөт кебек катыланган, мин

исә кануныңа өйрәндем. [71]Мине юашландыруың миңа яхшы булды, боерыкларыңа өйрәнер өчен
булды. [72]Авызыңнан чыккан кануның миңа яхшы тиде, исәпсез күп көмештән һәм алтыннан да
артыграк.

Шөкер:

[73]Кулларың мине булдырып төзегән: акыллыландыр мине, һәм боерыкларыңа өйрәнермен.
[74]Сүзеңә өмет иткәнемне күреп, Синнән куркучылар куанырлар. [75]И Ходай, хөкемнәреңнең туры
икәнен аңладым, һәм мине тиешлечә кимсеттең. [76]Бәндәңә әйткән сүзең буенча, рәхимең миңа
сөенечкә булсын иде. [77]Миңа юмарт бул, һәм тере торырмын, чөнки кануның миңа үгет.
[78]Гаепсез көе миңа каршы канунсызлык кылганнарына күрә, горурлар оятка калсыннар иде, мин
исә боерыкларыңны исәпләрмен. [79]Синнән куркучылар һәм таныткычларыңны белүчеләр миңа
кушылсыннар. [80]Синең боерыкларыңдагыча күңелем шиксез булсын иде, оятка калмасам иде.
[81]Коткаруыңны теләп, җаным эри, сүзләреңә өмет иттем. [82]Мине кайчан тынычландырырсың
дип әйтеп, сүзеңне көткәнлектән күзләрем бетте. [83]Суыкта каткан турсыктай булдым, алай да
боерыкларыңны онытмадым. [84]Бәндәңнең торасы көннәре күпме? Мине тыгызлаучыларны
кайчан хөкем итәрсең? [85]Кануннан язучылар миңа исәп бирделәр, тик ул исәп, и Ходай, Синең
кануның кебек түгел. [86]Барча боерыкларың – чын, гаепсез көе мине кудылар, миңа булыш.
[87]Җир өстендә аздан гына мине бетермәделәр, алай да мин боерыкларыңны ташламадым.
[88]Рәхимең хакына мине терелт, һәм авызың әйткән таныткычларыңны тотармын. [89]И Ходай,
Синең сүзең күктә гомергә тора. [90]Синең чының тумыштан тумышка *тора*; җирне коргансың,
һәм ул тора. [91]Көн Син куйганлыктан тора, чөнки һәрбер нәрсә Сиңа баш салып тора. [92]Әгәр дә
кануның миңа үгет булмаса, кимсетелүемдә юкка чыгар идем. [93]Боерыкларыңны гомергә
онытмам, чөнки алар белән мине терелттең.

Уртасы:

[94]Синеке мин, мине сакла, чөнки дөресләндергечләреңне эзләдем. [95]Гөнаһлылар мине әрәм итәсе
булып тордылар, *ә* мин таныткычларың турысында уйладым. [96]Һәрбер эшнең чиге барын
күрдем, *әмма* Синең боерыгың чиксез киң. [97]И Ходай, кануныңны бик сөйдем, көн буе миңа
үгет бирә. [98]Боерыгың белән мине дошманнарымнан бигрәк остарттың, чөнки ул гомергә
минеке. [99]Таныткычларың миңа үгет булганга күрә, өйрәтүчеләремнең барысыннан да күбрәк
белдем. [100]Боерыкларыңны эзләгәнлектән, картлардан да күбрәк белдем. [101]Сүзләреңне тотыйм
дип, аякларымны яман юлга ирек бирмәдем. [102]Син кушканнан авышмадым, чөнки Син аларны
миңа канун итеп куйдың. [103]Сүзләрең тамагыма бик тәмле, авызыма балдан да татлы.
[104]Боерыкларыңнан акыл алдым, шунлыктан һәртөрле ялган юлны яратмас булдым. [105]Кануның
аякларыма яктырткыч һәм сукмакларыма якты. [106]Дөрес сүзләреңне тотарга дип, ант итеп,
вәгъдә иттем. [107]Бик кимгә калдым, и Ходай, Үз сүзең буенча мине терелт. [108]И Ходай,
авызымның иректән әйткән *сүзләреңә* ризалык ит, һәм кушканыңа мине өйрәт. [109]Җаным һаман
Синең кулыңда, һәм кануныңны онытмадым. [110]Гөнаһлылар миңа ау кордылар, алай да мин
боерыкларыңнан авышмадым. [111]Таныткычларыңны гомеремә үземнеке иттем, чөнки
күңелемнең сөенече алар. [112]Кайтарыңа өметләнеп, дөресләндергечләреңне гомергә кылырга
күңелемне ийдем. [113]Кануныңнан язучыларны яратмадым, кануныңны исә нык сөйдем.
[114]Булышучым һәм яклаучым минем Син, сүзләреңә ышандым. [115]Яманлык итүчеләр, миннән
китегез һәм Алламның боерыкларына өйрәнермен. [116]Үз сүзең буенча мине якла, һәм тере
торырмын, өмет иткән көе мине оятка калдырма. [117]Миңа булыш, һәм котылырмын,
дөресләндергечләреңә дә һаман өйрәнермен. [118]Боерыкларыңнан бизүчеләрне барысын да
кимсеттең, чөнки уйлары дөрес түгел. [119]Җирдәге гөнаһлыларны, *кануннан* язучыларны
барысын да *күңелем белән* карап чыктым, шунлыктан таныткычларыңны нык сөйдем.
[120]Тәнемне Үзеңнән куркындырып тот, хөкемнәреңнән курыктым шул. [121]Дөреслек белән хөкем
иттем, рәнҗетүчеләремә мине тапшырма. [122]Горурлар мине әләкләмәсеннәр дип, бәндәңне
югары игелеккә ал. [123]Коткаруыңны һәм дөрес сүзеңне көткәнлектән күзләрем бетте. [124]Бәндәңә
рәхимең буенча кыл һәм боерыкларыңа мине өйрәт. [125]Мин Синең бәндәң: миңа акыл бир, һәм
таныткычларыңны белермен. [126]Ходайга кылырга вакыт инде: кануныңны боздылар шул. [127]Ә
мин боерыкларыңны топаздан да, алтыннан да бигрәк сөйдем. [128]Шул сәбәпле барча
боерыкларыңа борылдым, һәртөрле дөрессезлек юлын яратмадым. [129]Таныткычларың искиткеч,
шунлыктан җаным аларга өйрәнде. [130]Сүзләреңнең күренүе балаларны яктыртып
акыллыландыра. [131]Авызымны ачып, Рухыңны эчемә алдым, чөнки боерыкларыңны теләдем.

Шөкер:

[132]Исемеңне сөйгәннәргә кылган кебек, миңа күз салып, мине дә ярлыка. [133]Аякларымны Үз сүзең буенча йөргез, һәм һичбер канунсызлык мине биләп алмасын иде. [134]Кеше әләгеннән мине коткар, һәм боерыкларыңны тотармын. [135]Йөзеңне бәндәңә яктырылдыр һәм боерыкларыңа мине өйрәт. [136]Кануныңны кыла алмаганыма күрә елый-елый күзләрем, чишмә кебек, яшь агыздылар. [137]И Ходай, Син туры, хөкемнәрең дә туры. [138]Таныткычларыңда гел дөресне генә, тик чынны гына күрсәткәнсең. [139]Сиңа бирэнгәнлегем буенча, дошманнарым сүзләреңне онытканга *ачуым килеп* корыдым. [140]Сүзең бик таза, һәм бәндәң аны яратты. [141]Мин әле яшь кенә һәм юаш, алай да боерыкларыңны онытмадым. [142]Дөреслегең гомергә дөрес, һәм кануның да чын. [143]Кайгылар һәм мохтаҗлыклар мине очраттылар, тик боерыкларың гына мине өйрәттеләр. [144]Таныткычларың – гомергә торасы дөреслек: мине акыллыландыр һәм тере торырмын. [145]Бар күңелемнән инәлеп дәштем: и Ходай, мине ишет, дөресләндергечләреңне эзләрмен. [146]Сиңа дәштем: мине сакла һәм таныткычларыңны тотармын. [147]Вакытсыз чакта алдан торып инәлдем, сүзләреңә өмет иттем. [148]Сүзләреңә өйрәним дип, күзләремне таң атканчы алдан ачтым. [149]И Ходай, рәхимең буенча авазымны ишет, Үзең теләгәнчә мине терелт. [150]Мине канунсыз рәвештә куучылар якынлаштылар, кануныңнан исә ерак киттеләр. [151]И Ходай, Син якын, һәм юлларың барысы да чын. [152]Таныткычларыңны гомергә куйганыңны электән үк шул таныткычларыңнан белдем. [153]Юашлыгымны күреп, мине коткар, чөнки кануныңны онытмадым. [154]Эшемне тикшереп мине коткар, Үз сүзең буенча мине терелт. [155]Котылу гөнаһлылардан ерак тора, чөнки дөресләндергечләреңне эзләмәделәр. [156]Юмартлыгың күп, и Ходай, Үзең теләгәнчә мине терелт. [157]Мине куучылар һәм кысучылар күп, алай да таныткычларыңнан авышмадым. [158]Аңсызларның сүзләреңне тотмаганнарын күреп, корып беттем. [159]Боерыкларыңны сөйгәнемне күр, и Ходай, рәхимең буенча мине терелт. [160]Сүзләреңнең башы чын, һәм дөреслегеңнең хөкемнәре мәңге. [161]Башлыклар мине гаепсез көе кудылар, тик күңелем сүзләреңнән генә курыкты. [162]Күп табыш тапканга сөенгәндәй, сүзләреңә сөенермен. [163]Дөрессезлекне яратмадым һәм аннан җирәндем, ә кануныңны бик сөйдем. [164]Дөрес хөкемнәрең өчен Сине көнендә җиде тапкыр мактадым. [165]Кануныңны сөйгәннәргә тынычлык күп, һәм алар алданмыйлар. [166]Коткаруыңны көттем, и Ходай, һәм боерыкларыңны бик сөйдем. [167]Җаным таныткычларыңны саклады, һәм аларны бик сөйде. [168]Боерыкларыңны һәм таныткычларыңны тоттым, чөнки бар йөрешләрем, и Ходай, Синең алдыңда. [169]Инәлүем Синең алдыңа җитсен иде: и Ходай, Үз сүзең белән мине акыллыландыр. [170]Үтенүем Синең алдыңа җитсен иде: и Ходай, Үз сүзең буенча мине коткар. [171]Мине боерыкларыңа өйрәтсәң, авызым җырулар чыгарыр. [172]Телем Синең сүзләреңне сөйләр, чөнки боерыкларың барысы да дөрес. [173]Кулың мине сакласын иде, чөнки боерыкларыңны теләдем. [174]Коткаруыңны бик теләдем, и Ходай, һәм кануның миңа үгет. [175]Җаным тере торып, Сине мактар, һәм хөкемнәрең миңа булышырлар. [176]Адашып калган сарыктай адаштым, бәндәңне эзләп тап, чөнки боерыкларыңны онытмадым.

Шөкер:

17-нче кафисмадан соң,
Өч изгелек.
*Тропарьләр: 2-нче көйгә.*

Азгын ул кебек, Сиңа гөнаһ кылдым, и Коткаручы, мин тәүбәгә килүчене кабул ит, и Әти, һәм мине ярлыка, и Алла.

Шөкер: Салым җыючының тавышы белән Сиңа дәшәмен, и Коткаручы Мәсих, аны тазартканың кебек, мине дә тазарт, һәм мине ярлыка, и Алла.

Әле дә: И Алланы Тудыручы, Синең яклавыңа кирәксенгән миннән бизмә, җаным Сиңа өметләнде шул, мине ярлыка.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И бар нәрсәне дә тотучы Ходай Иям һәм барын да Яратучы, юмартлык кылучы Ата һәм рәхим күрсәтүче Алла. Син туфрактан кешене булдырып аны Үзең төсле итеп һәм Үзеңә охшаш итеп күрсәткәнсең, моның белән Синең иң ямьле исемең җирдә данлансын дип. Һәм Синең боерыгыңа каршы килгәне өчен оҗмахтан куып чыгаргач та, Мәсихеңдә аны яхшыракка яңадан булдыргансың, һәм күккә чаклы күтәрелдергәнсең. Сиңа шөкер итәмен, чөнки Үзеңнең

олылыгыңны миндә дә күбәйткәнсең, һәм мине тәмуг төбенә ташларга эзләүче дошманнарыма мине бөтенләйгә бирмәгәнсең, һәм канунсызлыкларым белән бергә харап булырга мине калдырмагансың. Хәзер дә, и күп рәхимле һәм бәхеткә тулы Ходай, гөнаһлының үлүен теләмисең, әмма кайтуын көтеп аны кабул итәсең; түбән егылганнарны төзәтәсең, җимерелгәннәрне савыктырасың. Мине дә тәүбәгә таба бор, мин түбән егылганны төзәт һәм җимерелгәнне савыктыр. Юмартлыгыңны һәм әүвәлдән үк кыла килгән белеп җиткерә алмаслык игелегеңне исеңә ал, һәм минем чамасыз канунсызлыкларымны оныт, аларны мин эшем белән дә, сүзем белән дә, уем белән дә кылганмын шул. Күңелемнең сукырлыгын чиш, һәм уемның шакшысын тазартыр өчен, күңел йомшаклыгы белән күз яшен миңа бир. И Ходай, ишет; и адәмне Сөюче, аң сал; и игелекле Күңелле, тазарт; һәм миндә патшалык итә торган нәфесләр газаплавыннан мескен җанымны азат ит, моннан ары гөнаһ мине тотып тормасын иде. Минем белән көрәшүче җен дә һич нәрсә кыла алмасын иде, һәм үзенең теләгенә мине алып бара алмасын иде. Әмма Үзеңнең куәтле кулың белән аның биләвеннән мине тартып алгач, Син Үзең, игелекле һәм кеше сөюче Ходай, миндә патшалык ит. Һәм бөтенләй Синеке булырга, моннан ары Синең иркең буенча гомер итәргә миңа ризалык ит. Үзеңнең әйтеп җиткезүсез игелегең белән күңелемнең тазарынуын, авызымның саклануын, эшләремне дөрес итүне, юаш уйлануны, уйларымның тынычлыгын, җан көчләремнең тынычлыгын, рухи шатлыкны, чын сөюне, озак түземлекне, игелеклелекне, сабырлыкны, риясыз иманны, тыйнаклыкны миңа бир. Һәм Үзеңнең Изге Рухыңны бүләк итүең белән бар игелекле җимешләр белән мине тулы ит. Гомеремнең яртысында мине ала күрмә, төзәлмәгән һәм әзерләнмәгән көе җанымны ала күрмә. Әмма Үзеңнең камиллегең белән мине камил ит, һәм шулай итеп бу тормыштан мине чыгар; каршылык итүчегә очрамыйча, караңгылыкның башлыкларын һәм хакимлекләрен үтеп, Синең дәүләтең белән якын бара алмаслык даныңның әйтеп җиткезүсез ямен бар изгеләрең белән күрсәм иде. Синең иң кадерле һәм иң ямьле исемең, Атаның, һәм Улның, һәм Изге Рухның, әүлияләреңдә үк изге ителгән һәм данланып тора, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

**Унсигезенче кафисма.**

Йөз унтугызынчы псалом (мәдхия).

*Песнь степеней*

*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Кайгырган чагымда Ходайга инәлеп дәштем, һәм Ул мине ишетте. 2И Ходай, җанымны
ялганчы авыздан һәм юмачы телдән коткар. 3Юмачы телең өчен сиңа ни бирелер, я сиңа ни
өстәлер? 4Куәтленең очлаган уклары, яндырып бетерә торган күмерләре *өстәлер*. 5Читен миңа,
чөнки торуым ят җирдә озакка китте, Кыдар чатырларында урнаштым. 6Җаным ят җирдә күп
торды, татулыкны яратмаганнар белән тату тордым. 7Аларга татулыкны сөйләгәч, гаепсез көе
миңа тотындылар.

Йөз егерменче псалом (мәдхия).

*Песнь степеней*

*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Күзләремне тауларга таба күтәрдем, миңа булышу шуннан килер. 2Миңа булышучы күкне һәм
җирне булдырган Ходай. 3Аягыңны какшатма: сине Саклаучы йокымсырамас. 4Менә Исраилне
Саклаучы йокламас та, йокымсырамас та. 5Ходай сине саклар, сине ябучы Ходай, уң ягыңда Ул.
6Көндез кояш сиңа зыян тидермәс, һәм төнлә ай да *зыян тидермәс*. 7Ходай сине һәрбер яманнан
саклар, Ходай җаныңны саклар. 8Ходай сине кергән чагыңда да, чыккан чагыңда да саклар,
әледән һәм гомергә.

Йөз егерме беренче псалом (мәдхия).

*Песнь степеней*

*(Зиярәтчеләр җыры).*

1”Ходай өенә барыйк” дигәч, бик сөендем. 2Әй Иерусалим, аякларыбыз синең йортыңа барып
торган кебек булды. 3Иерусалим, бер юнәлештән йортларын тоташ торгызган кала. 4Исраил
канунынча, Ходай исемен данларга дип, Ходай *халкының* тумалары шунда йөргән. 5Чөнки анда,
Давыт йортында, хөкем урыннары торган. 6Иерусалимгә тынычлык, аны сөючеләргә уңышлык

теләгез. 7Синең[10] чирүләреңдә тынычлык торсын, һәм коймаларың эчендә уңышлык булсын.
8Туганнарым һәм якыннарым хакына сиңа тынычлык телимен. 9Ходай Аллабызның йорты
хакына сиңа яхшылык эзләдем.

---

[10] Иерусалимнең.

### Йөз егерме икенче псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Сиңа, күктә торучыга, күзләремне күтәрдем. 2Менә ир колларның күзләре ияләренең кулларына
карап торган кебек, хатын колның күзләре хатын иясенең кулына карап торган кебек, шулай
безнең күзләребез дә Ходай Аллабызга, безне ярлыкасын иде дип, карап торалар. 3Безне ярлыка,
и Ходай, безне ярлыка, чөнки бик кимчелеккә калдык. 4Байларның хурлавына һәм горурларның
кимсетүенә җаныбыз бик туйды инде.

### Йөз егерме өченче псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Исраил әйтсен: “Әгәр дә безнең белән Ходай булмаса, 2безнең белән Ходай булмаса, безгә
каршы торган чагында кешеләр безне терелэй йотарлар иде; 3безгә аларның ачуы ярсыган чакта,
безне су басар иде”, дип. 4Җаныбыз инеш аркылы үтте, 5җаныбыз шаулап ага торган су аркылы
үтте. 6Безне алар тешләренә ирек бирмәгән Ходай данлаулы. 7Җаныбыз тотучыларның авыннан
кош кебек котылды: ау өзелде һәм без котылып чыктык. 8Безгә булышу күкне һәм җирне
булдырган Ходай исеме аркылы булды.

Шөкер:

### Йөз егерме дүртенче псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Ходайга өмет итүчеләр Сион тавы шикелле *нык торырлар*: Иерусалимдә торучы гомергә
кузгалмас. 2Иерусалимне таулар чорнап тора, һәм Ходай Үз халкын әледән дә гомергә чолгап
тора. 3Чөнки Ходай, гаделләр кулларын канунсызлыкка сузмасыннар дип, гаделләр өлешен
гөнаһлылар кулы астында калдырмас. 4И Ходай, туры һәм игелекле күңеллеләргә яхшылык ит.
5Бозыклыкка авышучыларны исә Ходай канунсызлык кылучылар белән бергә алып китәр.
Исраилгә тынычлык булсын!

### Йөз егерме бишенче псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Ходай Сионның тоткындагыларын кайтарган чакта бик сөендек. 2Шул чагында авызыбыз
сөенеч белән, һәм телебез куаныч белән тулды. Шул чакта ят халыклар арасында да: “Ходай
аларга зур эш кылды”, диделәр. 3Ходай безгә бик зур эш кылды: без куаныштык. 4И Ходай,
төшлектән *явым яудырып*, гөрләвекләр ташыткан кебек, тоткындагыларыбызны *төркем-төркем
агылдырып* кайтар. 5Елап чәчүчеләр сөенеп урырлар. 6*Тоткынга* китүчеләр киткәндә
орлыкларын елый-елый чәчтеләр, *тоткыннан* кайтучылар исә көлтәләрен алып, сөенешеп
кайтырлар.

### Йөз егерме алтынчы псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Өйне Ходай салдырмаса, салучылар юкка гына азапланалар; каланы Ходай сакламаса,
сакчының йокламый карап йөрүе дә бушка. 2Сез дә юкка иртүк торасыз, азап белән тапкан
икмәгезне ашагач, утырган җирегездән юкка тиз үк торасыз, Ходай ул чагында сөйгән
кешеләренә йокы бирә ич. 3Менә уллар – Ходай биргән дәүләт, ана эченнән килгән табыш.
4Тоткыннан котылганнарның уллары көчленең кулындагы уклар шикелле. 5Алар аркылы

теләгәнен булдырасы кеше бәхетле: *кала* капкасы төбендә дошманнары белән капма-каршы
сөйләшкәндә оятлы булмаслар.

Йөз егерме җиденче псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*
[1]Ходайдан куркучылар, Аның юлларыннан йөрүчеләр барысы да бәхетле. [2]Кулларың эшләгәнгә
кинәнерсең: син бәхетле, һәм сиңа яхшы булыр! [3]Хатының – өең әйләнәсендәге җимеш
китерүчән йөзем агачы шикелле. [4]Улларың табының әйләнәсендә зәйтүн агачының үрентеләре
шикелле. [5]Менә Ходайдан куркучы кеше шулай бәхилләнер. [6]Ходай Сионнан сине бәхилләсен
иде, һәм торган гомереңдә Иерусалим күргән яхшылыкны күрсәң иде; [7]һәм улларыңның
улларын күрсәң иде. Исраилгә тынычлык булсын.

Йөз егерме сигезенче псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*
[1]Исраил әйтсен: “Яшь чагымнан бирле миңа күп тапкыр тотынгаладылар; [2]яшь чагымнан бирле
миңа күп тапкыр тотынгаладылар, тик мине җиңә алмадылар”, дип. [3]Гөнаһлылар җилкәмдә
эшләделәр, канунсызлык кылуларын туктатмадылар. [4]Ходай гадел, гөнаһлыларның муеннарын
кисеп өзгән. [5]Сионны яратмый торучылар барысы да оятка калып, кире чигенсеннәр иде. [6]Өй
түбәсендә *үскән*, йолкыганчы корый торган үлән кебек булсыннар иде; [7]аның белән уракчы
учын тутырмас һәм көлтәләүче кочагын *тутырмас*. [8]Һәм узучылар: “Сезгә Ходайның бәхиллеге
булсын, Ходай исеме белән сезне бәхиллибез” дип, әйтмәсеннәр иде.

Шөкер:

Йөз егерме тугызынчы псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*
[1]И Ходай, эч күңелемнән Сиңа дәштем: и Ходай, авазымны ишет! [2]Инәлгән авазымны
колакларың тыңлап торсыннар иде. [3]Канунсызлыкларын тикшерсәң, и Ходай, и Ходай, кем
чыдап тора алыр? Тик Үзең генә тазартасың. [4]Исемең хакына Сиңа өметләндем, и Ходай, җаным
Синең сүзеңә өметләнде; җаным Ходайга ышанып торды, [5]иртәге сәгатьтән төнгә чаклы; иртәге
сәгатьтән төнгә чаклы Исраил Ходайга өмет итсен. [6]Чөнки Ходайда рәхим һәм коткаруы бик
олы, һәм Ул Исраилне барча канунсызлыкларыннан коткарыр.

Йөз утызынчы псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*
[1]И Ходай, күңелем масаймады, һәм күзләрем горур карамадылар: көчем җитмәстәй искитәрлек
зур эшләргә керешмәдем. [2]Юаш күңелле булмыйча, җанымны горурландырган булсам да,
имезеп үстергән *баласына* анасы ничек, Син дә минем җаныма шулай бул. [3]Исраил әледән һәм
гомергә Ходайга өмет итсен.

Йөз утыз беренче псалом (мәдхия).
*Песнь степеней*
*(Зиярәтчеләр җыры).*
[1]И Ходай, Давытны, һәм бөтен сабырлыгын исеңә ал. [2]Ул Ягъкуб Алласы Ходайга ант итеп, сүз
биргән: [3]”Йортыма кермәм, ятагыма ятмам, [4]күзләремә йокы бирмәм һәм күз кабакларымны
йомылдырмам, яңакларымны тынычландырмам, [5]Ходайга урын, Ягъкуб Алласына торыр җир
тапканчы”, дип. [6]Менә канун сандыгы Эфратада торган дип ишеттек, аны урман аланында
каршы алганнар. [7]Ходай йортына керербез, аяклары торган урынга башырырбыз. [8]И Ходай, тор,
изгелегеңнең сандыгы белән бергә тынычлык йортыңа *урнаш*. [9]Корбанчыларың дөреслеккә
киенерләр, һәм яраулыларың сөенерләр. [10]Үз бәндәң Давыт хакына майлаганыңның йөзен борып
җибәрмә. [11]Ходай Давытка чынлык белән ант итеп әйткән һәм ант иткәненнән танмас: “Тәхетеңә
*патшалыкка* синнән чыккан нәселдән утыртырмын. [12]Уларың васыятемне тотсалар, һәм аларга

өйрәтәсе таныткычларымны *сакласалар*, аларның уллары да тәхетеңдә гомергә утырырлар”,
дип. 13Чөнки Ходай Сионны сайлап, аны Үзенә торыр урын иткән: 14”Ул Миңа гомердән гомергә
тыныч урын, шунда урнашырмын, чөнки аны теләдем. 15Ашамлыкларын бәхилләп
бәрәкәтләндерермен, ярлыларын икмәккә тукландырырмын. 16Корбанчыларын саклармын, һәм
яраулылары бик сөенерләр. 17Анда Давытның куәтен үстерермен, майлаганыма дан әзерләп
беркеттем. 18Дошманнарын оятка капалрмын, ә аның өстендә изгелегем яшьнәп торыр”, дигән.

Йөз утыз икенче псалом (мәдхия).

*Песнь степеней*

*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Менә, ни яхшы, я ни ямьле, әмма туганнарның бергә торуы! 2Һарунның башыннан сакалына,
киеменең кырыйларына агып җәелгән миро мае кебек, 3Һермон тавыннан Сион таулары өстенә
төшкән чык кебек. Чөнки анда Ходай бәхиллек һәм мәңге тормыш бирмәкче булган.

Йөз утыз өченче псалом (мәдхия).

*Песнь степеней*

*(Зиярәтчеләр җыры).*

1Менә инде Ходайны данлагыз, әй Ходайның бар бәндәләре, Ходай өендә, Аллабыз йортының
ишегалдында торучылар. 2Төннәрен изге урынга кулларыгызны күтәреп, Ходайны данлагыз.
3Күкне һәм җирне булдырган Ходай Сионнан сине бәхилләсен иде.

Шөкер:

18-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 2-нче көйгә.*

Мине хөкем иткәнче, и Ходаем, и Ходай, Сиңа кайтуны һәм күп гөнаһларымның төзәтүен миңа бир; рухи күңел йомшаклыгын миңа бир, Сиңа дәшсәм иде: и игелекле күңелле кеше сөюче Аллам, мине коткар.

Шөкер: Акылсыз туарларга охшаганмын азгын булып, аларга кушылдым; Сиңа кайтуны миңа бүләк ит, и Мәсих, Синнән зур рәхимне кабул итсәм иде.

Әле дә: И Иям Кыз, Сиңа инәлүче миннән йөзеңне борма, әмма юмарт Алланың игелекле күңелле Анасы булганыңа күрә, ахырым булганчы, миңа кайтуны бүләк итәргә тырыш; Синең аркылы котылып, Сине җырласам иде, и Хуҗабикәм, Син минем котылуым һәм оятка калдырмаслык өметем, дип.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Ходай, ярсуың белән мине гаепләмәсәң иде, ачуың белән миңа кыен күрсәтмәсәң иде. И Ходай Иям Гайсә Мәсих, тере Алланың Улы, мин гөнаһлыны, ярлыны, чишенгәнне, ялкауны, тырышсызны, каршы әйтүчене, мескенне, азгынны, уйнашчыны, тиешсез шакшыланучыны, нәҗесне, шөкер итми торганны, рәхимсезне, каты күңеллене, эчкечене, вөҗданым беткәнне, ямьсезне, кыюланыр хәлем беткәнне, җавапсызны, Синең кеше яратуыңа тиешле түгелне, һәм һәртөрле газаплануга да, җәһәннәмгә дә, газапка да тиешлене ярлыка. Һәм минем шулкадәр гөнаһ кылганнарым өчен, и Коткаручы, мине күп газапларга туры китермә; әмма җаным белән дә, тәнем белән дә, акылым белән дә, уйлавым белән дә хәлсез булганыма күрә, мине ярлыка. Һәм Син белгән язмышларың белән, мин яраусыз бәндәңне коткар, безнең Алланы Тудырган иң таза Иябез Кызның да, әүвәлдән үк Сиңа яраулы булган изгеләреңнең дә догалары хакына. Чөнки Син данлаулы гомердән гомергә, амин.

**Унтугызынчы кафисма.**

Йөз утыз дүртенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

1Ходайның исемен мактагыз, әй бәндәләр, Ходайны мактагыз, 2Ходай өендә, Аллабыз йортының
ишегалдында торучылар. 3Ходайны мактагыз, чөнки Ходай игелекле; Аның исеменә җырлагыз,
чөнки ул яхшы. 4Чөнки Ягъкубны Ходай Үзенә сайлаган, Исраилне Үзенеке иткән. 5Мин Ходай

олы икәнне белдем, һәм безнең Ходаебыз аллаларның барысыннан да олы. 6Ходай теләгәннәрен
барын да булдырган, күктә дә, җирдә дә, барча төпсез урыннарда да. 7Җир кырыйларыннан
болытлар күтәрелдерә, яңгыр яуганда яшеннәр яшьнәтә, Үзенең яшерен урыннарыннан җилләр
чыгара. 8Мисырда кешенең дә, туарларның да элек туганнарын үтереп бетергән. 9Әй Мисыр,
синең уртаңда фиргавенгә һәм бар колларына билгеләр һәм могҗизалар җибәргән. 10Күп
халыкларны кырган һәм нык патшаларны үтергән: 11Аморилэр патшасы Сихонны, һәм Башан
патшасы Огны, һәм Кәнган җирендәге барча патшалыкларны да. 12Аларның җирен Үз халкы
Исраилгә, үзенә өлешкә биргән. 13И Ходай, Синең исемең гомергә, һәм Сине искә алу тумыштан
тумышка тора. 14Чөнки Ходай Үз халкын хөкем итәр һәм Үз бәндәләрен кызганыр.
15Мәҗүсиләрнең сыннары көмеш белән алтын, кеше кулының эшләре: 16авызлары булса да,
сөйләшә алмыйлар, күзләре булса да, күрә алмыйлар. 17Колаклары булса да, ишетә алмыйлар,
авызларында тыннары да юк. 18Аларны ясаучылар һәм аларга өмет итүчеләр барысы да алар
кебек булсыннар. 19Әй Исраил тумасы, Ходайны данлагыз! Әй Һарун тумасы, Ходайны
данлагыз! Әй Леви тумасы, Ходайны данлагыз! 20Әй Ходайдан куркучылар, Ходайны данлагыз!
21Иерусалимдә торучы Ходай Сионда данлаулы.

Йөз утыз бишенче псалом (мәдхия).
*Аллилуиа*
*(Һалелуя).*

1Ходайны сөйләп данлагыз, чөнки Ул игелекле, чөнки рәхиме мәңге. 2Аллаларның Алласын
сөйләп данлагыз, чөнки рәхиме мәңге. 3Башлыкларның Ходаен данлагыз, чөнки рәхиме мәңге.
4Ялгызы гына олы могҗизалар кылучыны, чөнки рәхиме мәңге. 5Күкләрне оста булдыручыны,
чөнки рәхиме мәңге. 6Җирне сулар өстенә беркетүчене, чөнки рәхиме мәңге. 7Зур
яктырткычларны ялгызы гына булдыручыны, чөнки рәхиме мәңге. 8Көнне яктыртырга кояшны
*булдыручыны*, чөнки рәхиме мәңге. 9Төнне яктыртырга ай белән йолдызларны *булдыручыны*,
чөнки рәхиме мәңге. 10Мисырны, аның элек туганнарын да кыручыны, чөнки рәхиме мәңге.
11Һәм алар арасыннан Исраилне чыгаручыны, чөнки рәхиме мәңге. 12Куәтле һәм кодрәтле кулы
белән *чыгаручыны*, чөнки рәхиме мәңге. 13Кызыл диңгезне икегә аеручыны, чөнки рәхиме
мәңге. 14Һәм аның уртасыннан Исраилне үткәзүчене, чөнки рәхиме мәңге. 15Фиргавенне дә,
аның чирүләрен дә Кызыл диңгезгә батыручыны, чөнки рәхиме мәңге. 16Үз халкын чүлдән
үткәзүчене, чөнки рәхиме мәңге. 17Зур патшаларны кырып бетерүчене, чөнки рәхиме мәңге.
18Һәм нык патшаларны үтерүчене, чөнки рәхиме мәңге. 19Аморилэр патшасы Сихонны
*үтерүчене*, чөнки рәхиме мәңге. 20Һәм Башан патшасы Огны *үтерүчене*, чөнки рәхиме мәңге.
21Һәм аларның җирен *Исраилгә* өлешкә бирүчене, чөнки рәхиме мәңге. 22Үз бәндәсе Исраилгә
өлешкә *бирүчене*, чөнки рәхиме мәңге. 23Без кимсетелгән чакта, Ходай безне исенә алды, чөнки
рәхиме мәңге. 24Һәм безне дошманнарыбыздан коткарды, чөнки рәхиме мәңге. 25Һәрбер тәнгә
ашамлык бирә Ул, чөнки рәхиме мәңге. 26Күктәге Алланы сөйләп данлагыз, чөнки рәхиме
мәңге.

Йөз утыз алтынчы псалом (мәдхия).
*Давида. Иеремиею*
*(Давытныкы. Иремия аша).*

1Бабыл инешләренең буенда утырып, Сионны исебезгә алган чакта елаштык. 2Анда
уеннарыбызны талларга элеп куйдык. 3Безне тоткынга алучылар шунда бездән җыру сүзләрен
сораштырдылар, һәм безне алып килүчеләр: “Сион җыруларын безгә җырлагыз” дип, җырларга
*куштылар*. 4Ходай җыруын чит җирдә ничек җырларбыз? 5Әй Иерусалим, сине онытсам, уң
кулым онытылсын. 6Сине исемә алмасам, Иерусалимне иң олы сөенечемә куймасам, телем
тамагыма ябышсын. 7И Ходай, Иерусалимне *җимергән* чакта: “Бетерегез аны, нигезенә чаклы
бетерегез”, дигән Эдом улларын исеңә төшер. 8Әй Бабылның мескен кызы, безгә кылганыңны
сиңа кайтарасы кеше бәхетле. 9Балаларыңны алып ташка бәрәсе кеше бәхетле.

Шөкер:

Йөз утыз җиденче псалом (мәдхия).
*Псалом Давида. Аггея и Захарии*
*(Давытның мәдхиясе. Хәггәй белән Зәкәриянеке).*

[1]И Ходай, бар күңелем белән Сине сөйләп данлармын, һәм фәрештәләр алдында Сине данлап
җырлармын, чөнки авызымның бар сүзләрен ишеттең. [2]Синең изге өеңә башырырмын, рәхимең
һәм чынлыгың өчен исемеңне данлармын, чөнки изге исемеңне барыннан да олы иттең. [3]Сиңа
инәлеп дәшкән көнне мине тиз ишет: җаным турысында куәтең белән күп кайгырт. [4]И Ходай,
җирдәге патшалар барысы да Сине данласыннар иде, чөнки авызыңның бар сүзләрен ишеттеләр,
[5]һәм Ходай юлларын данлап җырласыннар иде, чөнки Ходайның даны олы. [6]Ходай югары,
юашларга да күз сала, олыларны да ерактан таный. [7]Кайгы эчендә торсам да, мине терелтерсең:
дошманнарымның ачуына каршы кулыңны суздың, һәм мине уң кулың саклады. [8]Ходай минем
өчен кайтарыр; и Ходай, рәхимең гомергә, кулың булдырганнарны ким күрмә.

Йөз утыз сигезенче псалом (мәдхия).

*В конец. Давида. Псалом Захарии, в рассеянии*

*(Ахырга. Давытныкы. Зәкәриянең мәдхиясе, таралышканнан соң).*

[1]И Ходай, Син мине сынадың, инде мине беләсең: минем кайчан утырганымны һәм кайчан
торганымны да беләсең. [2]Уйларымны ерактан тоясың. [3]Сукмагымны һәм чамалавымны
эзәрлекләдең, һәм минем бар юлларымны алдан күрдең. [4]Минем телемдә юмалау юк. [5]Менә Син
Ходай, соңгыларны да, элеккегеләрне дә, барчасын беләсең. Син мине булдыргансың һәм миңа
кулыңны салып торасың. [6]Синең белүеңә исем китә, ул минем көчемнән тышкары, аны аңлар
хәлем юк. [7]Синең Рухыңнан кая китәрмен һәм Синең йөзеңнән кая качармын? [8]Күккә менсәм,
Син анда, тәмугка төшсәм, анда да Син. [9]Канатларым булып, кояш чыгышына очсам да, я
диңгез кырыйларына ук урнашсам да, [10]анда да Синең кулың мине йөртер һәм уң кулың мине
тотар. [11]Һәм әйттем: “Әллә мине караңгы күрсәтми тотар микән?”, дидем. Төн дә минем
әйләнәмдә яктыга алмашыр. [12]Чөнки Синең алдыңда караңгы да караңгы түгел һәм төн дә көн
кебек якты булыр: төн караңгысы көн яктысы кебек. [13]Чөнки Син бөтен эчем белән мине
Үзеңнеке иттең, анам корсагыннан мине күтәреп алдың. [14]Котчыгаргыч искитәрлек икәнең
Үзеңә әйтәм: эшләрең искитәрлек, һәм җаным аны бик белә. [15]Яшерендә Син булдырган
сөякләрем дә, җир астындагыдай төштә *булдырылган* гәүдәм дә Сиңнән яшерен түгел.
[16]Яралуымны ук күзләрең күрде һәм китабыңда ничә көнгә булдырылганнары язылулы,
язылмаганы берәү дә юк. [17]Миңа исә дусларың бик кадерле, и Алла, аларның куәтләре нык.
[18]Санасам, алар комнан да күп; уяндым исә, мин Синең белән. [19]И Алла, гөнаһлыларны кырып
бетерсәң иде; әй кан түгүчеләр, миннән читкә китегез. [20]Чөнки алар *усал* уйлар төзүне бик
яраталар, калаларыңда бушка гына торалар. [21]И Ходай, Сине күрәлмаганнарны яратмадым
түгелме, һәм дошманнарыңа *ачуым килеп* корып беттем. [22]Бөтенләй аларны күрәлмадым,
яратмадым, алар миңа дошман булдылар. [23]И Алла, мине сына һәм күңелемне бел; мине сына да
сукмакларымны аңыш. [24]Юлым канунсызлык юлы түгелме, күр, һәм мине мәңгелек юлына
бастыр.

Йөз утыз тугызынчы псалом (мәдхия).

*В конец. Псалом Давида*

*(Ахырга. Давытның мәдхиясе).*

[1]И Ходай, усал кешедән мине аралап ал, дөрес түгел кешедән мине коткар. [2]Алар күңелләрендә
дөрессезлек уйлыйлар, көн саен сугышырга тотыналар. [3]Телләрен елан теле шикелле
үткенләгәннәр, тел асларында аспид *дигән еланныкыдай* зәһәр тора. [4]И Ходай, гөнаһлылар
кулыннан мине сакла, дөрес түгел кешеләрдән мине аралап ал, алар аякларымны чалырга уй
троттылар. [5]Горурлар миңа яшерен тозак салдылар, һәм аякларымны эләктерергә тозакларын
элмәкләп куйдылар. [6]Сукмак өстенә миңа абындыргыч салдылар. [7]Ходайга әйттем: Син – минем
Аллам, и Ходай, инәлүемнең авазына аң сал. [8]И Ходай, и Ходай, мине саклаучы куәт, сугыш
көнендә башымны ябып тордың. [9]И Ходай, миңа каршылык итәргә уйлаучы гөнаһлыга мине
ирек бирмә: миңа каршылык уйладылар, мине ташлама, алар һичкайчан күтәрелмәсеннәр иде.
[10]Җыелышып иткән *усал киңәшләренең* иң яманы, авызларының эшләре үзләренә каплансын.
[11]Утлы күмерләр аларга төшәрләр, азап күрсәтеп аларны егылдырырсың һәм тора алмаслар.
[12]Яман телле кеше җирдә алга китмәс, дөрес түгел кешене яманлык туры китереп харап итәр.
[13]Ярлыларга Ходай хөкем итәсене һәм мескеннәргә кайтарасыны белдем. [14]Шунлыктан гаделләр
Синең исемеңне данларлар һәм дөресләр йөзең алдында урнашырлар.

Шөкер:

Йөз кырыгынчы псалом (мәдхия).

*Псалом Давида*

*(Давытның мәдхиясе).*

1И Ходай, Сиңа инәлеп дәшәм, мине ишет, Сиңа инәлгән чагымда догамның авазын тыңла.
2Минем догам, ладан исе кебек, Синең алдыңа җитсен иде, кулым күтәреп инәлгәнем – кичке
корбан кебек. 3И Ходай, авызымны сакландыр һәм телемне дә тыелдыр. 4Гөнаһларымның гаебен
киметер өчен, яман сүзләр әйтергә күңелемне авыштыра күрмә, канунсызлык кылучы кешеләр
кебек *булмасам иде*, аларның олылары белән дә йөрмәсәм иде. 5Гадел кеше мине рәхимлелек
белән үгетләсен һәм оялтсын, гөнаһлы кеше исә башыма май да сөртмәсен; алар теләгәнчә
булмасын иде дип, тә инәләмен. 6Аларның түрәләре *суга ташлаган* таш кебек югалырлар,
шунда татлы сүзләремне белерләр. 7Калын балчык ярылып җир өстендә таралгандай, аларның
сөякләре кабер янында таралып ятыр. 8Тик, и Ходай, и Ходай, күзләрем Сиңа таба: Сиңа өмет
итәм, җанымны ала күрмә. 9Миңа дип салган тозаклардан һәм канунсызлык кылучыларның
кызыктыруыннан мине сакла. 10Гөнаһлылар үз ауларына эләгерләр, ә мин ялгыз *имин калып,
дөньядан* күчкәнче, торырмын.

Йөз кырык беренче псалом (мәдхия).

1*В научение. Давида, когда он в пещере молился*

*(Давытның нәсыйхәте, мәгарәдә әйткән догасы).*

2Авазым белән Ходайга дәштем, авазым белән Ходайга инәлдем. 3Аның алдында догамны
агылдырырмын, хәсрәтемне әйтермен. 4Тыным чыгарга гына торганда да Син сукмакларымны
белеп тордың: мин йөри торган юлда миңа яшерен тозак корганнар. 5Уң ягыма, әйләнәмә
карадым, тик мине белүче юк иде, качар хәлем дә юк, җаным өчен көюче дә юк. 6И Ходай, Сиңа
дәшеп әйттем: Син минем өметем, тереләр җирендәге өлешем. 7Инәлүемә аң сал, чөнки бик
кимгә калдым, куучылардан мине коткар, чөнки миннән бигрәк ныгыдылар. 8Караңгы җирдән
җанымны чыгар, Синең исемеңне данласам иде; Син миңа кайтарганчы, гаделләр мине көтеп
торалар.

Йөз кырык икенче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида, когда его преследовал Авессалом, сын его*

*(Давытның үз улы Абшалум аны эзәрлекләгән чагында әйткән мәдхиясе).*

1И Ходай, догамны ишет, Үз чынлыгың хакына инәлүемә аң сал, дөреслегең буенча мине ишет.
2Һәм бәндәңне хөкемеңә салма, чөнки Синең алдыңда дөньяда торучының берсе дә дөрескә чыга
алмас. 3Чөнки дошман җанымны куды, тормышымны җиргә таптады, күптәнге үлекләргә
охшашлы итеп, мине караңгыга япты. 4Һәм эчемдәге рухым моңайды, йөрәгем каушады.
5Әүвәлге көннәрне исемә төшереп, барча эшләреңнән өйрәндем, кулларың эшләреннән үгет
алдым. 6Кулларымны Сиңа күтәрдем, җаным Сиңа сусаган җир кебек тора. 7И Ходай, мине тиз
ишет, рухым бетәргә тора; йөзеңне миннән борма, югыйсә кабергә төшерелә торганнарга
охшашырмын. 8Рәхимеңне миңа иртүк ишеттер, чөнки Сиңа өметләндем; и Ходай, барасы
юлымны миңа күрсәт, чөнки җанымны Сиңа күтәрдем. 9Дошманнарымнан мине аралап ал, и
Ходай, Сиңа сыендым. 10Үз иркеңне кылырга мине өйрәт, чөнки Син минем Аллам. Игелекле
Рухың мине дөрес җиргә алып барсын иде. 11Үз исемең хакына, и Ходай, мине терелтерсең,
дөреслегең буенча җанымны кайгыдан чыгарырсың. 12Үз рәхимең буенча дошманнарымны
бетерерсең һәм җанымны кысучыларны барысын да юк итәрсең, чөнки мин Синең бәндәң.

Шөкер:

19-нчы кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 7-нче көйгә.*

Шөкер итеп, Сине данлыймын, и Аллам, чөнки бар гөнаһлыларга тәүбә биргәнсең. И Коткаручы, бөтен дөньяны хөкем итәргә килгән чагыңда, оят эшләр кылучы мине оятка калдырма.

Шөкер: Сиңа чамасыз гөнаһ кылгач, чамасыз газапларны да көтәмен; и Аллам, юмартлык кылып, мине коткар.

Әле дә: Синең күп рәхимеңә хәзер килеп сыенамын, и Алланы Тудыручы, гөнаһларымның богауларын чишә күр.
И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Иям Мәсих Алла, Син Үз газапларың белән минем хәстәләремне савыктыргансың, һәм яраларың белән минем яраларымны дәвалагансың, Сиңа күп гөнаһ кылган миңа күңел йомшаклыгы белән күз яшен бүләк ит. Үзеңнең тере итүче Тәнеңнең хуш исен минем тәнемә дә катнаштыр, һәм каршы торучы мине ачы нәрсә белән эчерткәнгә, Үзеңнең кадерле Каның белән җанымны татлыландыр. Түбән авышкан акылымны Үзеңә таба күтәрелдер, һәм харап итү упкыныннан алып чыгар. Чөнки тәүбәгә килүем дә юк, күңелем йомшаклыгы да юк, котылу улларын тиешле җиргә күтерелдерә торган тынычландыручы күз яшем дә юк. Акылым белән дөнья нәфесләрендә караңгыландым, кайгырып һәм сызланып Сиңа кара алмыйм, Сине сөю күз яшьләремне чыгарып җылына алмыйм. Әмма, и Ходай Иям Гайсә Мәсих, яхшылыклар хәзинәсе, тулы тәүбәгә килү, һәм Сине эзләп табар өчен тырыш күңелне миңа бүләк ит; Үз дәүләтеңне миңа бүләк ит, һәм Үз төсеңнең охшашларын миндә яңарт. Сине ташлаганмын, мине ташлама; мине эзләп табар өчен чыга күр, Үзеңнең көтүлегеңә мине алып чыгар, һәм сайланган көтүеңнең сарыкларына мине дә кушылдыр. Алар белән бергә Синең Аллалык яшерегеңнең ашлыгыннан мине дә асра, Синең иң таза Анаңның да, бар әүлияләреңнең дә догалары хакына, амин.

**Егерменче кафисма.**

Йөз кырык өченче псалом (мәдхия).

*Псалом Давида. О Голиафе.*

*(Давытның мәдхиясе. Галиат турында).*

1Ходай Аллам данлаулы, Ул кулларымны сугыш рәтенә, бармакларымны *коралын тотарга*
өйрәтә. 2Рәхимем минем һәм сыенганым, яклаучым минем һәм коткаручым, аралаучым һәм Аңа
өметләндем; халкымны миңа буйсындыра. 3И Ходай, кеше ни нәрсә? Алай да аңа Үзеңне
белдердең; я адәм улы ни? Аны санлыйсың икән. 4Кеше буш нәрсә кебек, көннәре күләгәдәй
үтәләр. 5И Ходай, күкләрне сыгылдырып иң, тауларга тиен, һәм төтенләнерләр. 6Яшен яшьнәт,
һәм *дошманнарны* таратырсың, укларыңны җибәр, һәм аларны болгатып бетерерсең. 7Югартын
кулыңны сузып, мине аралап ал, дәү сулардан һәм ятлар улларының кулыннан мине коткар.
8Аларның авызлары бушны сөйләштеләр һәм уң куллары – дөрессезлек кулы. 9И Алла, Сиңа яңа
җыру җырлармын, ун кыллы саз уйнап, Сиңа җырлармын. 10Патшаларга котылу бирүчегә, Үз
бәндәң Давытны яман кылычтан коткаручыга *җырлармын*. 11Коткар мине һәм ятлар улларының
кулыннан аралап ал, аларның авызлары бушны сөйләштеләр, һәм уң куллары – дөрессезлек
кулы. 12Аларның уллары яңа утыртылып нык тамырланган яшь агачтай, кызлары матурлаган
өйдәй әйбәт киенәләр, үзләре бик чибәр. 13Амбарлары тулы, бураларының берсеннән икенчесенә
агыла, сарыклары үрчемле, көтелә торган җирләрендә ишәяләр, үгезләре көр. 14Коймалары нык,
урамнарында елашып кычкырышу юк. 15Андый кешеләрне бәхетлегә куялар, *әмма* Алласы
Ходай булган халык кына бәхетле.

Йөз кырык дүртенче псалом (мәдхия).

*Хвала Давида*

*(Давытның мактау җыры).*

1И Аллам, Патшам, Сине күтәрермен һәм Синең исемеңне гомергә һәм гомердән гомергә
данлармын. 2Һәрбер көнне Сине данлармын һәм исемеңне гомергә һәм гомердән гомергә
мактармын. 3Ходай олы һәм бик мактаулы, олылыгының чиге дә юк. 4Эшләреңне тумыштан
тумышка мактарлар һәм куәтеңне белдерерләр. 5Изгелегеңнең ямьле данын сөйләрләр һәм
могҗизаларыңны да белдерерләр. 6Котчыгаргыч эшләреңнең куәтен әйтерләр һәм олылыгыңны
да белдерерләр. 7Күп яхшылыгыңны искә алып, әйтеп җәелдерерләр һәм дөреслегеңә сөенерләр.
8Ходай юмарт һәм рәхимле, озак түзүчән һәм күп рәхимле. 9Ходай барысына да игелекле, һәм
юмартлыклары бар эшләрендә дә. 10И Ходай, булдырган нәрсәләрең барысы да Сине белдереп
торсыннар иде, һәм яраулыларың Сине данласыннар иде. 11Патшалыгыңның данын әйтерләр
һәм кодрәтеңне сөйләрләр, 12шул кодрәтеңне һәм патшалыгыңның ямьле данын адәм уллары

белсеннәр дип. 13Патшалыгың бар гомерләрдә дә тора торган патшалык, һәм тотып торуың
тумыштан тумышка тора. Ходай бар сүзләрендә дә дөрес һәм бар эшләрендә дә шиксез.
14Егылырга торганнарны барысын да Ходай егылтмый тота һәм түбән егылганнарны барысын да
торгыза. 15Барчаларның күзләре Сиңа өметләнеп торалар, һәм Син аларга кирәкле чагында
ашамлык бирәсең: 16кулыңны ачып, һәрбер җанлыны теләгәне белән туйдырасың. 17Ходай бар
юлларында да гадел һәм бар эшләрендә дә шиксез. 18Инәлеп дәшүчеләренә, чынлык белән
инәлеп дәшүчеләрнең барысына да Ходай якын. 19Үзеннән куркучыларның теләгәнен булдырып
бирер, һәм догаларын ишетеп, аларны коткарыр. 20Үзен сөючеләрне Ходай барысын да саклый
һәм гөнаһлыларның барысын да бетерер. 21Авызым Ходайның данын сөйләр, һәм һәрбер тән
Аның изге исемен гомергә, һәм гомердән гомергә данласын.

Шөкер:

Йөз кырык бишенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа. Аггея и Захарии*

*(Һалелуя. Хәггәй белән Зәкәриянеке).*

1Әй җаным, Ходайны макта. 2Гомеремдә Ходайны мактармын, үзем торган тиңенте Аллама
җырлармын. 3Коткара алмый торган башлыкларга, адәм улларына ышанып тормагыз. 4Адәмнең
рухы чыкты исә, ул кире туфрагына кайтыр, тоткан исәпләре барысы да шул көнне үк юкка
чыгар. 5Булышучысы Ягъкуб Алласы булган кеше, өметен Үз Алласы Ходайга иткән кеше
бәхетле. 6Шул Алла күкне һәм җирне, диңгезне һәм алардагы бар нәрсәләрне дә булдырган,
чынлыкны гомергә тота. 7Золымлык күрүчеләргә гаделлек кыла, ачыкканнарга ашамлык бирә.
Ходай богаудагыларны ычкындыра. 8Ходай сукырларны белемле итә, Ходай түбән
егылганнарны торгыза, Ходай гаделләрне ярата. 9Ходай читтән килеп торучыларны саклый,
үксезне һәм тол хатынны яклый, гөнаһлыларның юлын исә юкка чыгарыр. 10Әй Сион, Ходай
Аллаң гомергә, тумыштан тумышка патшалык итәр.

Йөз кырык алтынчы псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

1Ходайны мактагыз, чөнки мәдхия җырлау – яхшы эш, Аллабызга мактау татлы тисен.
2Иерусалимне торгызучы Ходай чәчелгән Исраилләрне җыяр. 3Ул күңелләре кайгылыларны
савыктыра һәм имгәнгән төшләрен бәйли. 4Йолдызларның исәбен белә һәм аларның барысына
да исем бирә. 5Ходаебыз олы, һәм кодрәте зур, белүенең чиге дә юк. 6Ходай сабырларны яклый,
гөнаһлыларны исә җиргә чаклы ия. 7Ходайны данлый башлагыз, Аллабызга гөслә белән
җырлагыз. 8Ул күкне болытлар белән киендерә, җиргә яңгыр әзерли, таулар өсләрендә үлән
үстерә һәм кешеләргә ашамлыкка ашлыклар *үстерә,* 9туарларга һәм Үзенә кычкырып тора
торган карга балаларына ашамлык бирә. 10Кешенең ат көченә *ышануын* теләми, аның аяк
ныклыгына *ышануына да* риза түгел, 11*әмма* Ходай Үзеннән куркучыларга һәм Аның рәхименә
өмет итүчеләргә генә ризалык итә.

Йөз кырык җиденче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа. Аггея и Захарии*

*(Һалелуя. Хәггәй белән Зәкәриянеке).*

1Әй Иерусалим, Ходайны макта, әй Сион, Аллаңны данла. 2Чөнки Ул капкаңның биген
ныгыткан, синдә *торучы* улларыңны бәхилләгән. 3Синең тирәләреңне тыныч тота һәм тук бодай
белән сине туйдыра. 4Үз сүзен җиргә җибәрә, Аның сүзе тиз җәелә. 5Карны йон кебек яудыра,
томанны көл кебек сибә. 6Бозын кисәге-кисәге белән яудыра, Аның суыгына кем чыдый алыр?
7Сүзен әйтеп җибәргәч, аларны эретә, җилен истерсә, сулар ага. 8Үз сүзен Ягъкубка әйтә,
боерыкларын һәм хөкемнәрен Исраилгә белдерә. 9Бер халыкка да алай кылмаган һәм аларга
хөкемнәрен белдермәгән.

Шөкер:

Йөз кырык сигезенче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа. Аггея и Захарии*

*(Һалелуя. Хәггәй белән Зәкәриянеке).*

[1]Әй күктәгеләр, Ходайны мактагыз, әй югарыдагылар Аны мактагыз. [2]Бар фәрештәләре Аны
мактагыз, бар чирүләре Аны мактагыз. [3]Кояш һәм ай, Аны мактагыз, якты һәм бар йолдызлар,
Аны мактагыз. [4]Күк өстендәге күкләр һәм күкләр өстендәге су да Аны мактагыз. [5]Ходайның
исемен мактасыннар, чөнки Ул әйткәч ,булганнар, Ул кушкач, яралганнар. [6]Аларны гомергә һәм
гомердән гомергә куйган, рәтен үзгәрмәслек итеп куйган. [7]Җирдәге еланнар һәм барча төпсез
җирләр, Ходайны мактагыз. [8]Ул кушканны кылучы ут, боз, кар, бозлы кар, давыллы җил;
[9]таулар һәм бар түбә җирләр, җимеш китерә торган агачлар һәм бар эрбет агачлары; [10]киекләр
һәм бар туарлар, шуышып йөри торган җәнлекләр һәм канатлы кошлар; [11]җирдәге патшалар һәм
бар халыклар, башлыклар һәм җирдәге бар түрәләр; [12]егетләр һәм кызлар, картлар белән яшьләр
*барысы да* [13]Ходайның исемен мактасыннар, чөнки бер Аның гына исеме күтәрелгән, Ул җирдә
дә, күктә дә данлаулы. [14]Һәм Ул Үз халкының куәтен күтәрер. Яраулылары барысы да, Аңа
якынлашучы халык, Исраил уллары, Аны данларлар.

Йөз кырык тугызынчы псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

[1]Ходайга яңа җыру җырлагыз: яраулылар җыенында Ул мактаулы. [2]Исраил үзен Булдыручыга
куансын, һәм Сион уллары да үз патшаларына сөенсеннәр. [3]Җыручылар җыены Аның исемен
мактасыннар, тимпан һәм саз белән Аңа җырласыннар. [4]Чөнки Ходай Үз халкына ризалык итә
һәм сабырларны котылдырып күтәрер. [5]Яраулылар данлаулы торып куанырлар һәм тыныч
урыннарында сөенерләр. [6]Авызларында Алланы зурлау һәм кулларында ике ягы да үткен
кылыч, [7]халыкларга үч кайтарырга дип, кешеләрне оялтырга дип, [8]патшаларын чылбыр белән
һәм олыларын тимер богау – кул богавы белән бәйләргә дип, [9]язган хөкемне аларга кылырга
дип. Шундый зурлык Аның бар яраулыларына тияр.

Йөз илленче псалом (мәдхия).

*Аллилуиа*

*(Һалелуя).*

[1]Алланы изге өендә мактагыз, нык куәтлегә күрә, Аны мактагыз. [2]Кодрәтлегә күрә, Аны
мактагыз, зур олылыгына күрә, Аны мактагыз. [3]Быргы авазы белән Аны мактагыз, саз һәм гөслә
белән Аны мактагыз. [4]Җыручылар җыены һәм тимпан белән Аны мактагыз, кыллы уен һәм
курай белән Аны мактагыз. [5]Ямьле авазлы кимвал белән Аны мактагыз, зур тавышлы кимвал
белән Аны мактагыз. [6]Һәрбер җанлы нәрсә Ходайны мактасын.

Шөкер:

Йөз илле беренче псалом (мәдхия).

*Сей псалом писан особо, вне числа 150 псалмов,*
*Давида, когда он единоборствовал с Голиафом*
*(Шушы мәдхия аерым язылган, 150 мәдхия санынан тыш,*
*Давытныкы, аның Галиат белән бермә-бер сугышканына нисбәтле).*

[1]Туганнарым арасында иң кечесе идем һәм атам йортында иң яше идем. Атамның сарыкларын
көттем. [2]Кулларым курай ясадылар, һәм бармакларым саз көйләделәр. [3]Ходаема *мине* кем
белдерер иде? Ходай Үзе, Үзе мине ишетте. [4]Үзенең фәрештәсен җибәреп, мине атам сарыклары
янынннан алдырды һәм изгеләндерү мае белән мине майлатты. [5]Агаларым бар да зурлар һәм
матурлар иде, алай да Ходай аларга күңел итмәде. [6]Ят зат кешесенә каршы чыктым, һәм ул мине
үзенең сыннарын әйтеп, каргады. [7]Әмма мин аның кылычын алып, башын чабып өздем, шулай
итеп Исраил улларын хурлыктан коткардым.

20-нче кафисмадан соң,

Өч изгелек.

*Тропарьләр: 8-нче көйгә.*

Һәртөрле яхшылыкларны булдырып җиткезүче Син, и Мәсихем, сөенечкә һәм куанычка
җанымны тулыландыр, һәм коткар мине, чөнки Син бер генә күп рәхимле.

Шөкер: Синең алдыңда гөнаһ кылган булсам да, и Коткаручы Мәсихем, Синнән башка бүтән
алланы белмимен, Синең игелекле күңеллелегеңә кыючылык итәмен исә, азгын улны кабул

иткәнең кебек, Сиңа кайтучы мине дә кабул ит, и игелекле күңелле Ата, һәм бердәнбер туган Ул, һәм Изге Рух, һәм коткар мине.

Әле дә: Синнән башка бүтән сыеныр җирне һәм җылы яклауны белмимен; Үзеңнән Туганга кыюлыгың барлыгына күрә, и Иям Кыз, булыш, һәм Үз бәндәңне мине коткар.

И Ходай ярлыка *(40 тапкыр).*

Дога.

И Ходай Аллам Гайсә Мәсих, мин гөнаһлыны ярлыка, һәм гомеремнең бар вакыты аша бүгенгә чаклы Сиңа кылган гөнаһларымны мин тиешсез бәндәңә кичер. Һәм адәм булганга күрә, ни белән генә гөнаһ кылган булсам да: иректән кылган гөнаһларым һәм ирексездән, эшем белән һәм сүзем белән, акылым белән һәм исәбем белән, күңелем авышуыннан һәм аң салмаганлыктан, күп ялкаулыгымнан һәм саксызлыгымнан, барысын да миңа кичер. Синең исемең белән ант иткән булсам, ялганга ант иткән булсам, я уем белән хурлаган булсам, я бер-бер кешене тиргәгән булсам, я әләкләгән булсам, я кайгырткан булсам, я бер-бер нәрсәгә ачуландырган булсам; я урлаган булсам, я азгынлык кылган булсам, я ялганлаган булсам, я яшертен ашаган булсам, я дустым килеп, аны кабул күрмәгән булсам; я туганымны хурлап, ачуын китергән булсам; я дога кылганда һәм мәдхия җырлаганда, яман уем яманга авышкан булса, я кирәкледән артык рәхәтләнгән булсам, я акылсызланып көлгән булсам, я уйнап сөйләшкән булсам; я масайган булсам, я горурланган булсам, я дөньяның буш нәрсәләрен күреп, аларга алданган булсам, я тиешсез нәрсәләргә күңелемне биргән булсам; я дога кылуым турыда пошмаган булсам, я рухи атамның боерыкларын сакламаган булсам, я бушны сөйләшкән булсам, я бүтән начарлыкны кылган булсам, барысын да миңа кичер. Боларның барысын һәм болардан күбрәктер мин кылдым, аларны исемә китерә алмыйм. И Ходай, ярлыка, һәм барын да миңа кичер, тынычланып йокыга китсәм иде. Сине була башлаган чагы юк Атаң белән, һәм иң изге, һәм игелекле, һәм тере итүче Рухың белән җырлап һәм мактап данласам иде, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

Ахыр һәм Аллага шөкер.

*Псалтырьне (Зәбурны) укып чыккач әйтелә торган догалар.*

Чынлап дөрес тиешле, и Алланы тудырган Кыз, Сине кадерләргә, Син мәңгегә кадерле, шиксез таза, Син безнең Аллабызның Анасы. Херувимнәрдән дә кадерле, серафимнәрдән дә данлы, Кыз көе Сүз Алланы тудырган, чын Алла Анасы Сине олылыйбыз.

*Яисә*:

Синең турыда, и дәүләтле Кыз, булдырганнарның барысы: фәрештәләр җыены һәм адәм заты сөенешәләр. Изге ителгән өй һәм сүзле оҗмах Син, кызлык яме; мәңгедән бар Аллабыз Синдә тәнләнеп Сабый булган, эчеңне Үз тәхетен иткән һәм корсагыңны күктән дә киң иткән. Синең турыда, и дәүләтле Кыз, булдырганнарның барысы сөенешәләр, Сиңа дан тиешле.

Изге Алла, Изге Кодрәтле, Изге Үлемсез, безне ярлыка. *(3 тапкыр).*

Шөкер Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә. Амин.

И иң изге Өчле, безне ярлыка; и Ходай, безне гөнаһтан тазарт; и Иябез, кануныңнан язганыбызны кичер; и Изге, безгә килеп безнең хәлсезлекләребезне савыктыр, Үз исемең өчен.

И Ходай, ярлыка. *(3 тапкыр).*

Шөкер Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә. Амин.

И Күктәге Атабыз, изге ителеп торсын исемең Синең; килсен патшалыгың Синең; җирдә дә күктәгечә булсын иркең Синең. Бүген көнлек икмәгебезне бир безгә, һәм бурычларыбызны безгә кичер, без дә безгә бурычлы булганнарга кичергән кебек; һәм сыналуга безне кертмә, әмма яманнан безне котылдыр.

*Тропарьләр: 6-нчы көйгә.*

Безне ярлыка, и Ходай, безне ярлыка, без гөнаһлылар үзебезне дөресләргә бер җавап та бирә алмагач, тик Син безне тотучыга шушылай гына инәләбез: и Ходай, безне ярлыка.

Шөкер: И Ходай, Синең пәйгамбәреңнең кадерле тантанасы җыенны күк итеп күрсәткән, кешеләр белән фәрештәләр сөенешәләр. Аның догалары хакына, и Мәсих Алла, гомеребезне тыныч үткәздер, Сиңа җырласак иде: аллилуиа.

Әле дә: Гөнаһларым күптән күп, и Алла Анасы, мине коткар дип, сыенып, и данлаулы таза Кыз, Сиңа инәләмен. Хәлсезләнгән җанымны күреп, Үз Улың безнең Аллага инәл, кылган усал эшләремне барысын да кичерсен иде.

И Ходай ярлыка. *(40 тапкыр).*

*Сурияле Ефрем әүлия ата догасын әйтеп, күпме телисең башыр.*

И Ходай һәм гомеремнең Иясе, ялкаулык, боегу, баш булу ярату һәм бушны сөйләү рухын миннән читләштер. *Бер башыр.*

Таза уйлау, юаш уйлау, түземлек һәм сөю рухын исә, мин бәндәңә бүләк ит. *Тагы башыр.*

Әйе Патшам Ходай, үз гөнаһларымны күрергә һәм туганымны хөкем итмәскә миңа бүләк ит, чөнки Син данлаулы гомердән гомергә, амин. *Тагы башыр.*

*Аннары бу доганы аң белән укы.*

И күп рәхимле һәм иң мәрхәмәтле Ходай, бар яхшылыкны бирүче кеше Сөюче, һәм бөтен дөньяның Патшасы, күп төрле исемле Иям һәм Ходай, ярлы һәм мескен мин үзем, Синең искитәрлек, һәм куркыныч, һәм изге исемеңә дәшәргә кыючылык итәмен. Шул исемеңнән исә, Үзең булдырган күктәге бар чирүләр куркышып калтырашалар. Үзеңнең сөекле Улыңны җибәрү белән, түбән җирдәге адәмгә әйтеп җиткезүсез мәхәббәтеңне искитәрлек итеп күрсәткәнсең. Кешеләрне дә фәрештәләр белән бер итеп төзесен дип, Аталык даныңның башлаусыз куеннарыннан аерылгысыз Аллалыгың белән Аны аерым иткәнсең. И Ходай, моңаеп юашлануымны исеңә ал; тирес һәм туфрак мин, Сиңа, әйтеп җиткезүсез Яктылыга инәлеп дәшәмен, тән хәлсезлеге белән чолганып; ул тәнне Синең Сүзең рәхим күрсәтеп, Үзенә алды, һәм Үз үлеме белән җаннарыбызны дошманга хезмәт итүдән азат итте; иман белән эшең камытын үзләренә алганнарны Синең даныңа тиешле итәр өчен; ул даныңнан әүвәле алдаучы шайтан егылып төшкән. Гөнаһлы уйлар белән караңгыланган мине ярлыка, ялкаулык күгәне һәм буйсынмау бозы белән басылган акылымны күтерелдер; күңелемне Сиңа ялкынланып торырга тотрыклы ит, күзләремә күз яше чишмәсен җибәр, һәм әҗәлем килеп җиткән чакта, Сиңа бозылусыз яраулы булырга мине Үзең ит, Синең өчен тырышып хезмәт итәргә мине өйрәтеп. И Ходай, Үзеңнең рәхимле күңеллелегең белән минем ата-анамны исеңә ал, һәм бар якыннарымны да, туганнарымны да, дусларымны да, күршеләремне дә, бар дөрес дин тотучы мәсихчеләрне дә исеңә ал; һәм бар изгеләреңнең догалары хакына мине коткар. Әле шушы Синең каршыңда әйткән мәдхияләрне һәм догаларны кадергә санап кабул ит, һәм шушы сызланып инәлгәнем Синең алдыңда җирәнгеч булмасын иде. Чөнки Син рәхимле һәм кеше сөюче, һәм Сине, була башлаусыз Атаны, бердәнбер туган Улың белән, һәм Изге Рухың белән данлыйбыз, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә, амин.

*Аннары:* Херувимнәрдән дә кадерле, серафимнәрдән дә данлы, Кыз көе Сүз Алланы тудырган, чын Алла Анасы, Сине олылыйбыз.

Шөкер Атага, һәм Улга, һәм Изге Рухка, әле дә, һәрчакта да, гомердән гомергә. Амин.

И Ходай, ярлыка. *(3 тапкыр).*

Бәхиллә.

И Ходай Гайсә Мәсих, Алла Улы, Синең иң кадерле таза Анаңның догалары хакына, кадерле һәм тере итә торган Хачыңның куәте белән, күктәге изге тәнсез чирүләрнең дә, күңелләрендә Алланы йөрткән яраулы аталарыбызның да, изге пәйгамбәрең Давытның да, бар әүлияләреңнең дә догалары хакына, мин гөнаһлыны да ярлыка һәм коткар, чөнки Син игелекле һәм кеше сөюче.